PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

№3 (303) – МАРТ 2017

ТАТАРСТАН

TATARSTAN

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1920 елдан
нәшер ителә

Ишегалларын нинди
киләчәк көтә

Бакый Урманче:
халыктан алганны – халыкка

Кубрат хан
хәзинәсе

РЕНАТ ИБРАҺИМОВ:
«ӨЕҢ – ҖИРДӘГЕ ҖӘННӘТ УЛ»

16+

Редакция:
420066, Казан,
Декабристлар ур., 2,
тел. (843) 222-09-79
tatarstan@tatmedia.com

Баш мөхәррир: Татьяна Николаевна Вафина,
vafina@tatmedia.com
Шеф-редактор: Әскәр Сабиров,
sabirov@tatmedia.com
Баш мөхәррир урынбасарлары:
Нияз Әхмәдуллин, ahmadullin@tatmedia.com
Алсу Троицкая
Чыгарылыш мөхәррире:
Фәридә Әхмәтҗанова
Бүлек мөхәррирләре:
Ольга Туманская, Олеся Бондаревская,
Руфия Фазлыева
Әдәби мөхәррир: Луиза Янсуар
Авторлар: Ксения Семина, Фаяз Хуҗин
Фотографлар: Ната Смирнова, Александр Эшкинин
Дизайн-макет: Леонид Гобәйдуллин
Вёрстка: Игорь Глушков, Леонид Гобәйдуллин,
Препресс: Игорь Глушков
Корректор: Айсылу Корманова
Офис-менеджер: Диана Сиражиева

Журнал 1920 елдан нәшер ителә

1979 елда Халыклар дуслыгы
ордены белән бүләкләнә

Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр
һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә
күзәтчелек буенча федераль хезмәттә теркәлгән.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС 77 – 66045, 10.06.2016.

Тираж: 3500 дана,
шул исәптән татар телендә – 1000.

Бәясе ирекле

Редакциянең язма рөхсәтеннән башка «Татарстан»
журналындагы материалларны күчереп бастыру тыела.
Күчереп бастырганда, журналның исемен күрсәтү
мәҗбүри. Автор фикере редакция фикере белән туры
килмәскә мөмкин. Реклама материалларының эчтәлеге
өчен редакция җавап бирми. «Промо» һәм «Медиа»
рубрикалары материаллары реклама-коммерция
нигезендә басыла.

Журнал «Татмедиа» АҖ филиалы «Идел-Пресс»
полиграфия-нәшрият комплексы типографиясендә
басылды: 420066, Казан, Декабристлар ур., 2

Заказ № А-574

Басарга кул куелды: 21.03.2017

Дистрибуция һәм трафик бүлеге җитәкчесе:
Миләүшә Байрашева,
milyaushanb@tatmedia.com
Коммерция директоры:
Нина Әхмәтшина, nivlana@tatmedia.com,
тел. (843) 222-09-76
Сату бүлеге белгече:
Гөлфия Фәттахова
Махсус проектлар бүлеге белгече:
Жәмилә Әхмәтшина, ahleva5@mail.ru
Бухгалтерия:
Ольга Басаркина, тел. (843) 222-09-80

ЯЗ ДИГӘН УТРАУДА...

Инде ничәмә-ничә миллион тапкыр яз җирдәге бар тереклеккә өмет бирә. Яңарышка, исәнлеккә, бәхеткә һәм мәхәббәткә өмет... Бу юлы да ул үз кагыйдәләреннән тайпылмады: берәүдән дә җавап көтмичә, һәр җан иясенә толым-толым җылысын, назын өләште.

Тукта әле, ә безнең соң бурычыбыз нинди? Яшебезгә, җенесебезгә, дан-дәрәҗәбезгә бәйсез рәвештә бирелә торган бу бәһасез бүләкне алгач та, аның кыйммәте турында уйланырга кирәктер бит, мөгаен. Әмма көндәлек ыгы-зыгыда бәяләп тору гына түгел, ә бу бүләкнең безгә бөтенләй бушка бирелгәнен ваемлап өлгерү дә – мөмкин эш түгел диярлек. Гардеробны яңартасы, туннарны ераграк яшерәсе, туфлиләрне барлап-әзерләп куясы бар, һәм – башы-азагы булмастай тоелган мәшәкатьләр артыннан чабасы да чабасы. Йә, нәрсә әйтеп була инде бу урында?! Кушаяклап чабып баручы XXI гасыр, шулай итеп, үтә гадәти булган фасыллар алышыну күренешенә әллә ни игътибар юнәлтеп торырга өндәми.

Әгәр сез, вакыт диктаторларына буйсынмыйча, алай да күз читегез белән генә язны күреп алгансыз икән, – туктап торыгыз, аның нәни генә бер кыйпылчыгын күңелегезгә сеңдерергә тырышыгыз, һәм ул сезнең белән җәйгә кадәр барыр. Әйе, әйе, үзенең җай гына агышында барлык матурлыкны чагылдырып: монда мартның умырзаялары да булмый калмас, аннан инде күңелегезгә кереп урнашкан ул язгы утраучыкта шаулап май сиреньнәре чәчәк ата башлар.

Шундый ул – җанны яңарту һәм сихәтләү көченә ия. Юкка гына яратабызмыни без аны?!

СЕЗНЕҢ РЕДАКЦИЯГЕЗ

Редакция советы:
АЛАЕВ Юрий Прокопьевич
АЛЕКСАНДРОВСКАЯ Ирина Алексеевна
ӘХМӘТШИН Равил Кәлимуллович
БЕЛЯКОВ Роман Юрьевич
БИКЧӘНТӘЕВ Фәрит Рәфкатович
БОЛЬШАКОВ Андрей Георгиевич
ВӘЛИЕВА Зилә Рәхимҗановна
ГАЛИЕВ Марат Гадыевич
СӘЛӘХОВ Мәгъзум Кәлимуллович
ФӘЙЗУЛЛИН Равил Габдрахманович
ХӘКИМОВ Рафаэль Сибгатович
ХОМЕНКО Вадим Васильевич

татмедиа

Гамәлгә куючы:
«Татмедиа» АҖ
Нәшер итүче:
«Татмедиа» АҖ

420097, Казан,
Академическая ур., 2

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла

«Татарстан» журналына язылу барлык элемтә бүлекләрендә кабул ителә
Индекс **П2381** – татар телендә
Индекс **П2378** – рус телендә

Ярты елга язылу бәясе:
864 сум 24 тиен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ КАРТИНАЛАР ГАЛЕРЕЯСЫ

Рассам: Е. Канев. 2017 ел.

МАРТ. КАЗАН.

ЭЧТӘЛЕК

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

4. Җәмәгать урыннары елы.
Татарстан ишегалларының киләчәге нинди?

14. Төп пассажир канатлары.
Президентлар өчен ВИП-самолетлар ничек эшләнә

22. WorldSkills талантлар эзли.
3D-проектны ничек итеп 2D-сызымга әйләндерергә

26. Мәҗбүри медицина иминияте.
Ул безгә нәрсәләр бирә

32. Бакый Урманче.
Бөек шәхесне якташлары ничек хәтерли

38. Шәһәр һәм олы тарих.
Менделеев, Пастернак һәм Збарский Татарстанның кайсы төбәгендә «очрашкан»

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

44. Ризидә Хәсәновадан бәйрәм табыны.
Катлы бәлеш ничек әзерләнә

50. Хатын-кыз бәхете нәрсәдә.
Татарстанның төп хатын-кызлары фикере

62. «Татарстан»ның алтын запасы.
Давыллы туксанынчы еллар мизгелләре

66. Тормыш мәктәбе.
Ренат Ибраһимов нинди «сериал» төшерә

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

70. Тарих битләре.
Кубрат хан хәзинәсе

76. Төп бүләк – китап бастыру.
«Татарстан» журналының әдәби премиясен дәгъва итүче әсәр

80. Китап киштәсе.
Без нәрсәләрне хәтердә сакларга тиеш

84. Татар авыллары.
Чыршы авылында ничә чыршы бар

88. Татарстан риваятьләре.
«Свияжск әкиятләрен» кем язып алган

Тулырак мәгълүмат түбәндәге сайтта:
www.protatarstan.ru

PRESSA.RU

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

26.02

Аида Гарифуллина, Вена дәүләт операсы солисткасы, Татарстанның атказанган артисткасы, – Әлмәттәге сольный концертыннан соң:

– Мин үз республикамны зур горурлык белән тәкъдим итәм, һәм бу бик тә яхшы! Безнең музыка шундый матур! Әле күптән түгел генә Decca Classics чыгарган дебют альбомымда татарча җыр башкардым, һәм Европада барысының да исе китте. Алар аны бонус-трек дип атадылар, һәм бу әйбәт билге. Мин татар музыкасын дөнья күләмендә яңгыратырга кирәк, дип саныйм.

ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

16.02

Анн Идальго, Париж мэры, – Казанга эш сәфәрен тәмамлаганда:

– Мин бәхетле, хисләрем ташый. Казаннан киләчәктә бергәләп хезмәттәшлек итү өчен күпсанлы идеяләр белән китәм. Үзе өчен сезнең шәһәрне ачкан һәм аңа гашыйк булган беренче Париж мэры булуыма шатмын, һәм моның белән горурланам.

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

28.02

Евгения Петровна Сафонова, Кама Тамагында яшәүче әбекәй, – 100 яше тулган көндә:

– Җәй якынлаша. Җиң сызганып эшләр вакыт…

АКЫЛЛЫ ГАМӘЛЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Татарстан ишегалларын **НИНДИ** киләчәк көтә

Президентлар өчен ВИП-самолетларны **КАЙДА** ясаганнар

3D-проектны **НИЧЕК** 2D-сызымга әйләндерергә

Медицина иминияте **НӘРСӘ** бирә

Бакый Урманчены якташлары **НИЧЕК** хәтерли

КАЙСЫ шәһәр Бондюг заводыннан үсеп чыккан

PRESSA.RU

БЕЗ ЮГАЛТАЧАК **ИШЕГАЛДЫ?**

Җәмәгать урыннары елында «Татарстан» зур һәм кечкенә шәһәрләрнең ишегалларын йөреп, карап чыкты. Безнең материал – ике классик сорауга җавап түгел, ә бәлки безнең бүгенге көн ишегалдының нинди булуын, һәм аның киләчәге бармы-юкмы икәнлеген ачыкларга теләү ул.

Фото: Ната Смирнова

Автор:
Ксения Сёмина

PRESSA.RU

ГАЛОШ КАРАКЛАРЫ ЗАМАНЫ ҮТТЕ

Өч катлы йортның якты фасады кышкы Мамадыш пейзажы фонында якты бер утрау булып балкып тора. Февральдә шәһәр кар көртләренә чумып утыра әле, әмма без Горький урамындагы 33/12 Б номерлы йортка бер каршылыксыз, җыйнак итеп чистартылган юллардан узабыз. Өч подъездның һәркайсында – белдерү тактасы.

Безне җирле активистлар төркеме каршы ала. Без якынлашканда хатын-кызлар үз араларындагы яшь кенә бер ир кеше белән нәрсә турындадыр кызып-кызып сөйләшәләр иде. Танышабыз. Ир заты үзен «Мамадыш районы һәм Мамадыш шәһәре идарәче компаниясе»нең директоры Нияз Мөхәммәтханов дип таныштыра. Аның ишегалдындагылар белән гап-гади итеп аралашуына гаҗәпләнәм.

– Без бит монда барыбыз да бер-беребезне беләбез, шәһәребез зур түгел, – ди 33/12 Б номерлы йорт буенча җаваплы Лариса Яковлева.

Мин аңардан мәйданны яхшырту һәм парковка мәсьәләсенең торышы хакында сөйләвен үтенәм.

– Матуррак вакытта килмәдегез, хәзер кар ята бит. Ә җәй көне безнең бар җирдә чәчәкләр үсә. Һәр подъезд янынннан су чыгарылган, исәпләү приборы буенча түлибез. Менә балалар мәйданчыгы, без аңа ел саен үз көчебез белән ремонт ясыйбыз, – ди Лариса Александровна.

Хәзер шәһәрне уңайлырак итү буенча күпчелек мәсьәләләр территориаль үзидарә органнарының (ТҮО) актив катнашлыгында хәл ителә. Кешеләр тәкъдимнәре яисә үтенечләре белән үзидарә вәкилләренә мөрәҗәгать итә, ә алар, үз чиратында, ИК белән хезмәттәшлек итә. Мәсәлән, әлеге һәм тагын ике күрше йорт активы тарафыннан оештырылган бу ТҮО «Елның иң яхшы территориаль үзидарә органы» республика конкурсында откан грант акчаларына җәй көне балалар уен мәйданчыгына яңа элементлар урнаштырырга җыена. Шулай ук монда яшәүчеләр үзләре «Ишегалды көне», «Күрше бәйрәме», «Май чабу», Шәһәр көне, Яңа ел бәйрәмнәре кебек тантаналы чаралар уздыралар.

– ИК безгә теләсә нинди эштә булыша. Соңгы сигез елда йортта ике тапкыр капремонт үткәрелде. Район башлыгы Анатолий Иванов зур ярдәм күрсәтә, ул ай саен йорт буенча җитәкчеләрне, ТҮО рәисләрен, идарәче компанияләрне, ТКХ хезмәтләре җитәкчеләрен җыеп, бөтен проблемалы мәсьәләләрне тикшерүне оештыра, – дип сөйли Лариса Александровна. – Моннан тыш, ул ел саен кешеләр белән очраша. Һәр ишегалдын йөреп чыга. Барлык мөрәҗәгатьләр беркетмәгә теркәлә, аннары шәһәр коммуналь хезмәтләренә һәм оешмаларына конкрет күрсәтмәләр бирелә. Икенче тапкыр җыелганда, башлык, бу беркетмәгә кире кайтып, эшнең ничек башкарылуын тикшерә.

Мамадышта тагын халык почтасы да эшли. Ай саен шикаятьле һәм тәкъдимле юлламалар башлыкка тапшырыла. Җавап тиз арада бирелә, диләр. Шулай ук аның башлангычы белән шәһәрдә һәм районда ишегалларын һәм җәмәгать киңлекләрен яхшырту буенча төрле проектлар тормышка ашырылып тора. Ишегалларын һәм җәмәгать биналарын чәчәкләр белән һәм Яңа елга бизәү буенча даими рәвештә конкурслар үткәрелә. Быел Анатолий Иванов кабул иткән программа буенча ишегалларына асфальт җәеләчәк. Ремонт өчен иң начар хәлдә саналган 14 объект билгеләнгән.

– Ә яшьрәк буын вәкилләре йорт һәм ишегалды эшләрендә катнашамы? – дип сорыйм активистлардан.

– Аларның вакыты юк бит, балалары бар, акча эшләргә кирәк, – дип җавап бирәләр апалар. – Бездә күбесенчә урта яшьтәгеләр активлык күрсәтә.

– Һәм хәтта бальзак яшендәгеләр дә! – дип өсти Нияз Яһүдевич башкаларны көлдереп.

Биредә һәрвакыт шулай җылы традицияләр, мөнәсәбәтләр, тәртип булганмы-юкмы икәнлеге белән кызыксынам.

– Әлбәттә, һәрвакытта да түгел. Әле 15 ел элек кенә биредә сыерлар йөри, тездән пычрак иде. Эшкә барып җитсәң, чәчне тузаннан аралап булмый иде, – ди Лариса Александровна. – Күрәсезме, паласлар эленеп тора? Алар ай буе да торырга мөмкин. Ә элек шундый вакытлар да булды: подъездда резин галошны да калдырып булмый – урлыйлар! Хәзер, шөкер, барысы да – күңелләр дә, ишекләр дә ачык.

Шәһәр җирендә чын-чынлап автомобильнең хакимлек итүен Хөсәен Ямашев проспектындагы 104 нче йорт ишегалдында да күзәтәм.

БАЛАЛАРГА МӘЙДАНЧЫКЛАР ЮК

Үз хезмәтләренең берсен «Машинаның кешене буйсындыруы» дип исемләгәндә, Владимир Ильич бу тезисның якынча йөз елдан соң чын-чынлап тормышка ашасын күз алдына китердеме икән?

Моңа инану өчен, безнең кебек, зур шәһәрнең бер йокы микрорайонына барып чыгу да җитә. Әйтик, Казан шәһәренең Фатих Әмирхан проспектындагы 95 нче йорт ишегалдына кереп карыйк.

– Әйтегез әле, сезнең уен мәйданчыгы кайда? – дип сорыйм кечкенә улы белән урамга чыккан яшь әнидән. Без сөйләшкән арада, малай дүрт подъездлы биек йорт каршындагы тар тротуар буйлап әрле-бирле йөгергәли. Ишегалды юк монда, үтү юлы һәм парковка гына.

– Моннан ике ишегалды аша нәни генә балалар шәһәрчеге һәм шуа торган таулары булган бик матур иркен мәйданчык бар. Шунда йөрибез, – дип җавап бирә әни кеше. Бу йортта яшәүчеләр, хәлне үзгәртү өчен, ни дә булса эшләргә тырышамы-юкмы икәнлеген сорыйм.

– Биредә мәйданчыкны кая сыйдырасың? Һәм нинди акчага? Менә без парковканы үз акчабызга эшләттек. ИК ярдәм итеп тормады, – ди ул дистәләп машинаны сыйдырган киртәләнгән квадратка күрсәтеп. Бу утраучыкка үтеп керү ювелир осталыгы таләп итәдер, мөгаен. Мәйданчык өстендә каен ботаклары моңаеп тирбәлә, юкка чыккан бакчаны сагыналардыр, күрәсең.

Шушында ук миңа очраган әби сөйли: машиналар подъездларга ук терәлеп туктамасын өчен, биредә яшәүчеләр, тротуарны киртләп алып, каршылыклар корган булган икән.





Бу утраучыкка үтеп керү ювелир осталыгы таләп итәдер, мөгаен. Мәйданчык өстендә каен ботаклары моңаеп тирбәлә, юкка чыккан бакчаны сагыналардыр, күрәсең.

Тик аларны чүп җыючы машина изеп үткән дә, машиналар кабат элекке урыннарына кайткан.

Ә күршедәге, Фатих Әмирхан проспектындагы дүрт озын панель йорт (89, 91, 93, 97) уртасында барлыкка килгән квадратны тимер гаражлар тезмәсе икегә бүлә.

– Идарә итүче компания вәкилләре чираттагы хисап җыелышында безгә биредә зур, заманча балалар мәйданчыгы урнаштыруда ярдәм итәргә әзер булуларын, әмма проектны үзебез тәкъдим итәргә тиешлекне әйткәннәр иде. Әмма моның өчен гараж хуҗалары белән килешергә кирәк. Ә җыелышларга бездә, күп дигәндә, халыкның өчтән бере генә йөри. Безгә аны ничек эшләргә инде? – ди мин туктатып сорау биргәч, улын һәм кызын иярткән әни кеше. Аннары ашыга-ашыга алга китә – улы белән кызының тренировкага соңга калуы бар.

Тугыз катлы панель йортлар кирпечтән төзелгән заманчарак яңа йортлар белән керешеп китә. Аларның киртәләп алынган территорияләрендә парковкалар да, балалар мәйданчыклары да, газоннар да бар. Тик монда да проблемалар юк түгел: парковка урыны һәркемгә дә җитми.

Шәһәр җирендә чын-чынлап автомобильнең хакимлек итүен Хөсәен Ямашев проспектындагы 104 нче йорт ишегалдында да күзәтәм. Аның нәкъ уртасында, кайчандыр күләгәле аллея буйлап тротуар сузылган җирдә, хәзер сак астындагы парковка. Ул камералар һәм капкаларны автомат рәвештә ачу-ябу системасы белән тәэмин ителгән. Киртәләнгән урыннан 200 метр арырак 10 машина тора. Һәм күп подъездлы озын йортның бөтен периметры буйлап – тагын 50.

– Бу түләүле парковка, – ди миңа биредә яшәүчеләрнең берсе. – Мин машинамны анда куймыйм. Менә монда куям, тротуар буена.

Сүз уңаеннан, йорттан дистәләп адымда – тагын бер түләүле парковка, 200ләп урынга...

Александр Сидякин,
РФ Дәүләт Думасы депутаты, Дәүләт Думасының Торак сәясәте һәм ТКХ комитеты рәисенең беренче урынбасары.

ИШЕГАЛДЫ УЛ – ҮЗАРА МӨНӘСӘБӘТЛӘР ТЕРРИТОРИЯСЕ

– Бүгенге көндә бик күп сораулар ишегалдында парковкалар оештыру белән бәйле. Баганалар утырту, юлны киңәйтү, «кесә»ләр булдыру – болар барысы да анда яшәүчеләрнең гомуми җыелышында хәл ителергә тиеш. Минемчә, «шлагбаумлаштыру» – хәлдән чыгу юлы түгел. Яшәүчеләр арасында киртәләп алынган ишегалды эчендә үк парковка урыннарын бүлгәләү кебек үк. Күптән түгел РФ Югары суды бу мәсьәлә буенча каршы чыкты. Моннан тыш, йорт яны территориясе (аны ызанлау милекчеләргә карый) һәм гомуми файдалану территориясе (муниципалитетка карый) дигән төшенчәләр бар. Димәк, якларның берсе дә чит территория белән милекче рөхсәтеннән башка файдалана алмый. Ни кызганыч, бездә ИК һәм яшәүчеләр арасында диалог юк диярлек. Әмма күпфатирлы йортлар советы булдырылган урыннарда прогресс күзәтелә. Казанның «Уютный дом» ИК һәм Мәскәү районы ИК идарәләрендә – 500дән артык йорт, һәм торак милекчеләре тырышлыгы белән йорт яны территорияләренең күбесе балалар мәйданчыклары, клумбалар һәм тренажёрлар h.б. белән тәэмин ителгән. Хәлнең яхшы якка үзгәрүен күрсәтүче мисаллар бар. Мәсәлән, Фатих Әмирхан проспектындагы 77 нче йорт янында. Гадәти типик «тартма» рәвешле төзелеш ул, әмма биредә ишегалды спорты зонасы да, балалар мәйданчыгы да, яшь агачлар да бер-берсе белән уңышлы сыешкан.

Тимур Кадыйров,
Казан шәһәренең баш архитекторы урынбасары

ИШЕГАЛДЫ УЛ – МӨМКИНЛЕК

– Хәзерге вакытта Казан шәһәренең 2018–2035–2040 елларга яңа Генераль планын эшләү бара. Компактлылык төшенчәсе анда да уңайлы тормыш булдыру коралларының берсенә әверелә. Моннан тыш, шәһәр төзелешен проектлауның яңа нормативларында шундый принциплар бар – алар шәһәр яны территорияләрен файдалану планында төзүчеләрнең мөмкинлекләрен киңәйтә, «машиналарсыз ишегалды» концепциясен актив кулланырга мөмкинлек бирә. Мәсәлән, йорттан беркадәр ераклыкта күпкатлы парковкалар төзү яки парковка мәйданнарын оештыру мөмкин булачак. Төрле сценарийлар исәпкә алына, мәсәлән, йортта яшәүче кеше, машинасы куркынычсыз урында һәм беркемгә дә комачауламый икәнен белгән хәлдә, 500–600 метр араны өенә җәяү кайта ала. Әгәр дә ул кунак икән, аның өчен якынрак территориядә вакытлы паркинг табарга була. Монда закон кырында зур эшләр көтелә әле. Әмма, ничек булса да, җәмәгать урыннарын оештыруга мөнәсәбәт кардиналь рәвештә үзгәрә. Һәм бу инде тормышка ашырылган проектлардан да сизелеп тора. Парин урамындагы сквер – яхшы мисалларның берсе. Элек бу сквер, кешеләрне җәлеп итүдән битәр, куркытып тора иде. Әмма янәшәдәге йортта яшәүчеләр мохитны «гуманлаштырырга» тырыштылар – тирә-ягын яхшырттылар, анда чәчәкләр һәм хәтта яшелчәләргә кадәр үстерделәр! Бу тәҗрибә проектчылар тарафыннан өйрәнелеп, бүгенге парк концепциясенең бер өлешен тәшкил итте, һәм паркларның искиткеч рекреация һәм транзит зоналарына әверелүенә булышты. Бу проект – район корылмаларының бер карашка үле тоелган территорияләре белән ничек нәтиҗәле эшләп булуын күрсәтүче мисал. Мондый территорияләрнең төгәл чикләре юк һәм шуңа күрә проектчыларны аеруча кызыксындыра. Тиешенчә якын килгәндә, монда һәр социаль төркем вәкиленә конструктив эшчәнлек мөмкинлеге бирә торган күпфункцияле мәйдан булдырырга мөмкин. Ягъни яхшы ишегалдын начарыннан аерып торучы тормыш үзе инде ул.

Айрат Баһаутдинов,
инженер, «Мәскәү – инженер карашыннан», «Казан – инженер карашыннан» дигән туган якны өйрәнү проектлары авторы

ИШЕГАЛДЫ УЛ – ҖАВАПЛЫЛЫК ЗОНАСЫ

– Минемчә, киләчәк ишегалды ул – уңайлыклар булдыру гына түгел, кешеләрнең аңа мөнәсәбәте дә. Якын-тирә йортларда яшәүчеләр аның шәһәргә караган абстракт киңлек кенә түгел, үз йортларының бер өлеше, үзләренең җаваплылык зонасы икәнен аңлагач кына, гадәти ишегалды киләчәк ишегалдына әвереләчәк. Алар аны үзләре балалар белән йөрү, кешеләр белән аралашу, күләгәдә тынычлап ял итү, этләрен йөртү өчен уңайлы итәргә тиеш. Алар ишегалдында тәртип һәм чисталык саклануын күзәтергә тиеш. Минемчә, киләчәк ишегалды – күптән онытылган үткән еллар ишегалды ул. Автомобильләрдән арындырылган, тынычлап ял итү өчен ачыграк булган. Анда агач-куаклар, чәчәкләр утыртылган, эскәмияләр куелган. Уен мәйданчыклары, футбол тартмалары һәм шугалаклар, чайканырлык бассейннар бар. Хәзер бит бездә күбесенчә – ташландык үле территорияләр. Аларны үзгәртүдә кешеләр үзләре дә катнашса, ничек яхшы булыр иде. Шул чакта гына аларда, мин алда телгә алганча, үзләренең дә катнашы булу хисе туачак.

Анна Сиприкова,
«Җәмәгать мәйданнары өчен проект»ның (Нью-Йорк) әйдәп баручы консультанты, «Шәһәр кешеләре эшләгән» (Россия) проекты кураторы

ИШЕГАЛДЫ УЛ – ФУНКЦИЯ

– Бер караганда, урта сыйныфлар өчен торак проектлаучы архитекторлар ишегалларын индивидуальләштерергә омтыла – кешеләргә үз яшел почмагы тәкъдим ителә, мәсәлән, Ослодагы – Sorenga block 6 («Соренга блок 6») проектындагы яисә Нью Йорктагы – Jenga tower by herzog and de meuron («Башня Дженга», архитекторлары Херцог һәм Де Мерон) проектындагы кебек. Икенче яктан караганда, уңайлы типик төзелешләрдә балалар мәйданчыгын, спорт корылмаларын сыйдырган гомуми ишегалды булачак, ә беренче катларда күршеләр үзәкләре барлыкка киләчәк, алар ишегалдын – гомуми бәйрәмнәр яки йога белән шөгыльләнү өчен – актив кулланачак. Мондый үзгәрешләр яңа районнарда тизрәк үтеп керәчәк, яңа төзелешләрнең онлайн-форумнары раслаганча, алар эшләнә дә инде. Иске ишегалларында барысы да төрлечә булыр, әмма һәр ишегалдында күршеләрне туплаучы һәм ишегалдын көннән-көн яхшырта баручы энтузиаст табылыр дип ышанасы килә. Һәм, әлбәттә, мин җәмәгать транспортының көйләнүе һәм sharing-economy (милек иясе – бу очракта, автомобиль иясе – булу урынына гомуми файдалану, аренда һәм бартер икътисады) безнең ишегалларын парковка өчен сугышудан азат итәр, дип өметләнәм.

PRESSA.RU

ЯНӘШӘБЕЗДӘГЕЛӘР ҺӘМ ЯКЫНДАГЫЛАР ТУРЫНДА

ТАТАРСТАН

ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ БАСМА

1 февральдән 31 мартка кадәр 2017 елның II яртыеллыгына
«Татарстан» журналына алдан язылу игълан ителә

Реклама 16+

Индекс:
П 2378 **рус телендә**
864 сум 24 тиен

Индекс:
П 2381 **татар телендә**
864 сум 24 тиен

ТАБИГАТЬ БЕЛӘН ГАРМОНИЯДӘ

Президент Владимир Путин Указы белән 2017 ел Россиядә Экология елы дип игълан ителде. Әйләнә-тирә мохиткә игътибар артканнан-арта бара. Башкалар көнләшерлек үсеш темпларына ия Татарстан өчен мондый игътибарның сәбәпләре аңлашыла. Республика халкы өчен табигатьне кайгырту буш сүз генә түгел. Татарстан ел саен җир астыннан миллионлаган тонна нефть чыгара, биредә бик куәтле нефть-газ химиясе комплексы һәм дистәләрчә эре машина төзү предприятиесе эшли. Шуңа ярашлы рәвештә, өстенлекле бурычларның берсе – икътисадның экологияне саклауга юнәлтелгән үсешен тәэмин итү.

Һәм әлеге бурыч уңышлы хәл ителә дә. Татарстанның иң эре предприятиеләре социаль һәм экологик җаваплы компанияләр абруеның кадерен белә һәм үзләренең эшчәнлекләрендә экологик идарәнең заманча принципларын файдалана, табигатьне саклауның алдынгы технологияләрен актив куллана. Масштаблы экологик программаларны гамәлгә кертү, табигатьне саклау өлкәсендә катгый халыкара стандартларга җавап бирү – республиканың әйдәп баручы предприятиеләренең көндәшлекле өстенлегенең мөһим өлешләре. Һәм моңа иң яхшы дәлил – читтән бирелгән уңай бәя. Табигатьне саклау министрлыгының экологик рейтингыннан күренгәнчә, Татарстан Республикасы башкаласы Россиянең иң яхшы ун шәһәре исемлегенә керә. Республикада балалар туу да, уртача гомер озынлыгы да арта.

PRESSA.RU

«Алойл» ЯАҖ активында – табигать ресурсларыннан дөрес файдалануның 20 еллык тәҗрибәсе

ЭКОЛОГИЯ ПРИЗМАСЫ АША КАРАГАНДА НЕФТЬ ЧЫГАРУ

Нефть чыгару тармагының киләчәген экологик технологияләр куллланудан башка күзаллап та булмый. «Алойл» ЯАҖнең әлеге тармакта 20 еллык тәҗрибәсе бар. Мөһим нәтиҗәләр арасында – атмосфера һавасын саклау чараларын уңышлы куллану һәм аны пычрата торган матдәләр чыгаруны киметү.

Беренче 26 компаниянең берсе булган «Алойл» ЯАҖ нефть компаниясе 1997 елда ТР Президентының УП-81 санлы Указы нигезендә оештырыла. Компания эшчәнлегенең төп төре – РФнең ике субъекты территориясендә – ТРның Баулы районы һәм Оренбург өлкәсенең Төньяк районы чикләрендә урнашкан лицензияле Алексеевск нефть чыганагын эшкәртү һәм геологик өйрәнү.

«Алойл» ЯАҖ 20 ел эшләү дәверендә нефть чыгарганда табигый ресурсларны саклауның нәтиҗәле ысулларын тапкан. Атмосфера һавасын саклау өлкәсендәге иң әһәмиятле чараларның берсе – иярчен нефть газын (ПНГ) утильләштерү. РФ законнарына ярашлы рәвештә, «Алойл» ЯАҖндә иярчен нефть газын утильләштерү программасы эшләнгән һәм 2007 елдан бирле гамәлгә кертелә. Алексеевск нефть чыганагында факелларны бетерү һәм газүткәргечләр төзү эше башлана. 2009 елда озынлыгы 12,4 километрлы ДНС-1 – ДНС-10 газүткәргече файдалануга тапшырыла, шулай ук ДНС-1дә (Алексеевка авылы) компрессор җайланмасы эшли башлый, ул нефть чыгаруны арттырыр өчен нефтьле катламнарга иярчен газны кертү микъдарын 5 тапкырга арттыру максатында куела.

Газүткәргечләр төзү эше 2010–2011 елларда да дәвам итә, ул чакта ДНС-260 тан озынлыгы 14,8 километрлы һәм ДНС-461 дән озынлыгы 13,2 километрлы тагын ике газүткәргеч файдалануга тапшырыла. Шулай ук алда аталган программа кысаларында 2012 елда нефтьне әзерләү җайланмасында нефть җылыткычлар (УПН) файдалануга тапшырыла.

Әлеге чаралар елына 10 миллион кубометр иярчен нефть газын утильләштерү һәм «Алойл» ЯАҖ объектларындагы барлык факел җайланмаларын сүндерү мөмкинлеген бирә. Бүген компания иярчен нефть газын 100 процентка файдалана һәм утильләштерә. Хәзерге вакытта компания иярчен газны катламга кертүдә куллана. Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: «Востокнефтегазтехнология» ҖЧҖ проектына ярашлы рәвештә, «Алойл» ЯАҖ Алексеевск нефть чыганагындагы катламга су-газ катнашмасы составында иярчен нефть газын кертү технологиясен инде җиде ел буе уңышлы файдалана.

Шул ук вакытта «Алойл» ЯАҖндә һаваны пычрата торган матдәләр чыгаруны киметү буенча да зур эш алып барыла. Моның нәтиҗәле ысулларыннан берсе – компания объектларында углеводородларның җиңел фракцияләрен тотып калу (УУЛФ) системасын кертү. 2014 елда шундый ике система урнаштырылган. Алар кыйбатлы углеводород чималын югалтудан саклый, сепарациянең соңгы баскычларында һәм резервуарларның сулыш клапаннарыннан газ чыгаруны булдырмый. Әлеге система объектларның янгында шартлау куркынычын киметә, атмосфера һавасының нефть саклау резервуарларына керүен булдырмый, бу исә резервуарларның хезмәт срогын арттыра, чөнки коррозия процессы акрынрак бара. Тотып калынган углеводород газы, иярчен нефть газы кебек үк, «Татнефтегазпереработка» газ эшкәртү заводына җибәрелә, шулай ук нефть җылыткыч җайланмаларны җылытуда файдаланыла.

Химреагентларны агызу өчен «Алойл» ЯАҖ махсус җайланмалар куллана, алар скважиналардагы газны атмосфера һавасына кушылудан саклый.

Предприятие эшчәнлеге зонасында атмосфера һавасы, туфрак, җир өсте һәм җир асты суларының чисталыгы даими контрольдә тотыла. Туфракны һәм җир өсте-җир асты суларын пычранудан саклау өчен, скважиналар янындагы мәйданчыклар түшәкләндерелә, технологик җиһазлар дренажы һәм скважина янындагы поддоннардан җыелган сыекчалар дренаж савытларына җыела.

«Алойл» ЯАҖ хезмәткәрләре яхшы аңлый: җир ресурсларын саклау проблемасын хәл иткәндә нефть промыселлары объектлары төзелешенә авыл хуҗалыгы җирләрен бирүне максималь кыскарту, шулай ук пычратылган җирләрнең уңдырышлылыгын торгызу беренче чираттагы бурыч булып тора.

«Алойл» ЯАҖндә коррозиягә каршы көрәшнең нәтиҗәле ысулларын булдыруга юнәлтелгән чаралар комплексы гамәлгә кертелә: торбаүткәргечләрне ингибитор саклау, протектор саклау, шулай ук эчке коррозиягә каршы катлам белән капланган, тышы исә полиэтилен белән изоляцияләнгән торбаүткәргечләр төзү. Нәтиҗәдә нефть промыселларындагы торбаүткәргечләрнең ышанычлылыгы проблемасы хәл ителә, аларның ремонтсыз эшләү чоры озыная, бу исә, үз чиратында, икътисадый күрсәткечләрдә, сәнәгать һәм экология куркынычсызлыгы халәтендә уңай чагыла.

«Алойл» ЯАҖ – ТР ның 450 компаниясе арасында үткәрелгән «Эколидер» республика конкурсының 2009 һәм 2015 еллардагы «Пычратуларны киметү буенча эш» һәм «Нефть чыгару һәм нефть химиясе сәнәгате» номинацияләре лауреаты.

ЗАО «АЛОЙЛ»

тел: (85569) 5-62-27

факс: (85569) 5-62-27

e-mail: aloil116@mail.ru

Реклама

«ЧЕЛНЫВОДОКАНАЛ»: ИННОВАЦИЯЛӘР ЮЛЫННАН

Су белән тәэмин итү һәм кулланган суны түгү системасының өзлексез эшләве – шәһәр хуҗалыгының нормаль эшчәнлеге өчен зарури шарт. Чаллыда әлеге бурычны «Челныводоканал» ҖЧҖ уңышлы башкарып килә.

«КАМАЗ» ГАҖнең бүлендек предприятиесе – «Челныводоканал» ҖЧҖ – уңышлы һәм тотрыклы, югары профессиональ коллективы һәм грамоталы менеджменты булган, Россиядә һәм Татарстан Республикасында әйдәп баручы һәм аеруча нәтиҗәле эшләүче ТКХ предприятиеләренең берсе. Эш нәтиҗәләре генә түгел, сыйфат буенча да күп кенә Россия һәм республика конкурслары дипломнары предприятиенең уңышлы эшләвенә ачык дәлил булып тора. 2016 елда компаниянең генераль директоры Кирилл Пузырьков «Ел җитәкчесе-2016» республика бәйгесендә «Яңа җитештерү булдырган өчен» номинациясендә җиңү яулады.

К. Пузырьковка «Ел җитәкчесе – 2016» дипломын ТР Президенты Р. Миңнеханов тапшыра.

«Челныводоканал» предприятиесенең кулланучыларга күрсәткән хезмәтләр төре шактый киң – «КАМАЗ» ГАҖ объектларын эчәргә яраклы, җитештерү өчен кирәкле, әйләнештәге, кабат куллану ла торган су белән тәэмин итү, хуҗалык-көнкүреш, сәнәгать, шлам һәм аеруча пычрак юынтык суларны кабул итү һәм чистарту, химик суларны чистарту. Болар белән беррәттән, «Челныводоканал» 500 меңнән артыграк кеше яшәгән Чаллы шәһәренә хезмәт күрсәтә, аның су белән тәэмин итү һәм кулланган суны түгү челтәрләреннән файдалана.

Компания җитәкчелегенең төптән уйланган җитештерү һәм икътисадый сәясәте нәтиҗәсендә предприятиедә кулланучыларга су бирү һәм юынтык суларны түгүнең ышанычлы һәм өзлексез эшли торган системасы булдырылган.

Биредә төп эш принцибы – проблемалар килеп чыгуын көтү һәм аларны аннары хәл итү түгел, бәлки нәтиҗәләрне яхшыртуга омтылу һәм кисәтү чараларын күрү.

Чаллыда эчәргә яраклы суның сыйфаты югары, тәме тәмле, ул норматив таләпләргә җавап бирә. Челтәргә кертер алдыннан су ультрашәмәхә нурлар белән эшкәртелә. Сүз уңаеннан, «Челныводоканал» – республикада эчәргә яраклы суны чистартуга УШ-йогышсызландыру технологиясе кертелгән беренче предприятие.

2015 елдан «Челныводоканал»да аш тозыннан электролиз ысулы белән реагент – натрий гипохлориты җитештерәләр, ул хлор урынына кулланыла. Йогышсызландыру эффекты хлор тәэсиренә тәңгәл – авыру тудыручы бактерияләр юкка чыгарыла. Натрий гипохлоритының өстенлеге шунда: ул персонал өчен дә, кулланучылар өчен дә куркынычсыз.

Йогышсызландыруның химик (натрий гипохлориты) һәм физик (УШ) методларын бергә куллану Чаллы шәһәрен эпидемиологик куркынычсыз су белән тәэмин итү мөмкинлеген бирә.

2016 елда, эчәргә яраклы судагы органик матдәләрдән котылу һәм төрле тәм-исләрне киметү өчен, күмер белән чистарту станциясе файдалануга тапшырылган. Суны күмер пульпасы белән кыска вакытта – язгы ташу һәм җәйге яшелләнү вакытларында гына эшкәртәләр.

«Челныводоканал»да юынтык су торбаларын чистартуга да бик җаваплы карыйлар. 2014 елда, республикада беренчеләрдән булып, чистартылган суларны ультрашәмәхә нурлар белән йогышсызландыра башлаганнар. Әлеге экологик проект нәтиҗәсендә хлор куллану һәм саклау белән бәйле хәвефләр юкка чыга, су объекты хлорлы органик кушылмалар белән пычранудан туктый.

Юынтык суларны чистартуның сыйфатын яхшырту өчен аэротенкларны этаплап реконструкцияләү бара, ул 2019 елда төгәлләнәчәк. 2016 елда эшләтеп җибәрелгән актив ләмнең артыгын куерту узелы ләм карталарына чыгарыла торган утырмаларның күләмен киметү мөмкинлеген бирәчәк.

Су белән тәэмин итү һәм кулланган суны түгү булгеч челтәреннән «Челныводоканал» 2001 елдан бирле файдалана. Инде ул чакта ук ачык күренә: торбаларны тәртипкә китермичә генә шәһәр халкын сыйфатлы су белән тәэмин итеп булмаячак. Предприятиедә катлаулы, әмма бик җаваплы бурыч куялар: шәһәрнең барлык суүткәргечләр челтәрен яңарту зарур. Траншеясыз технологияләр куллану нәтиҗәсендә бүген шәһәр суүткәргеченең 62 проценты нормативларга туры килә.

Суүткәргечләр хуҗалыгын план буенча яңарту стратегиясе үзенең нәтиҗәлелеген раслый. 2016 ел нәтиҗәләре буенча, суүткәргечләр челтәрендә аварияләрнең чагыштырма саны – 1 километрга 0,27, канализациядәге тыгылулар саны – 1 километрга 2,59, күчергәндә эчәргә яраклы суның югалу өлеше 6,75 процентка тәңгәл.

Менә шуңа күрә «Челныводоканал» кулланучылары сыйфатлы һәм зыянсыз су белән тәэмин ителә, аны хәтта, кайнатмыйча, краннан агызып та эчәргә ярый.

Йомгаклап, тагын бер мөһим ремарка. Җитештерү һәм технологик объектларны яңарту буенча барлык чараларны «Челныводоканал» үз акчасына үткәрә. Шактый эш подрядчы оешмаларны җәлеп итмичә, үз бүлекчәләре көче белән башкарыла. Бу яхшырак, сыйфатлырак һәм арзанрак.

Реклама

PRESSA.RU

ТӨП ПАССАЖИР КӘНӘФИЕ

Автор:
Әскәр Сабиров

Җитмешенче еллар уртасы. Эшкә чакыру турында игъланнар шәһәр тулы: «Эшкә чакырабыз, эшкә чакырабыз...» Ә миңа иң ошаганы менә монысы: «Самолетның эчен бизәү өчен кызыл агач осталарын эшкә чакырабыз. 300 сум оклад, премия...». Салоны кызыл агач белән белән бизәләчәк самолет нинди икән ул – монысы зур сер. Әмма Казанда ялкауның гына ишеткәне юк иде: генераль секретарьлар һәм президентлар өчен ВИП-самолетларны бездә җыялар.

Казан авиация заводында КПСС ҮК генераль секретаре өчен №1 нче номерлы Борт, һәм шулай ук ГДР, Куба, КХДР, Ангола һәм СССР белән дус башка илләрнең лидерлары өчен самолетлар җыялар иде. Президентлар өчен эшләнгән кайбер Ил-62М самолетлары, моннан өч-дүрт дистә ел элек җыелган булсалар да, әле хәзер дә дәүләтнең беренче затларын йөртә. 2015 елның февралендә интернетта иптәш Ким Чен Ынның Төньяк Корея башкаласы күгендә очып йөргән сурәтләнгән фотолар пәйда булды. Фотодагы самолет – безнеке, әле совет чорында Казанда җыелган «ильюшин»....

Бүген бу инде бернинди сер түгел. Ләкин без хәзергә кадәр иң кызыклысын белмибез. ВИП-самолет салонын бизәгән кызыл агач осталарына квалификацияле инженерларга түләгәнгә караганда өч мәртәбә күбрәк түләргә әзер булулары турында, мәсәлән. Һәм тагын оча торган апартаментларны бизәгәндә Төп пассажирның зәвыгы ни күләмдә исәпкә алынуы турында.

ВИП-ИНТЕРЬЕР ДОМИНОСЫ

Бервакыт Леонид Ильич Брежнев төн уртасында «президент» самолетының йокы бүлмәсендә уянып

китә дә карават башында гадәттәге бортпроводникны чакыру төймәсен таба алмый. Төймә, әлбәттә, беркая да китмәгән, ләкин генсек инде олы яшьтә булуы сәбәпле, аны бөтенләй башка яктан эзли. Ләкин Төп пассажирның яше – акланыр өчен сәбәп түгел. Мондый «ЧП» дан соң башкалага тиз арада белгечләр чакырыла – «конструктив җитешсезлекләрне» юкка чыгару өчен. Нәтиҗәдә карават янында берьюлы өч чакыру төймәсе урнаштырыла – икесе баш очында, берсе – аяк очында. Теләмәсәң дә – табасың. Өч төймәле әлеге самолет соңрак аның дәвамчысына, алга таба тагын бер генераль секретарьга күчә…

Кадерле Леонид Ильич өчен 1 нче номерлы Бортның беренчесен әле 60 нчы еллар ахырында җыйган булалар. Салонны ул бер күрүдә бик ошаткан, дип сөйлиләр. Брежневның Ил-62 сендә һавада килеш тә дәүләт эшләрен башкару өчен бөтен нәрсә була. Утырышлар өчен иркен конференц-зал. Булышчылар өчен аерым салон. Ишек артында – Төп пассажирның рөхсәтеннән башка беркемгә дә керү рөхсәт ителмәгән эш кабинеты, йокы бүлмәсе һәм персональ бәдрәф. Койрыкта – дөньяның теләсә кайсы ноктасына шалтырату мөмкинлегенә ия элемтә узелы. Барысы да гади, зиннәтлелеккә ым да юк дияргә була. «Дияргә була» – чөнки салон өчен махсус эшләнгән җиһазлар кызыл агач шпоны белән капланган, ә идәндә – натураль келәм. Эш кабинеты стенасында кызыл агач белән бизәлгән СССР гербы урнаштырылган. Тагын әле вакыт пояслары күрсәтелгән сәгать һәм югары сизгерлеккә ия КВ-диапазонлы («дошман тавышын» тыңларга теләгән һәркемнең зур хыялы!) үзебездә эшләнгән приемник та була.

Салондагы җиһазлар, интерьерның бизәлеше – боларның барысын да Казан белгечләре эшли. Төп пассажир теләге буенча вакыт-вакыт салонның эчке ягына үзгәрешләрне дә алар кертә. Леонид Ильич, мәсәлән, салонда ванна бүлмәсе кирәклеген искәртә, гәүдәсенең чандырлыгы белән аерылып тормаган генераль секретарьга озак очышлардан соң су коенып чыгу комачауламагандыр, билгеле. Ләкин конструкторлар аптырап кулларын гына җәяләр: лайнер эченә ванна кертү һәм шул ук вакытта авиация куркынычсызлыгының катгый таләпләрен саклау мөмкин булмый. Дөрес, генсек үпкәләми: юк икән – юк, коенмый да түзәргә мөмкин.

Ул вакытта Ил-62 самолетында шартлар гомумән спартаннарча була. Әйткәнебезчә, шактый саллы гәүдәле Леонид Ильич очыш вакытында артка китә торган, киңлеге 90 см лы караватта ял иткән һәм зарланмаган – сугыш үткән кеше бит, фронтта мондый «комфорт» турында хыялланырга гына булган. Әйләнә торган кәнәфиләр – уңайлы, ләкин гади тукыма белән тарттырылган. Серванттагы рюмкалар – гап-гади пыяладан, хәтта алтын белән дә йөгертелмәгән. Аның каравы, өстәлләр полировкадан ялтырап тора. Хәтта эш кабинетындагы түгәрәге дә: анда Леонид Ильич иптәшләре белән домино уйнарга ярата. Доминодан кырылган өстәл өстен һәрбер очыштан соң диярлек яңартырга туры килгән.

Сүз уңаеннан, әлеге түгәрәк өстәл 1 нче номерлы Бортның интерьерын бизәгәннәрнең кәефе кырылуга да сәбәп булган. Салонны комиссиягә тапшырганда, кабул итүчеләрнең берсе өстәлнең өстен көч белән тартып карый – өстәл әйләнеп каплана. Өстәлне урнаштырган эшче идәнгә беркетелә торган конструкциянең шөребен начаррак борган булган икән. Җаваплыларга эләгә: премиядән колак кагалар, катгый кисәтү дә ясала үзләренә. Ә инде җиһазны моннан соң күз белән генә түгел, көч белән дә тикшерәләр: сакланганны саклармын дигән бит.

КОМАНДАНТЕ СТИЛЕНДӘ

Брежнев очкан ИЛ-62М мирас буенча Михаил Сергеевич Горбачевка күчеп, берничә ай үткәннән соң, Мәскәүдән хәбәр ирешә: тиз арада кием шкафы ясарга! Эш Горбачевта түгел, ә беренче ледида икән. Раиса Максимовна шелтә ясаган: «Туным һәрвакыт бөгәрләнә. «Плечикларга» элгәч, шкафның биеклеге җитми – итәге бөкләнә…» Шкафны яңадан ясыйлар, һәм инде беренче лединың киемнәре моннан соң бернинди дә уңайсызлыклар кичерми…

Әле Горбачев вакытында ук салоннан кунаклар өчен тотылган рюмкалар тезелгән сервант юкка чыга. (Горбачев һәм рюмка – нонсенс!) Иркенәеп калган урында телевизор һәм видеомагнитофон пәйда була – вакыт һәм Төп пассажирның таләпләре үзгәрешләргә китерә. Соңрак, Борис Николаевич заманында, ВИП-салон СССР гербы белән хушлаша – бу инде хәзер Россия Президенты самолеты була.

Һәр лидерның – үз зәвыгы һәм үз таләпләре. Казанда моны башкаларга караганда яхшырак беләләр.

Һәр лидерның – үз зәвыгы һәм үз таләпләре. Казанда моны башкаларга караганда яхшырак беләләр. Эрих Хонеккер өчен самолет ясаганда, ВИП-салонның бөтен компоновкасын үзгәртергә туры килә. ГДР лидеры үз апартаментының башка генераль секретарьларныкы һәм президентларныкы кебек уртада түгел, ә алгы өлештә урнаштырылуын тели. Аның таләбе буенча эш кабинетын зуррак итәләр, ләкин йокы бүлмәсе шактый кечерәя.

Революцион минимализм хас булган Фидель Кастро ИЛ-62 гә заказ биргәндә дә үз принципларыннан тайпылмый. Казанда аңа дип эшләнгән салон – ул күпләгән кечкенә бүлекләр, берсе дә өстенлекле итеп ясалмаган. Кубаның Төп пассажиры самолетында җитәкченең персональ урыны да, йокы бүлмәсе дә булмый. Һәр бүлектә – бары тик өстәл, диван һәм ике кәнәфи. Команданте күңеле тарткан теләсә кайсы бүлеккә урнашып, кунакларны һәм үзен озата йөрүчеләрне шунда чакыра алган. Һәм бизәлештә дә артык нәрсәләр юк – барысы да бик гади, күзгә бәрелми, хаки төсендәге френчы кебек эш өчен тәгаенләнгән.

PRESSA.RU

Ким Чен Ынның Ил-62 самолеты.

КИМ ИР СЕННАН СӘЛАМ

Төньяк Корея лидеры салонын ясаганда Казан белгечләренә озак изаланырга туры килә. Иптәш Ким Ир Сенның таләпләре күрше бөек державадагы партиядәшенә караганда да күпкә җитдирәк булып чыга: әле интерьерның төсе ошамый, әле җиһаз дөрес урнаштырылмаган. Ә безнең белгечләргә иң зур мәшәкать тудырганы КХДР гимны була... Техник биремгә караганда, персональ лайнерда хуҗаны һичшиксез ил гимны сәламләргә тиеш. Һәм ул Корея генералиссимусының аягы ВИП-салон идәненә җәелгән келәмгә тиеп, нәкъ биш секунд үткәннән соң кушылырга тиеш була: нәкъ биш секунд – иртә дә түгел, соң да түгел. Белгечләр карамагында булган техника белән моңа ирешү эш кабинетын кыйммәтле агач белән бизәү белән чагыштырганда шактый авыр булып чыга. Домодедовода әзер салонны тапшыру да тулы бер вакыйгага әверелә. Корея генераллары һәм полковниклары делегациясе әзер салонны берничә атна дәвамында карый һәм тикшерә.

Ләкин иң кызыгы соңрак була. Ким Ир Сенның Ил-62 самолеты очраклы рәвештә тагын Казанга кайта (самолет партиясендә кечкенә генә дефект табыла). Һәм шулвакыт хуҗаларның интерьерны тулысынча үзгәртүләре ачыклана. Корея генералиссимусы салоны стеналары инде чын ефәк белән бизәлгән, төсле фанера бүлемнәр эшләнгән, ә идәндә затлы келәм – калынлыгы дүрт сантиметрлап. Мондый затлылыкны күреп, безнең белгечләр башларына ябыша: авиациядә кулланылырга тиешле материаллар катгый таләпләргә җавап бирергә тиеш – янмаска, зарарлы матдәләр бүлеп чыгармаска, йөкләнешкә чыдарга h.б.лар. Ә монда барлык куркынычсызлык таләпләренә ниндидер күрсәтмә затлылык барәбәренә махсус күз йомганнар диярсең – берәр нәрсә килеп чыга калса, ефәк һәм фанера шунда ук гөртләп кабыначак....

Хәер, Ким Ир Сен апартаментларының затлылыгы күрсәтмәле генә дә булмый. Безнекеләр шунда беренче тапкыр бик зур музыкаль үзәк (СССРда ул чакта бу турыда хыяллана да алмаганнар), мобиль кондиционер, велотренажер күрәләр. Техник прогресс могҗизаларын күрергә дип, экскурсиягә берничә тапкыр КПСС обкомыннан җаваплы иптәшләр дә килгән, дип сөйлиләр. Корея лидеры салонына кергәндә аларны рәт булып тезелеп торган башмаклар каршы алган – иллеалтмыш парлап. Милли колорит, янәсе....

Бүген исә әлеге ИЛ-62 самолетында инде яңа лидер – Ким Чен Ын оча. Салонның байлыгы арткан гына. 2015 елда ММЧнда пәйда булган рәсемнәргә караганда, анда хәзер фил сөяге төсендәге күн җиһазлар, кызыл агачтан эшләнгән панельләр һәм тәмәке төпчеге өчен авыр бәллүр савытлар куелган.

Россия президентлары Ил-62М самолетында инде бүтән очмыйлар. Аларны заманча машиналар – ИЛ-96М һәм ТУ-214 алыштырды. Беренчесендә Төп пассажир, кагыйдә буларак, чит илләргә оча. Ә ил эчендә еш кына ТУ-214 самолетында йөри. Тележурналист Аркадий Мамонтов илгә хәбәр иткәнчә, Президент өчен ТУ-214 не Ульяновскида эшләгәннәр. Тик ул ялгыша – Президентка тәгаенләнгән ТУ-214 Татарстанда эшләнгән.

Фото: www.dailymail.co.uk

ПРЕЗИДЕНТ НИНДИ САМОЛЕТТА ОЧА

1 нче номерлы Борт нәрсә ул? Ул тиз арада, бернинди дә куркыныч тудырмыйча Төп пассажирны А пунктыннан Б пунктына илтеп куярга тиеш кенә дисәк, дөрес булмастыр. Президент самолетының салоны – очыш вакытында Президент ил белән идарә итә, киңәшмәләр үткәрә һәм ял итә ала торган урын. Әлбәттә, дәүләт башлыгының эше һәм ялы өчен барлык шартларның да тиешле югарылыкта булуы карала, шөкер, заманча технологияләр моңа мөмкинчелек бирә. Компьютерлар, бик югары тизлекле интернет, спутник аша дөньяның теләсә кайсы ноктасы белән элемтәгә керү, зур ЖК-телевизор – болар барысы да бүгенге көндә 1 нче номерлы Бортның эчке ягын тәшкил итә.

Хәтта Президентка да самолетны утыртканда һәм очып киткәндә пилот кабинасына керергә ярамый. Ләкин шуңа да карамастан безнең дәүләт башлыгы очкыч җирдән аерылып киткәндә яисә кайдадыр Миланда яки Омскида самолетны утыртканда үзен «ике йөз ундүртенченең» штурвалы артындагы кебек иркен тоя ала. Эш шунда ки, пилот кабинасы эчендәге берничә видеокамера төшергән сурәтләр онлайн рәвештә Төп пассажирның эш кабинетындагы телевизор экранына бирелә. Үзеңне пилот кабинасында кебек хис итү искиткеч көчле!

Әгәр кайчан да булса сезне президентның Ту-214 бортына чакыралар икән, иң беренче чиратта игътибарыгызны эш кабинеты стенасына эленгән Россия флагына, гербына һәм Президент штандартына юнәлтегез. Кыйммәтле агач токымнарыннан, металл, алтын йөгертелеп эшләнгән атрибутлар интерьерга тиешле тантаналылык өсти. Киңәшмәләр үткәрелә торган кабинетта – йомшак кәнәфиләр, ачык төстәге күн диваннар, кызыл агач шпоны белән капланган өстәлләр. Затлы йон келәм, нәзакәтле яктырткычлар, үзе сүнә-кабына торган сизгер выключательләр һәм бизәү

Төп пассажир гадәттә чит илләргә сәфәр кыла торган Ил-96М самолеты.

PRESSA.RU

һәр ВИП-салон – ул һәрвакыт эксклюзив интерьер.

эшендә алтын йөгертелүнең күплеге – болар барысы да салон эчендә җылы мохит тудыра һәм Төп пассажирның аерым статусына ишарәли. Җылы төсләрдә эшләнгән заманча стена панельләре матур да, берүк вакытта утилитар функцияне дә үти – тавышларны йота. Двигательләрнең эшләве ишетелми диярлек: тыныч кына, ярампышылдап сөйләшергә дә мөмкин.

– Ту-214нең фюзеляжы, башка заманча лайнерларныкы кебек үк, бераз гына «уйный». Күтәрелгәндә һәм утырганда җиңелчә шыгырдау сизелә. Гадәти самолет өчен бу шулай тиеш кебек. Литерлы бортны тапшырганда, безгә болай диделәр: «Егетләр, әйдәгез, ничек итеп шыгырдаудан котылу турында уйлашыйк әле», – дип сөйли КАҖБ көнкүреш җиһазлары авиатехнигы Миңнехан Хисамов. – Бер генә көн башыбызны ватмадык, очыш вакытында шыгырдауның кайда көчлерәк ишетелгәнен тыңлый идек. Проблеманы хәл иттек – хәзер Төп пассажирны бернинди ят тавышлар да борчымый.

Литерлы салон эчендәге бизәлешнең сыйфатын хәзер күз белән түгел, лазер ярдәмендә тикшерәләр. Шуңа күрә Брежнев заманында өстәл белән килеп чыккан кебек казусларның бүген булуы гомумән мөмкин түгел. Бүгенге көндә мондый ВИП-салоннарны бизәү белән шөгыльләнүчеләрнең төгәл кагыйдәләре бар. Совет заманында «президент» самолетын ясаганда теләге булган һәр завод кешесе диярлек кереп карый алган. Ә хәзер – гафу итегез! Салонга бары тик наряд-заказ буенча конкрет эш башкарырга вәкаләтлеләр генә керә ала. Һәм – бары тик конкрет урынга гына. ВИП-салон буенча йөрергә беркем дә рөхсәт итмәячәк. Махсус кизү торучы һичшиксез синең билгеләнгән урында билгеле бер биремне үтәвеңне тикшереп-карап торачак. Эшеңне бетерүгә, чыгып китәчәксең.

Төп пассажирның эш кабинетын эшләгән кеше, әйтик, ял зонасының нинди булуы турында бернәрсә дә белми булып чыга. Таныштырыйк:

Россия Президенты Ту-214ПУ самолетында үзенең беренче очышын 2010 елның октябрь аенда Яр Чаллы шәһәренә ясады.



биредә – яхшы итеп ял итү өчен кирәкле бар нәрсә дә бар. Уңайлы киң карават, телевизор, душ кабинасы... Сыйфатлы сантехника, алтын йөгертелгән краннар һәм тоткычлар – барысы да пассажир статусына ярашлы рәвештә ясалган.

– Барысы да очыш шартларында идеаль эшләргә тиеш, шуңа күрә һәр җиһазга махсус таләпләр, – дип аңлатма кертә Миңнехан Хисамов. – Әйтик, самолет утырырга бара, ә Төп пассажир душ кабул итәргә җыена. Гадәти аскуйма авышу-янтаю нәтиҗәсендә почмакта су җыелачак – бу дөрес түгел. Берничә сынау очышыннан соң конструкция камилләштерелде – һәм хәзер бернинди проблема да юк.

Сынау очышлары, катгый контроль, заказчының салонны кабул итеп алуы – һәр литерлы бортны кулланучыга тапшырыр алдыннан башкарыла торган гамәлләр. Бу, әйтергә кирәк, аерым бер ритуал. Ул төгәлләнгәннән соң, заказчы вәкилләре салонны мөһерләп куялар да башкалага очалар – икенче самолетта. Төп пассажирның оча торган апартаментларны хәзер инде Мәскәүдә – 1нче номерлы Бортның очышына ахыргы рөхсәтне бирергә тиешле җаваплы затлар гына ачып керә ала.

Литерлы бортны эшләүдә катнашучыларның барысы өчен дә бер язылмаган кагыйдә бар. Салонны бизәгәндә дә, сынау очышы вакытында да бер генә кеше дә, бер генә секундка да Төп пассажир кәнәфиенә утырырга тиеш түгел. Бу кәнәфигә бары тик бер кеше – ил Президенты гына утыра ала. Казанда дистә еллар дәвамында президент лайнерларын ясау барышында әлеге кагыйдә бер генә мәртәбә дә бозылмаган.

Фото: www.avia.pro, fb.ru, newsru.com

«Татарстан» журналы редакциясе материалны әзерләүдә булышканнары өчен Горбунов исемендәге КАҖБ ветераннарына рәхмәтен белдерә.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛДЫНДАГЫ КАЗАНЫШЛАР ӨЧЕН

Татьяна Водопьянова – профсоюзга Казан дәүләт университетын тәмамлагач килә. «Машинистка булып кына эшләмәдем», – ди ул карьерасы хакында. ТР Профсоюзлар федерациясен 2000 елдан бирле җитәкли. ТР Дәүләт Советының өченче һәм дүртенче чакырылыш депутаты. Социология фәннәре кандидаты, Хезмәт һәм иҗтимагый мөнәсәбәтләр академиясенең Казан филиалындагы Иҗтимагый-хезмәт мөнәсәбәтләре һәм профсоюз хәрәкәте нигезләре кафедрасын җитәкли. «Әнием-мама» хәйрия фондының президенты. 2015 елда «Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән бүләкләнә.

ТӘВӘККӘЛ ТАТЬЯНА

«Ничек яшәп ятасың?» – дигән сорауга җавабым бер генә: «Күңелсезләнергә вакыт юк!» – ди Татьяна Водопьянова. Ул 40 ел буе хезмәт итүчеләрнең мәнфәгатьләре сагында – ТР Профсоюзлар федерациясе рәисе быел үзенең производство юбилеен билгеле.

Әзерләде:
Ольга Туманская

БАШКА ЫСУЛЛАР

Мин һәрвакыт үзара аңлашу яклы, әмма балачактан ук бер дәресне үзләштердем: әгәр кеше оятсызлык һәм көч белән җиңәргә тырыша икән, аның белән сүз ярдәмендә килешү мөмкин түгел, димәк кискенрәк чаралар кулланырга кирәк. Минем белән бишенче класста укыганда булды шундый хәл. Бездә бер хулиган малай бар иде, менә шуның алдында классташ кызларымны яклап чыгарга туры килде. Сүз белән генә берни майтарып булмавын аңлагач, ачуымнан тулышып, гамәлгә күчтем: якасыннан эләктереп алдым да этеп җибәрдем тегене, ул, сөрлегеп, егылды. Үч кайтармый калмас инде бу, дип, көтеп йөрдем, әмма, ни гаҗәп, хулиган малаебыз майлагандай булды…

Бәхеткә, тормышымда башка кул уйнатырга туры килмәде, шулай да әдәпсезлекнең чиге бар, һәм ул шул чиктән ашса, сүздән гамәлгә күчми булмый. 28 яшьлек кафе иясе белән сөйләшүләрне яхшы хәтерлим. Аның бер эшчесе производствода эшләгәндә шактый җитди җәрәхәт алган иде. Әлбәттә, ШЭ аны тиешлечә теркәмәгән дә егетнең кулында нибары авыру турында кәгазь генә калган. Ахыр чиктә, яхмыш аны безгә китерде. Шул чакта мин аның җитәкчесе белән үзем очрашырга булдым. Ул чын мәгънәсендә әдәпсез зат булып чыкты: теле нәрсә сөйләгәнен колагы ишетми. Минем дәлилләремне тыңлауны кирәк дип тә тапмады, гәрчә мин законны боза торган күп нәрсәләрне ишетергә мәҗбүр булдым.

Ярар соң, мондый «дөнья кендекләре»нә карата башка ысуллар да кулланырга мөмкин. Мисал өчен, ТР Дәүләт хезмәт инспекциясе, Прокуратура һәм Россия табигать күзәтчелеге белән безнең арадагы килешү кысаларында уздырыла торган өстәмә тикшерүләр. Кызганыч, мондый җитәкчеләр – шактый киң таралган күренеш, бигрәк тә кече бизнес тармагында. Эшчеләрен кайгырту мәсьәләсе алар өчен һәрчак иң соңгы урында кала бирә.

ҖАВАПЛЫЛЫК МЕНӘ ШУНДА КҮРЕНӘ

Профсоюз эшчәнлегендә катлаулы сораулар еш туып тора. Безнең тарихыбызда 90 нчы еллар да булды, кризислар вакыты да. Андый чакларда кешеләр үзләрен төрле яклап күрсәтәләр. Кемдер, килеп туган шартларга буйсы-

ныш, кыскартуга, яисә эш хакын тоткарлауларына риза булырга мәҗбүр, шуңа да карамастан, ситуациядән чыгу юлларын эзләвен дәвам итә. Ә кемдер күләгәдәрәк калып эш йөртә башлый, ягъни үз мәнфәгатьләрен генә кайгырта. Җитәкченең иҗтимагый җаваплылыгы менә шунда күренә дә инде. Әлеге җаваплылык булган очракта гына аның белән аңлашып, килешеп була, ул яңа юллар, ысуллар эзли. Авыр вакытларда КАМАЗның үзен ничек тотканын гына искә алыйк. Администрация белән сөйләшүләр алып барганда, авыр хәлдә калган кешеләргә ничек тә булса ярдәм итү юлларын таба идек. Йә булмаса Серго исемендәге заводны алыйк. Үз заманында ул, гарантияләнгән оборона заказыннан мәхрүм ителеп, ватык тагарак янында калгандай булды. Завод рәисе белән профком рәисе цехлар буйлап йөреп, эшчеләргә хәлне аңлатырга тырыштылар. Аларның шулай ачыктан-ачык эш итүе моношәһәрдәге киеренкелекне җиңеләйтте һәм күпсанлы сорауларга җавап булып яңгырады.

Республиканың сәнәгать секторы җитәкчеләрдән уңды, дип исәплим. Куәтле рәисләр буыны әле совет чорында ук формалашып калган иде. Әмма мин яңа буын вәкилләрен күзәтеп торып та куанам. Күбесендә оешманың ни икәнен дөрес күзаллау бар. Алар аңлый: оешма – җитештерү күрсәткечләре генә түгел, ул тере организм да. Мәсәлән, Яшел Үзәндәге Горький исемендәге заводның җитәкчесе Ренат Мистахов. Аңа бу оешманы җитәкләгәндә әле кырык яшь тә тулмаган иде, һәм, әйтергә кирәк, заводка ул шактый авыр вакытта килде. Бүген аның оешмасында эшчеләрнең сәламәтлеген кайгыртуга, аларның торак шартларын яхшыртуга, пенсионерларның тормыш сыйфатын күтәрүгә, хәтта ки армия хезмәтенә алынган кадрларның эш урынын саклап калуга кадәр юнәлтелгән җитди иҗтимагый чаралар күрелә. Һәм андый җитәкчеләр бер Мистахов кына түгел, аларны тагын санарга була!

Хәер, башка күренешкә тап булырга да туры килә: хосусый милек ияләре белән шәхси оешма җитәкчеләре, шул исәптән чит капитал белән эш итүчеләр профсоюз эшчәнлегенә төрлечә киртәләр куялар. Шундый очраклар да бар: анда эшләүчеләр профсоюз оештырырга омтылып, эшләреннән азат ителде. Аларга эштән китәр өчен барлык мөмкинлекләрне дә тудырдылар, дисәк тә ялгыш булмас! Әйе, без, әлбәттә, эшчеләрнең мәнфәгатьләрен хокукый рәвештә яклау буенча эшнең барышына катнашып, ниндидер йогынты ясый алабыз, әмма, ни кызганыч, монда башка факторлар да үз ролен уйный. Әйтик, психологик басым, ә аны һәркем дә күтәрә алмый.

КЫЙБЛАДАН ТАЙПЫЛМЫЙЧА

Һәр яңа йомыш белән килүче каршында пошынып утырган чакларымны әле бүгенгедәй хәтерлим: йә, нинди четерекле сорау булыр икән инде бу юлы, янәсе. Аларның иң беренчесен дә яхшы хәтерлим хәтта. Елга портында эшләүче ир-ат иде ул. Йөзү вакытындагы хезмәт хакын дөрес түләмәгәннәр, дип исәпләп килгән иде ул. Җиңел очрак түгел, минем өчен – чын мәгънәсендә стресс. Берни дә белмим, дигән пошыну. Республиканың профсоюзларындагы юридик консультациянең студент чак практикасы әнә шулай башланды. Ул чакта безгә мөрәҗәгать итүчеләр күп иде. Төрле өлкәгә караган сораулар явып кына тора, ә минем ни интернетым юк, ни компьютерым, бары папкага тутырылган документлар, законнар, карарлар белән тулы иксез-чиксез стендлар гына... Һәм, бәхетемә, янәшәмдәге кешеләр һәрчак ярдәмгә килеп торды, алар чын мәгънәсендә белем чыганагы иделәр. Һәм, өзлексез стресска карамастан, мондый күпкырлы эш үземә дә ошады, шуңа күрә, университетны тәмамлаганнан соң, профсоюзга кайттым. Һәм менә 40 ел инде сайлаган кыйбладан тайпылганым юк.

Хәзер профсоюзлардагы эшчәнлек тагын да киңкырлырак. Эш хакы, хезмәт сагы, өстәмә социаль гарантияләр, закончылыкны саклау – тормыш сорауларны үзе китереп чыгарып тора! Кешеләрне бүген нәрсә борчый? Балаларның сәламәтлеге мәсьәләсеме, әллә... ТКХ мы? Яхшы хәтерлим, коммуналь хезмәт өчен түләүнең яңа системасына күчкәндә бик күп бәхәсле очраклар килеп чыкты. Мөрәҗәгатьләр явып кына торды, һәм без бу темага баштанаяк чумарга мәҗбүр булдык. Түгәрәк өстәлләр, хезмәт күрсәтүче затлар белән очрашулар, хокукый нигезләр белән таныштыру, проблемалы зоналарга төзәтмәләр кертү, дисеңме... Күп нәрсәгә ирештек. Һәм бүген коммуналь хезмәт өчен түләүнең үсеше инфляция чигеннән артып китми икән, монда безнең өлешебез дә бар.

«КИРӘК!» – ДИГӘН ТЫЛСЫМЛЫ СҮЗ

«Ничек яшәп ятасың?» – дигән сорауга җавабым бер генә: «Күңелсезләнергә вакыт юк!» Тыгыз график, күпсанлы командировкалар һәм очрашулар... Әгәр эшнең артыбрак китүен сизсәм, берничә километр җәяү йөреп керәм, баш шунда ук аязып китә. Минем өчен «Кирәк!» сүзе тормыштагы үзәк сүз булып әверелде. Моның өчен әти-әниемә һәм спортка рәхмәтлемен. Җиңел атлектика буенча тренербызны үз эшенә тугрылыгы өчен хөрмәт итә идек. Сиңа унөч кенә яшь булганда, ялкаулык үзенекен итә. Әмма спортка кәефеңә карап кына килмиләр – монда барысы да үтә җитди. Шулай ук бирелдә «телим-теләмим» рәвешендәге тарткалашулар да була алмый, монда төп сүз – «кирәк». Юрий Михайлович Красильниковны холкымны тәрбияләүгә керткән зур өлеше өчен еш кына тирән ихтирам белән искә алам. Бәхеткә, андый кешеләр тормышымда шактый күп булды: беренче укытучым Антонина Ивановна Кокуркина, профсоюздагы беренче җитәкчем Ришат Фәйзрәхмәтович Зәбиров һ.б. Мин алардан бик күп нәрсәгә өйрәндем.

СТЕРЕОТИПЛАРНЫ ҖИМЕРЕП

Бер эшлекле чарадан соң, берничә хатын-кыз белән бергә урамга чыктык. Урамда яз! Сөйләшеп басып торабыз, шулчак ТИСБИ ректоры Нэлла Матвеевна Прусс әйтеп куймасынмы: «Әйдәгез, безгә, чәйләп алырбыз!» Бу – әле беренче карлыгачы гына иде... Безнең киләчәктә оешачак хатын-кыз җитәкчеләр оешмасының. Шуннан бирле инде ун ел гомер узып та киткән. Гөлнара Сергеева, Аделя Конюшева, Евгения Даутова, Людмила Китайцева, Людмила Кузьмина – алар белән аралашуыма горурланам. Бу кешеләр белән мин рәхәтләнеп күңелемне бушатып кына калмыйм, ә күп нәрсәләр турында әңгәмә дә кора алам, киңәшләшә дә, һәм көлә-шаяра да.

Татарстанда яңа матур традиция урнашып килә: җитәкче урыннарда хатын-кызлар күбәя. Мин башка вакытларны хәтерлим әле: кабминдагы җитәкчеләр плеядасында нибары Зилә Вәлиева гына бар иде. Хәзерге үзгәрешкә чын күңелдән сөенәм. Билгеле, ул кинәт кенә барлыкка килмәде. Башта без ТР Дәүләт Советына үтеп кердек – өченче чакырылышта уникe хатын-кыз депутат тупланды. Ә бүген югары постларда утыручы хатын-кызлар инде элеккегечә сирәк күренеш түгел. Һәм аларның барысы да үз урынында эшен җиренә җиткереп башкара! Бу, әйтергә кирәк, ир-атлар күп еллар дәвамында тудырган стереотипларны җимерә.

Шулай бервакыт мин Россиянең бәйсез профсоюзлары Федерация Советында гендерлык тигезлеге турында доклад белән чыгыш ясадым. Үзебезнең республикадагы Профсоюз федерациясендә гендерлык тигезлеге идеясен тормышка ашыруыбыз хакында сөйләдем, ул чакта инде безнең әгъза оешмаларының яртысының башында хатын-кызлар тора иде. «Без моның дөрес карар булуына инандык, һәм бу тенденцияне үстерүне алга таба да дәвам итәчәкбез», – дидем доклад азагында. Чыгышымнан соң, яныма берничә кеше килеп, арттырып сөйләмәвемне кат-кат белеште. Әйе, башка төбәкләрне безнең тәҗрибә әле һаман да сокланып тел шартлатырга мәҗбүр итә!

«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены белән ТР дәүләтчелеген үстерүдә, гражданнарның хокукларын һәм азатлыгын тәэмин итүдә, икътисад, мәдәният, фән, мәгариф, сәламәтлек саклау, сәнгать һәм спортны үстерүдәге зур казанышлар, шулай ук җәмәгать тәртибен саклауда күрсәткән кыюлык һәм батырлык өчен бүләкләнәләр. Әлеге билге 925нче пробалы көмештән эшләнгән.

PRESSA.RU

ДЕТАЛЬЛӘРДӘ ЧАГЫЛГАН ГҮЗӘЛЛЕК

3D-сызымны 2D-сызымга әйләндерергә дә кире кайтарыргамы? Төрле гаджетлар өчен кул эшләнмәләре кибете ачаргамы? Берничә сәгатьтә нәзакәтле алка-йөзек моделе уйлап табып, аны эретеп-коеп ясап та чыгарыргамы? Бер кыенлыгы да юк! Татарстанда «Яшь профессионаллар» (WorldSkills Russia)-2017 төбәк чемпионатының җиңүчеләре, алдынгылары ник менә шундый сәер һөнәр – бәлки, сәер гомер юлын да – сайлаганнары турында сөйләделәр.

Алинә Һадиуллина, 19 яшь, Алабуга политехника көллиятенең 3 курс студенты, төркем старостасы, чемпионатның көмеш медале иясе.

– Көмеш медальгә илтә торган юл көллиятнең «Машина төзелеше технологиясе» курсына укырга керүемнән башланды. Дөресен әйткәндә, бу һөнәр турында бөтенләй бернәрсә дә белми идем диярлек. Тик беренче уку көннәреннән соң ук моның нәкъ менә минеке, минем өчен икәнен аңладым. WorldSkills стандартлары буенча «Яшь профессионаллар» төбәк чемпионатына беренче курста ук әзерләнә башладым. Чемпионаттагы «Полимеханика-Автоматика» бәйгесенең стандартлары нигездә минем уку программасы белән туры килә иде, шуңа күрә чемпионатка мин төпле әзерлек белән килдем. Көндәшләрем Бөгелмә көллиятеннән өч егет иде. Бу һөнәр төрендә мин бердәнбер кыз булып чыктым. Чемпионаттагы биремнәр бик катлаулы. Өч көн эчендә без билгеле бер тәртиптә детальнең сызымын укырга, аның 3D-моделенең проектын ясарга, җиһазны шул детальгә көйләп, аны эшкәртү өчен технологик процессны әзерләргә, компьютер белән идарә ителә торган станокта бу детальне җитештерү программасын язарга, күпләп җитештерү үзенчәлекләренә бәйле рәвештә процессны камилләштерергә тиеш идек. Башта ярышта киеренкелек хөкем сөрде, ләкин соңыннан без бер-беребезгә булышып эшли башладык, нәтиҗәдә бик дуслашып киттек, хәзер дә аралашып торабыз. Мин призлы урын алырмын дип уйламадым да, чөнки безнең эшне бәяли торган шартлар исемлеге шундый озын, көндәш егетләр дә яхшы әзерлекле иде. Хәзер исә киләсе ярышларга кайчан әзерләнә башларбыз икән дип, сабырсызланып көтәм. Мондый бәйгеләрдә киләчәктә дә катнашырга телә идем. Синең белән бер өлкәдә эшләүчеләр белән очрашу, тәҗрибә уртаклашу, ниндидер яңа нәрсәләр өйрәнү шундый шәп бит! Өстәвенә, үз һөнәреңдә көннән-көн яхшыра, остара барасың...

Автор:
Ксения Сёмина

Анастасия Әһлиева, 18 яшь,
Казан халык сәнгать һөнәрчелеге техникумының 1 курс студенты, республиканың WorldSkills җыелма командасы әгъзасы.

> **– Биремдә кушылганча, сызымның нечкәлекләренә төшенеп, шуның нигезендә бизәнү әйбере ясый алдым. Бу гаҗәеп мавыктыргыч икән бит!**

– «Яшь профессионаллар» төбәк чемпионатында беренче тапкыр катнаштым. Без, ягъни мин һәм техникумның тагын биш студенты, ярышларга берникадәр вакыт кала махсус әзерлек уздык. Эмоциональ яктан авыр булырга мөмкин дип, укытучылар безне алдан кисәтеп куйды. Шулай булып чыкты да: ул биремнең кыенлыгын, таләпләрнең катлаулылыгын күреп, безнең янда тамашачылар җыелуыннан арып, барысын да ташлап качасы килде. Ләкин соңыннан үземне яхшырак хис итә башладым, кызыксыну да артты, биремне башкарып чыга алуымны да аңладым һәм бөтен игътибарны шуңа гына юнәлттем. Биремдә кушылганча, сызымның нечкәлекләренә төшенеп, шуның нигезендә бизәнү әйбере ясадым. Бу гаҗәеп мавыктыргыч икән бит! Чемпионатта чыгыш ясап, шуңа төшендем: WorldSkills бәйгеләре үз һөнәри дәрәҗәңне ачыклау, омтылыш-максатларны билгеләү мөмкинлеге бирә, үзеңә карата таләпчәнлекне арттырырга бер этәргеч булып тора. Хәтта салмаклык, сабырлык таләп ителгән зәркәнче кебек һөнәрдә дә! Чөнки күпләп җитештерү тармагында хезмәт куйганда, тиз һәм хатасыз эшләү күнекмәләре дә таләп ителә. Ә инде син дизайнер икән – моданы, җәмгыятьтәге карашларны, кызыксынуларын күзәтеп барырга, хыялыңны эшкә җигеп, синеке икәнлеге аерылып торган үзенчәлекле нәрсәләр ясый белергә, камиллеккә омтылырга тиешсең. Булачак һөнәремнең шундый яклары миңа әлеге бәйгедән соң бөтенләй башкача, тагын да аныграк рәвештә ачылды.

PRESSA.RU

Диләрә Низамова, 17 яшь,
Яр Чаллыдагы 26 нчы гимназиянең
11нче сыйныф укучысы,
чемпионатта җиңүче.

– Былтыр февраль аенда без сыйныфыбыз белән Чаллының «Кванториум» технопаркына бардык. Ул көнне паркка Россия Президенты Владимир Путин килергә тиеш иде. Хөрмәтле кунакны көткәндә, лазер технологияләре бүлмәсендә утырып тордык. Анда лазер белән кисеп ясалган әйберләрне күргәч, кызыксыну туды. Үземнең дә шушы эшне өйрәнәсе килеп китте. Менә шулай башланды да инде. «Кванториум» дәрес алу, күнекмәләр булдыру өчен бик шәп база булды – монда кирәкле станоклар һәм материаллар бар. Өстәвенә, мин сәнгать мәктәбен тәмамладым, әлеге уку йортында ахыргы модельне китереп чыгару өчен бөтен этапларны күзаллау сәләте, пространстволы фикерләү күнекмәсе булдырыла. Бу исә лазер белән кисеп нәрсәдер ясаганда бик булыша. Чемпионатка бары тик җиңү максаты белән генә барган идем. «Лазер технологияләре» бәйгесендә дүрт кеше көч сынаштык – ике егет һәм ике кыз. Асылда кызегет дип аерып карау булмады, ярыш мәйданчыгында үзара ярдәмләшү атмосферасы хөкем сөрде. Бирем 2D-сызым нигезендә 3D-модель ясаудан гыйбарәт иде. Беренче көнне эш панеле моделен ясарга кирәк булды, икенче көнне – җитештерү өчен деталь моделе, ә өченче көнне – металл пластинканы чүкү. Беренче биремне алгач, эш планын төзи башладым. Каушап-борчылып торырга вакыт юк иде. Барысын да бер көндә эшләдем. «Кванториум»га ел буе дәресләргә йөреп туплаган бик зур практик тәҗрибә җиңүгә алып килде дә. Гомумән, бүген инде бу – минем өчен яраткан шөгыль генә түгел, ә киләчәк тормышымны бәйләргә теләгән һөнәри юнәлешем дә. Лазер технологияләренең бик күп тармакларда – медицинадан алып космоска кадәр – көннән-көн әһәмияте арта барган ролен бәяләү дә авыр. Ә мин нәкъ менә шунда – алгарышның өр-яңа нәтиҗәләре көндәлек тормышыбызның тагын да яхшыруына, җайлашуына китергән өлкәдә булырга телим.

Юлия Сичевская, 21 яшь, Тимирясов исемендәге Казан инновация университеты менеджмент һәм инженерлык бизнесы факультетының 4 курс студенты. Әлеге уку йортының тагын бер студенты – Карина Халеева белән чемпионатта җиңү яулыйлар.

– «Яшь профессионаллар» чемпионаты турында университетта белдем. «Эшмәкәрлек» төре буенча бәйгедә катнашу өчен тест уздым, аннары – Татарстан Республикасының җыелма командасына кабул ителдем. Әлеге якты һәм озын тарих әнә шулай башланды. Кейслар, проектлар, идеяләр, презентацияләр, йокысыз төннәр... Чемпионат алдыннан безнең ярыш төрендә катнашучыларның барысы да Татарстанның Икътисад министрлыгына көн саен дәресләргә йөрде, бизнес-тренерлар һәм уңышлы эшмәкәрләр белән очрашты. Чан Ким белән Рене Моборның «Зәңгәр океан стратегиясе» китабы кызыксыну, бу өлкәгә омтылыш уятты, ә икътисадның реаль тармагындагы микро- һәм кече эшмәкәрләр өчен хәзерләнгән «Бизнес-класс» түләүсез программасы (порталы) гамәли яктан файдалы булды. Бер-бер артлы модульләрне узып, эшмәкәрлекнең минем өчен чыннан да кызыклы икәнен, бу юнәлештә тагын да үсештә булырга теләвемне аңладым. Чемпионатта Карина белән бергә «TatarStyle» интернет-кибете һәм остаханәсе проектын тәкъдим иттек. Ул телефоннар/планшетлар өчен татар милли өслүбендә эшләнгән күн һәм агач каплар, тышлыклар, ноутбуклар өчен кейслар ясауны күздә тота. Безнең проект җиңү яулады. Бу яхшы репетиция булды. Шул рәвешле мин белемнәремне арттырам, аларны гамәлдә кулланып карыйм, хаталарымны тикшерәм. Әүвәлрәк үз эшемне ачуга бик еракта-гы, кул җитмәс хыял кебек карый идем, куркып йөрдем (уңышсызлыкка очрап, акча югалтудан һәркем шүрли бит). Хәзер исә үз эшемне башлау – чын максатым, һәм мин аны тормышка ашыру юлына басарга әзермен. Төп сорау – кайсы өлкәне сайларга һәм бу мәсьәләдә ничек ялгышмаска? Эшемне чын-чынлап яратырга һәм бары тик яраткан эш белән генә шөгыльләнергә телим. ■

> **– Бер-бер артлы модульләрне узып, эшмәкәрлекнең минем өчен чыннан да кызыклы икәнен, бу юнәлештә тагын да үсештә булырга теләвемне аңладым.**

PRESSA.RU

Автор:
Руфия Фазылова

АКЧАҢ БУЛМАСА... ЧИРЛӘМӘ!

Авырып китсә, дәвалану өчен күпме акча чыгасын үз башыннан кичергән кеше генә белә. Бер кан анализы тапшыру гына да 300 сумнан башлана. Ә УЗИ, МРТ кебек тикшерүләр исә бөтенләй дә меңнәр белән исәпләнә. Шул ук вакытта ай саен хезмәт хакының якынча 6 проценты мәҗбүри медицина иминияте фондына (ФОМС) күчеп бара. Нигә кирәк соң бу? Сырхауханә, хастаханәләргә баргач, нәрсәгә дәгъва кыла алабыз?

ДИСПАНСЕРИЗАЦИЯНЕ – ӨЧ КӨНДӘ!

Һич уйламаганда «АК БАРС-Мед»тан шалтыраттылар. Баксаң, 2017 елдан диспансеризация узуны әлеге оешма контрольдә тота, алай гына да түгел, мәҗбүри иминият фондларының төп юнәлешләренең берсенә әйләнгән икән. Телефоннан шалтыраткан туташ бик матур итеп сөйләште:

– Быел сезнең елгылар диспансеризация уза. Бездә исемлек бар: бер тапкыр да диспансеризация үтмәгәнсез. Яшәгән урыныгыз буенча үзегезнең участок табибына барыгыз, озак түгел ул.

Чынлап та, минем бер тапкыр да диспансеризация узганым юк. Сәбәбен хәтта аңлата да алмыйм, мөгаен, дәваханәләрдәге су буе чиратлар куркытадыр. Аннан да бигрәк, тик торганнан табибка йөрергә гадәтләнмәгән. Озын сүзнең кыскасы, «АК БАРС-Мед»тан шалтыраткан кызның да үтенечен кире какмаска булдым. «Бармасагыз, яңадан шалтыратам», – дип «яңады» бит.

Без Казан шәһәренең Мәскәү районында яшибез, Восстание урамындагы 11нче дәваханәгә карыйбыз. Дөресен әйтим, моңа кадәр анда булганым юк иде. Шулай итеп участок табибы белән танышырга бер форсат булды. Гаҗәп, әмма табибка чират зур түгел, минем алда бары тик 2 кеше генә. Ярты сәгатьләп көтеп утырганнан соң, табиб-терапевт янына кердем. Башта табиб кан басымын үлчәде, йөрәкне тыңлап карады. Аннан шәфкать туташы анкета сорауларына җавап бирүемне үтенде. «Көненә ничә чакрым җәяү йөрисең?», «Күпме яшелчә, җиләк-җимеш ашыйсың?», «Тәмәке тартасыңмы?» «Аракы эчәсеңме?» кебек сорауларга җавап язганнан соң, ЭКГ узарга җибәрделәр. Биредә су буе чират. (Күбрәк – өлкән буын кешеләре). Аңламыйча калдым, әллә шунда бер ир-ат чиратсыз керергә теләгән, әллә башка сәбәп, ЭКГ кабинеты каршысында бик нык тавышланалар. Җитмәсә, утырырга урын да юк. Читкәрәк китеп бастым. Теге ир белән әби унбиш минутлап кычкырышкандыр. Инде алар тынычланды гына дигәндә, бер ханым тавыш күтәрде: авыру баласын чиратсыз кертергә тели икән. Кырык минутлап зар-интизар тыңлаганнан соң, ЭКГ узу бәхетенә ирештем үзе. Кардиограмманы кулга тотып, янәдән табиб-терепевт янына кердем. Ул көнгә башка белгечләргә барасы булмады: кан анализына, гинекологка дигән талоннарны алып, дәваханәдән чыгып киттем.

Икенче көнне кан тапшырырга бардым. Баксаң, диспансеризация узучыларга кан бирү кабинеты аерым икән. Чират күп булмасын өчен, зур дәваханәләрдә махсус шулай эшләгәннәр. Ләкин халык шактый иде, ярты сәгатьләп чиратта торырга туры килде. Ун көнләп вакыт узгач, янә участок табибы янына килдем. Тапшырган анализларымның нәтиҗәсен белергә кирәк бит. Бу юлы да табибка чират тормадым, минем алда 1 генә кеше иде.

– Барысы да тәртиптә сезнең, – дип шатландырды табиб. Тагын яңа белгечләргә җибәрер, дип уйлаган идем, ялгышкан булып чыктым. – Сезнең яшь өчен шулар гына каралган, – дип, сүзен җөпләде. Әмма минем эндокринологка күренәсем килде, тик диспансеризация вакытында бу белгечкә 39 яшьтән соң гына баралар икән. Кыскасы, тулы тикшеренү дигәннәре кан, бәвел анализы тапшыру, ЭКГ яздыру һәм гинекологка кереп чыгу белән чикләнде.

Диспансеризациядән нинди тәэсирләр калды соң? Тулаем алганда, начар түгел: моның өчен, чынлап та, әллә ни күп вакыт кирәкмәде. Берданбер гаҗәпләндергән нәрсә: белгечләр бик аз. «Ниндидер күрсәтмә булганда гына махсус белгечләргә җибәрәбез», – ди табиб. Әгәр кеше сәламәтлегеннән зарлана икән, табиб ни өчен УЗИга юлламаа бирми? (Миңа калкансыман бизне берничә ел элек үк тикшертергә кушканнар иде, мәсәлән).

«ХОКУКЛАРЫН БЕЛМИЛӘР»

Татарстанда медицина иминияте компанияләре өчәү: «АК БАРС-Мед», «Спасение» «Чулпан-Мед». Иң зурысы «АК БАРС-Мед» санала, республикада яшәүче халыкның 90 проценты әлеге оешмада теркәлгән. Гәрчә калган ике медицина иминияте компаниясенең дә бурычлары шул ук – халыкка бушлай медицина хезмәте күрсәтүне контрольдә тоту. Беренчесенең популярлыгы, мөгаен, еллар буена килгән тәҗрибә белән исәпләнәдер, алар медицина иминияте оешмаларының иң беренчеләреннән санала.

«АК БАРС-Мед»ның клиентларга хезмәт күрсәтү департаменты җитәкчесе Эльвира Назыйрова мондый оешмаларның эш үзенчәлеге турында сөйләде:

– Иминият полисларын алган кешеләрнең күбесе үз хокукларын белми. Табиб ниндидер түләүле анализлар тапшырырга кушса ризалашалар. Андый очракларда беренче чиратта иминият компанияләренә шалтыратып сорарга кирәк: шулай тиешме, юкмы? Һәр компаниянең тәүлек буе эшли торган «кайнар линия»ләре бар.

Күрсәтелгән медицина хезмәтеннән риза булмаган кешеләр иминият оешмаларына үзләре килә ала. Теге яки бу дәвалау оешмаларын, аерым табибларны судка бирү очраклары да булгалый икән.

– Кеше факторы дигән әйбер һәр җирдә бар, – дип сүзен дәвам итте Эльвира Назыйрова. – Күп очракта пациент белән табиб арасында аңлашылмаучанлык кына килеп чыккан була. Дәваханә, сырхауханәнең бүлек җитәкчеләренә шалтыратып, шул аерым хәлләрне ачыклыйбыз. Алар исә җитәкчелек карамагындагы табиблар белән хәл итәләр. Нәтиҗәдә, пациент мәнфәгатьләре өстә кала, 90 процент очракта мәсьәләләр уңай чишелә.

Иминият компанияләренә иң күп мөрәҗәгать: стационарда, бигрәк

Фотолар: «АК БАРС Мед» Мәҗбүри медицина иминият компаниясе клиентларга хезмәт күрсәтү департаментыннан алынды.

PRESSA.RU



Шаккатмалы хәл: узган ел республика буенча диспансеризация узып, өч-алты ай яшәгәннән соң, 20 кеше вафат булган. Ә тикшеренү нәтиҗәләре буенча, аларның барысы да сәламәт дип табылган. Шулай икән, диспансеризация узып, «сәламәт» дип сугылган мөһернең ни дәрәҗәдә дөреслеккә туры килүенә һәркем үзе нәтиҗә чыгара ала, димәк.

тә көндезгедә, дәваланганда, табибларның кайбер уколларны, даруларны сатып алырга кушуларына карата дәгъва икән. Әлбәттә, авыру үз хокукларын белергә тиеш.

– Стационарда дәваланганда, дару препаратлары белән тәэмин итү түләүсез нигездә башкарыла, шул исәптән көндезгедә дә, – ди Эльвира Айдаровна. – Медицина оешмасында табиб, пациентның авыруына карап, дәвалау юлларын, кирәкле даруны билгели. Дарулар да, диагностик тикшеренүләр дә бушлай булырга тиешле. Әгәр закон бозыла икән, даруга яки диагностик тикшеренүләргә тотылган акчаны кире кайтару юлларын табабыз. Бары бер таләп бар: сырхауханәдә яткан пациент, үзе сатып алган укол, даруларның чекларын сакларга тиеш. Башта, әлбәттә, стационарда яткан-да кешенең әлеге препаратларны кулланганлыгын тикшерәбез, алар амбулатор картада теркәлгән була.

НӘРСӘГӘ ӨМЕТЛӘНӘ АЛАБЫЗ?

Медицина иминияте полисы булган кешенең хокуклары бик киң: МРТ, КТ, ангиография кебек тикшеренүләр, катлаулы операцияләр, бала табу һ.б. Ә иң мөһиме – болар барысы да бушлай булырга тиеш, бу закон белән расланган. Ләкин, яшерен-батырын түгел, тормышта икенче хәл белән очрашабыз: бушка булган тикшеренүләргә айлар буе чират көтәргә кирәк. Ә акча түләсәң, барысы да көнендә хәл ителә. Хәтта хатын-кызлар да, бала тудыру йортына барганчы, башта билгеле бер күләмдә акча түләп куюны хуп күрә. Мондый очракларда иминият компанияләре, халыкны үз хокукларын белергә өнди: полисы булган кешегә медицина ярдәмен күрсәтү стандартлары һәм тәртипләрендә теркәлгән барлык төр медицина хезмәтләре дә түләүсез!

Татарстан Республикасында гражданнарга медицина ярдәмен түләүсез күрсәтүнең дәүләт гарантияләре программасы бар. Анда шулай ук һәр тикшеренү турында аерым күрсәтмә дә бар. Мисал өчен:

– ашыгыч ярдәм машинасы, шалтырату булганнан соң, 20 минут эчендә килеп җитәргә тиеш;

– табиб, ашыгыч булган очракта, авыру янына 2 сәгать эчендә килергә бурычлы;

– магнитлы-резонанслы томография (МРТ) РТ, КТ, ангиография үткәрү вакыты, табиб билгеләгән көннән алып, 30 көннән артмаска тиеш;

– рентген, УЗИ, маммография, функциональ диагностика тикшеренүләрен көтү вакыты, иң күп дигәндә, 14 календарь көнне тәшкил итә;

– дәваханәләрдә аерым белгечләргә язылу вакыты (невролог, хирург, офтальмолог һ.б) 14 календарь көннән артмаска тиеш;

– план буенча госпитальләштергән очракта, көтү, дәвалаучы табиб биргән вакыттан алып, 30 календарь көннән артмый. (Пациент госпитальләштерү өчен үзенә тәкъдим ителгән көндә мөрәҗәгать итәргә тиеш).

«АЕРЫМ КҮРСӘТМӘ БУЛСА ГЫНА...»

Казанда яшәүче Гөлназ Әхәтова табибларның битарафлыгыннан зарланды:

– Өч-дүрт еллап баш авыртудан интегәм, – дип сөйләде ул. – Берничә тапкыр «больничный» да алдым. Неврологка бардым, бер-ике төрле укол язды да бетте. Тик аларны кадатканнан соң баш авыртуым бетмәде. Участок табибына бардым:

> 2016 елда республиканың медицина иминияте оешмаларына 597 мең мөрәҗәгать булган. Шуларның 1238е – ризасызлык белдереп шалтыратучылар.

«Миңа МРТ ясатырга юллама бирегез әле», – дидем. Табиб гозеремне кире какты, янәсе, аерым күрсәткечләр юк. Ә еллар буе баш авырту нинди күрсәткечкә керә?

Мондый хәлләр белән күп кеше очраша. Дөрес, төрле кешедә төрле проблема: кемдер маммологка эләгә алмый, кемдер ангиография ясата алмый. Бу хәлне дистә еллар сырхауханәдә участок табибы булып эшләгән Камил әфәнде (мәгълүм сәбәпләр аркасында исеме үзгәртелде) болай дип аңлатты:

– Әгәр һәр теләгән кешегә МРТ яки башка тикшеренүләргә юллама бирә башласак, дәваханә, сырхауханәләрдә урын булмас иде. Шуңа да аерым күрсәткечләр: кан, башка анализлар, авыруның гомуми халәтенә карап фикер йөртәбез. Бик авыр хәлдәге кешеләр иң беренче булып тикшерүгә җибәреләләр. Базар мөнәсәбәтләре чорында яшибез: бүген һәркем (гади авыл мәктәбе, клубыннан башлап зур-зур оешмаларга кадәр) дәүләт биргән акчадан тыш өстәмә керем алуны кайгыртырга тиеш. Шул исәптән дәүләт дәваханә, сырхауханәләре дә. Шуның өчен алар түләүле хезмәт күрсәтү бүлекләре булдырдылар. Аның аерым бер квотасы бар, ягъни теге яки бу аппаратта бер көнгә билгеле бер сандагы пациентларны гына карарга рөхсәт ителә. Монда табибларны гаепләргә ашыкмасыннар, система шундый, бернишләп тә булмый...

Табиблар турында сүз чыккач, бер «күркәм гадәт» турында да сүз әйтмичә булмас. Операция ясаткач, бала тапканнан соң, табибларга акча, яки кыйммәтле бүләкләр бирәбез. РФ Гражданнар кодексына күз салсак, анда болай диелгән: «Медицина оешмалары хезмәткәрләренә пациентлар һәм аларның туганнары тарафыннан бүләк бирү рөхсәт ителми. Ләкин моңа бәясе өч мең сумнан артмаган гадәти бүләкләр керми». Кыскасы, өч мең сумнан артмаган бүләк рөхсәт ителә булып чыга. Ләкин тагын бер документ бар – Татарстан Республикасы табибының Этика кодексы. Анда акка кара белән болай язылган: «Табибка, авыру стационардан чыкканчыга кадәр, бүләкләр яки бәхилләшүнең башка төрләрен алу тыела. Пациент, үзен өстенлекле шартларда дәвалауны сорап бүләк тәкъдим итә икән, табиб баш тартырга тиеш. Шулай да рәхмәт табибның да, пациентның абруен төшерми. Ул РФ законнары белән беркетелгән бүләк бирү турындагы хокукый нормаларны бозмый торган формада булганда гына табиб тарафыннан алынырга мөмкин».

Кыскасы, табибларга бүләкне законга яраклаштырып бирергә кирәк булып чыга инде.

«АШАГАН БЕЛМИ, ТУРАГАН БЕЛӘ?»

Ай саен хезмәт хакыбызның 33 проценты өстәмә социаль кертемнәр өчен тотыла. Бу акчаның иң күп өлеше – якынча 22 проценты Пенсия фондына, дүрт процент чамасы социаль иминиятләштерү фондына (ФСС) һәм калганы мәҗбүри иминиятләштерү фондына (ОМС) күчә. Соңгысында исә: «Ашаган белми, тураган белә», – дип аңлатырга тырыштылар. Пациентның 1 атна стационарда ятып чыгуы, дәвасына карап, йөз мең сумнан да ким түгел икән. Хезмәт хакыннан тотылган алты процент акча беренче чиратта шуңа китә.

Хәзер барлык сырхауханәләрдә, бала тудыру йортларында диярлек түләүле палаталар бар. Гәрчә дәвалау шул ук. Бу очракта кеше аерым уңайлыклар өчен түли. Гадәттә, түләүле палаталар ремонтланган, юыну бүлмәләре ялт иткән була. Медицина оешмасы белән килешү төзисең дә, рәхәтләнеп аерым палатада ятасың. Монысы аңлашыла.

Аңлашылмый торган як та бар: иминият полислары булып та, күпләребез, бигрәк тә яшьләр, түләүле анализлар тапшыра, түләүле табибларга йөри. Беренчедән, анда чират көтәсе юк. Икенчедән, дәваханәләргә әллә ничә тапкыр шалтыратып, шул ук неврологка чиратны икешәр атна көткәнче, тиз генә түләүлегә кереп чыгасың. Әнә бит, диспансеризация үткәндә участок табибыннан эндокринологка җибәрергә сорагач: «Аерым күрсәтмә булса гына», – диде. Аңлавымча, «күрсәтмә» булсын өчен аяктан егылырга кирәк, шуннан соң гына аерым белгечләргә, яки УЗИга юллама бирәләр. Шулай да бер юаныч бар: әле ярый стационарда бушка дәваланабыз. Хәер, иң мөһиме – чирләргә язмасын!

Марина Мөхәммәтҗанова,
ТР Территориаль медицина иминияте фонды директоры урынбасары:

– Федераль рейтингта ТР иминият фондлары астагы баскычларда тора. Сәбәбе – мәгълүмат бирү буенча аз эшлиләр. Бу максатка күбрәк акча сарыф итәргә кирәк. Медицина полислары булган кешеләр үз хокукларын, профилактик чаралар турында белергә тиеш. Моны аерым контрольгә алачакбыз.
Татарстанда иминиятләштерү вәкилләре институты барлыкка килде. Аның максаты – халыктан килгән шикаятьләрне хәл итү. Республикада медицина иминиятләштерү оешмаларында 83 вәкил бар. Алар махсус сырхауханә, дәваханәләргә чыгып, халыкның зарын тыңлый. Аерым белгечләргә, озак вакыт УЗИ, МРТ уза алмыйча йөргән пациентларның мәнфәгатьләрен кайгырта.

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН-24»: СӘГАТЬ САЕН ЯҢАЛЫКЛАР

Эфирда әле күптән түгел генә старт алган «Татарстан-24» телеканалының генераль директоры Сергей Лобов журналыбызга биргән интервьюда республика мәгълүмат кырында әйдәп баруга йөз тоткан яңа медиа-ресурсның нигә кирәк булуы, аның потенциаль аудиториясе һәм гамәлгә куючылар тарафыннан йөкләнгән финанс вазыйфалары турында сөйләде.

Әңгәмәне
Нияз Әхмәдуллин
алып барды

– «Татарстан-24» телеканалын булдыруга нинди сәбәпләр этәрде?

– Төп сәбәпләр – икәү. Беренчедән, республикада шактый бай мәгълүмат кыры барлыгына карамастан, Татарстанда ниләр эшләнүе турында сәгать саен хәбәр итеп торучы яңалыклар форматы юк иде. Шуңа күрә республика халкына чынлыкта онлайнга якынайтылган режимда яңалыклар турында сөйләп торучы канал булдыру кирәге туды да инде. Без «Сәгать саен яңалыклар» бренды белән эшлибез. Үзебез программалаштырганга һәм оригиналь контентның 90%тан күбрәген мөстәкыйль булдырганга күрә, безнең тәүлек дәвамында даими режимда яңалыкларны күзәтү мөмкинлегебез бар. Әйтик, иртәнге сәгать 10да Алабугада, Түбән Камада, Казанда яки башка бер урында ниндидер вакыйга булган икән, без бу хакта бер сәгатьтән эчтәлекле сюжет күрсәтә алсак, сәгать 12дә ул инде экспертлар катнашында чыга, кичкә вакыйга нәтиҗәләре буенча тулы бер тикшеренү күрсәтә алабыз.

Хәзер канал булдыруның икенче сәбәбе турында. Сез беләсездер, быелдан башлап, федераль каналлар челтәрдәге партнёрлары белән мөнәсәбәтләрен туктата. Шулай булгач, байтак төбәк телестанцияләре өчен үз тапшыруларын дәвам итү проблемалы эшкә әверелә. Аларга бик еракка – 60 нчы, 70 нче төймәләргә күчәргә туры киләчәк, кабель операторы аларны шунда «утыртачак». Шуңа күрә «Татарстан-24» – республика телеканалларының бөтен төбәк челтәре өчен котылу чарасы ул. Беренчедән, без 22 нче төймәдә чыгачакбыз, ә бу алай ук ерак түгел. Икенчедән, без районнарда тапшыруларны тулысынча саклап калдык. Төбәк телестанцияләрендә татар һәм рус телләрендәге тапшырулар тулысынча сакланып калды. Мин җәйгә таба безнең барлык төбәк телестанцияләребез «Татарстан-24» йөзендә үзләренең челтәр партнёрын табар, дип уйлыйм.

> **“**
> **Әйтик, иртәнге сәгать 10да Алабугада, Түбән Камада, Казанда яки башка бер урында ниндидер вакыйга булган икән, без бу хакта бер сәгатьтән эчтәлекле сюжет күрсәтә алабыз.**

– Ә тамашачылар аудиториясен ТНВ белән ничек бүлешергә җыенасыз?

– Беләсезме, республиканың медиабазары кайсы ягы белән яхшы? Безнең «Эфир»га да, «ТНВ»га да, «Татарстан» ДТРК»нә да көндәш булмавыбыз белән. Бер генә канал да бу базарда «сәгать саен» режимында яңалыклар тәкъдим итү мөмкинлегенә ия түгел. Шуңа күрә без бер-беребезгә көндәш булып тормыйбыз. Тамашачы исә төрле каналларда төрле контент карау мөмкинлеген ала.

– Сезнең потенциаль тамашачыларыгыз кемнәр?

– Алар – халыкның 25–30 яшьтән башланган һәм үзләре өчен бүгенге мәгълүмат кырында ориентлашуны кызыклы санаган социаль актив өлеше.

– Сезнең телеканал тарафыннан программаларны татар телендә карарга теләгән тамашачыларның таләпләре ни дәрәҗәдә исәпкә алына?

– Төбәкнең рус һәм татар телләрендә эшләгән барлык телестанцияләре дә үз районнары һәм шәһәрләрендә шул телләрдә алып барган тапшырулар күләмен саклап кала.

– Бу елда үз алдыгызга нинди бурычлар куясыз?

– Телеканалны гамәлгә куючылар арасында – «Татмедиа» АҖ һәм идарә итүче компания дә бар. Без чынлап һәм озакка килдек. Әлбәттә, бүгенге көндә без стартап стадиясен үтәбез. Гамәлгә куючыларыбыз безне акча эшләү максатына юнәлдерә. Безгә реклама бирүчеләр белән эшне җәелдерергә кирәк, шул ук вакытта без рекламаны бөтен республикага тарату өчен яхшы шартлар тәкъдим итә алабыз. «Татарстан-24» сыйфатлы контент җитештерә һәм һәркем белән хезмәттәшлеккә ачык. Безнең өчен мөмкинлекләребезнең тулысынча файдаланылуы мөһим.

Реклама 16+

PRESSA.RU

Бакый Урманченың Буа Төбәк музеендагы почмагы. Яраткан креслосы, мольберты, рәсемнәре, эскизлары һәм аксакалның бюсты. Бу экспонатларның кайберләрен музейга Милли музей сатып алып тапшырса, кайберләре Урманченың тормыш иптәше Флора ханым һәм улы Айдар тарафыннан бүләк итеп тапшырылган.

КЕЧЕ ВАТАН ПАТРИОТЛАРЫ

ХАЛЫКТАН АЛГАННЫ – **ХАЛЫККА...**

Автор:
Луиза Янсуар

Аның хакында туган төбәгендә кемнән генә сорасаң да, бер сүзне әйтәләр: «Гади иде, шул ук вакытта, ил агасы кебек, зирәк, тирән шәхес. Халыктан алганны халыкка кайтарып тапшырды». Алар бу шәхеснең иҗаттагы новаторлыгы, яңа ачкан офыклары, техникасының байлыгы, метаморфозалары турында сүз алып бармый, әмма әнә шул халыкчан рухны тоя һәм аның кеше буларак затлылыгы турында сөйли. Шунысы мөһим дә бит: туган төбәккә күренекле шәхесләрнең якташлары күңелендә нинди эз калдырганын белергә кайтабыз.

Фото: Ната Смирнова

Буага килеп төшүгә, безне мондагы Буа Төбәк тарихы музее директоры Люция Әхмәтҗанова белән озак еллар дәвамында Буа районының төрле структураларында җитәкче вазыйфаларда эшләп, хәзерге көндә лаеклы ялда булган ватанпәрвәр шәхес – Рафик абый Нугманов каршы алдылар. Чәйләп утырганда, Рафик абый Люция апага ымлап, болай диде:

– Люция апагыз бу музейда – көн дә, төн дә, ул булмаса, мондагы экспозицияләрнең күбесе булмас иде.

Чынлап та, музейны карый башлагач, шуны аңладык: һәр экспозиция турында аерым-аерым язарга мөмкин. Менә Буа тимер юлы төзелү тарихына багышланган тулы бер зал, менә Буа театрына багышланган почмак, менә Идел буендагы ачлык елларындагы шомлы сәхифәләрне хәтерләтеп, дивардан йөзе сыдырылып кипкән, гәүдәсе күбенгән сабый фоторәсеме ачынулы караш белән карап тора...

Әйтергә кирәк, Люция апа мин Казаннан беренче тапкыр шалтыратуга: «Була ул, Луиза сеңлем, кешеләрен дә табам, сөйләшеп тә куям», – дип кистереп әйтте. Һәм килүебезгә, Буаның үзендә дә, Күл Черкене музей-йортында да безне заманында Бакый аганы күреп-белеп калган кешеләр көтеп тора иде.

Бакый Урманченың тамырларын барлауны район үзәгендәге музейдан башладык. Соңыннан инде Күл Черкене авылындагы музей-йортка юл тоттык.

КҮЛ ҖЫЛЫСЫН САКЛЫЙЛАР...

– Бакый агага багышланган бу почмак 2007 елда барлыкка килде. Баштарак Флора апа шәхси экспонатлар белән ярдәм итте, аннары мин улы Айдар белән эш итә башладым, – дип сөйләп китте Люция ханым. – Нәкъ менә Айдар безгә әтисенең остаханәсенә ишекләрне ачты, дисәк тә була. Флора апа күбрәк Казандагы Урманче музее белән бәйләнештә булды. Бакый ага остаханәсеннән алып, без музейның беренче катына аның атаклы сыннарын кайтарып куйдык. Аларның бер өлеше Күл Черкене музей-йортына урнаштырылды.

Бакый Урманче почмагының иң түрендә күн кресло тора. Әйтүләренә караганда, бу аның яраткан креслосы булган. Шулай ук – Урманченың эш кораллары, буяулары таралып яткан мольберты. Люция ханым безгә мольбертның бер тартмасын ачып күрсәтә – анда хәтта рәссам исән чагында кулланып өлгермәгән буяу тюбикларына кадәр бар.

Диварларда – төрле техникада эшләнгән рәсемнәр. Фотосурәтләр. Тулы бер эпоха. Тарих.

– Без бу рәсемнәрне сатып алдык, дөресрәге, аларны Милли музей безнең өчен сатып алды, – дип төгәллек кертә Люция ханым. – Без бит – Казандагы музей да, райондагысы да – аларның филиалы... Кайберләрен Айдар белән Флора ханым бүләк итте...

– Казандагы Урманче музее белән бәйләнешләрегез ничек? Сез бер-берегезгә конкурентлармы? – дип кызыксынам.

– Алай дип әйтеп булмый инде, безнең вазыйфаларыбыз төрле бит, – ди Люция ханым. – Казандагы музей хезмәткәрләренең безгә кунакка килгәннәре дә бар. Хәзер, Флора ханымның вафатыннан соң, сүлпәнрәк аралашабыз-аралашуын. Ул музейны булдыру идеясе Флора ханымныкы, алар бит бездән иртәрәк барлыкка килделәр. Шуңа Флора ханым аларга күпчелек әйберләрне тапшырып калдырган. Алар да, без дә төрле чыганаклардан туплыйбыз материалларны, үзара килешеп түгел. Безгә Бакый аганың туган төбәге белән бәйле еллары кадерлерәк, билгеле...

Флора ханым, беренче эш итеп, фотографияләр белән бүлешкән икән. Аннан берәмтекләп калган экспонатларны туплаганнар. Акрынлап-акрынлап, аз-азлап. Шуңа Люция ханым һәрберсенең тарихын белә, җентекләп сөйли.

Бакый Урманченың туган төбәгендәге музей-йорт. Булачак рәссам 10 яшенә кадәр яшәгән йорт нигезе сакланмаган, аның урынында хәзер мәктәп бинасы.



Бакый Урманче музей-йортындагы татар сәнгатенең күренекле әһелләрен гәүдәләндерүче сыннар.

PRESSA.RU

Бакый Урманченың якташлары: Рафик Нугманов, Буа Төбәк тарихы музееның директоры Люция Әхмәтҗанова, Буа районы мәдәният идарәсе җитәкчесе Мөдәррис Гайфуллин.

– Ә уникаль экспонатлардан нәрсәләр бар? – дип төпченәм.

– Күл Черкене авылындагы музей-йортка без үлгәннән соң Бакый Урманчедан ясатып алынган масканы урнаштырдык. Ул бары тик бездә генә. Шулай ук рәссамның уң кулының күчермәсе. Айдар безгә аның яраткан, шуның артына утырып яза, эшли торган имән өстәлен дә тапшырды. Әмма ул иләмсез зур, авыр, әллә никадәр тартмалары бар аның. Бу почмакка сыйдыра алмадык үзен, ул әлегә фондта саклана, киләчәктә, бәлки, аны да матур итеп кайдадыр урнаштырып куя алырбыз.

Бакый аганың эш кораллары бездә аеруча зур кызыксыну уятты. Оста гадәти карандашлар, пумалалар, кечкенә көрәкчекләр белән генә канәгатьләнеп калмыйча, кайбер коралларны үзенә яраштырып та эшләгән. Әйтик, берничә карандашны сүс белән кысып бәйләп, бергә укмаштырып куйган. Йә булмаса, кайбер пумалаларның башларын йөнтәсләп чыккан. Күрәсең, алар нәкъ менә шундый хәлдә генә рәссам күзаллаган дөнья сурәтен киндердә бар нечкәлегендә чагылдыра алганнар. Сыннарны чокый торган кораллар да бар музейда – алар, шулай ук, махсус киндергә төреп куелганнар һәм кадерләп саклананалар.

– Бу эш коралларының бездә булуына ничек сөенгәнебезне белсәгез, – дип елмая Люция ханым. – Күрегез әле! Кайберләренең буяулары да юып төшерелмәгән, катып калганнар. Ягъни, алар Бакый ага кулында ничек соңгы тапкыр булганнар, шул килеш саклаcналар да...

Музей экспонатлары кагылгысыз булса да, Люция апа миңа пумалаларга орынып карарга рөхсәт бирә. Чынлап та, дулкынландыра...

– Бигрәк тә балалар тәэсирләнә, аларны күргәч, – ди Люция апабыз. – Аларга шәхси әйберләрне күрү кызык бит. Мәктәпләрдә аның картиналарын, сыннарын презентацияләр аша күрсәтәләр, билгеле. Ә музейга килгәч, аларның бу мәшһүр рәссамның креслосын күреп исләре китә, пумалаларын... Шәхеснең үзеннән калган шәхси детальдән, әйберләрдән дә көчлерәк корал юк музейда...

Рафик абыйның хатирәләрен тыңлыйбыз да, беренче каттагы сыннар янынннан ишеккә узабыз. Киләсе тукталыш – Бакый аганы исән чагында күреп-белеп калган, заманында Күл Черкене мәктәбендә математика укыткан, директор булып эшләгән Минислам абзый йорты. Сыннар безне сабыр-уйчан карашлары белән озатып кала. Люция апа, кинәт кенә исенә төшергәндәй, ачыклык кертә:

– Нәкышьче дип атарга куша иде Бакый аганы Флора ханым, сынчы дип түгел. Сыннарга караган саен, бу сүзнең матурлыгына ныграк төшенәм. Шулай атыйбыз да...

«КЕШЕЛӘРНЕҢ ГОЗЕРЕН ТЫҢЛАСАҢ, ҮЗЕҢНЕ ДӘ ХӨРМӘТ ИТӘРЛӘР»

Рафик Нугманов, хәзерге көндә лаеклы ялда:

– 1976 елда Кама Тамагы районының Олы Карамалы урта мәктәбенә директор итеп билгеләндем. Бу мәктәпне үз вакытында бик күп атаклы шәхесләр тәмамлап чыккан. Мин эшләгән чорда мәктәпкә 11 авылдан килеп укыйлар иде. Ул авылларның берсе – Кече Салтык. Нәкъ шушы авылда Бакый Урманченың әтисе Идрис абый яшәгән. Кече Салтык авылы зур түгел, әмма табигате гаҗәеп матур: авыл эчендә бик тәмле сулы ике чишмә челтерәп ага. Авылны икегә бүлүче кечкенә елгасы да бар. Кече Салтык авылы үзенең табигате буенча Күл Черкене авылына охшаган. Бәлки, шушы ике авылның – әтисе яшәгән һәм балачакта Бакый ага килеп йөргән Кече Салтыкның һәм ул дөньяга килгән Күл Черкененең – табигатьләре бәләкәй авыл малаена бөек рәссам сәләтен биргәндер дә.

Еллар узгач, миңа яңадан туган ягыма кайтып төпләнергә насыйп булды. Ул чакта мин инде Ленин орденлы «Татарстан» колхозына парторг булып билгеләндем. 1986 елда Казанның икенче республика хастаханәсендә дәваланырга туры килде. Ул чакта миңа 33 яшь иде. Һәм иң гаҗәбе: биредә мин Бакый аганы очраттым. Шулай ук анда танылган җырчы Вафирә Гыйззәтуллина, бөек композитор Рөстәм Яхин да дәвалана иделәр ул чакта. Әле дә күз алдымда: радиодан үзе язган республика гимны яңгыраганда, Рөстәм ага Яхин, аның каршысына басып, дикъкать белән гимнны тыңлый иде. Вафирә Гыйззәтуллина безнең якларда гастрольләрдә булуын, Иске Суксуда булган концерт мизгелләрен, хәтта мине хәтерләвен дә сөйләп шатландырды.

Бакый аганың палатасы аерым булса да, ул безнең белән арлашырга ярата иде. Миңа, яшь җитәкче буларак, халык белән нинди мөнәсәбәттә булырга икәнлекне дә аңлатты хәтта. Төп киңәше шул иде аның: кешеләрне ихтирам ит, аларның гозеренә колак сал, халыкка якынрак бул, шул чакта гына синең үзеңне дә һәм җитәкче, һәм шәхес буларак олыларлар.

Аның янына килүчеләр бик күп иде, ул һәрвакыт игътибар үзәгендә булды. Буш вакытларда кулындагы карандашы белән ак кәгазьгә

нәрсәдер ясый иде. Карандашының гаҗәеп пөхтә итеп очланган булуы, ясаган рәсемнәре әле дә күз алдымда тора.

Безнең белән шул ук вакытта Кече Салтык авылында күп еллар дәвамында колхоз рәисе булып эшләгән Газиз абый Иштерәков та дәвалану курсы узды. Алар Бакый ага белән бик озаклап сөйләшеп утыралар иде. Хәзер уйлыйм: бәлки, алар бергә уйнап үскән булганнардыр. Газиз абый да 1901 елда туган кеше иде бит. Шуны да әйтеп узасым килә: Кече Салтыклар бөек рәссамны үзләре авылында үскән дип сөйләргә яраталар, гәрчә Бакый ага тумышы белән Күл Черкене авылыннан булса да.

«БИК ӘЙБӘТ МӘКТӘП ТӨЗЕГӘНСЕЗ»

Минислам Җамалетдинов, хәзерге көндә лаеклы ялда:

– 1967 елда, озак вакытлар күренми торганнан соң, Бакый ага, ниһаять, туган авылына кайтып төшә. Аның үз кече ватанына ни өчен озак кайта алмавының сәбәпләре барыбызга да яхшы билгеле… Күл Черкене халкы кадерле якташларын күрергә бик шат булалар, әлбәттә. Мин бу вакыйгага үзем шаһит булмадым-булуын, шулай да искә алып сөйләгәннәрен яхшы хәтерлим. Тулы бер митинг булды ул, диләр.

Бакый ага туган авылына буш кул белән кайтмый – мәктәпкә үз куллары белән ясаган Галимҗан Ибраһимов бюстын алып кайтып бүләк итә. Ул чактагы мәктәп әле элеккеге мәчет бинасында урнашкан була. Хәзерге мәктәп исә өлешчә Бакый аганың туган нигезе урынында урнашкан. Галимҗан Ибраһимов бюсты яңа мәктәптә – татар теле һәм әдәбияты кабинетында саклана.

Икенче кабат Күл Черкенәнә кайтуына мин инде үзем дә шаһит булдым. Бу, хәтерем ялгышмаса, 1974 елның җәе иде. Бакый ага туган тиешле егет белән кайтты да, балачак дусты Шәйхетдин абзыйларда тукталды. Авылда ул ике көн булды. Авылны урап йөргәне хәтердә калган. Һәм менә, мәктәпкә дә килеп чыкты.

Кабинетларны карап йөрде. Татар теле һәм әдәбияты кабинетында озаграк булды: стенага эленгән язучыларның портретларына күз йөртте, үзе бүләк иткән Галимҗан Ибраһимов бюсты каршында уйланып басып торды. Аннары, елмаеп, болай диде: «Бик әйбәт мәктәп төзегәнсез, эшләрегез дә уң булсын».

Мәктәп бакчасында балалар мәш килеп эшләп яталар – җәйге практика вакыты иде ул. Бакый абый балалар янында тукталды: «Укулар ничек бара? – дип сорады алардан якташ абзыйлары. – Мәктәбегез менә дигән, мондый мәктәптә гел «дүртле» белән «бишле»ләргә генә укыйсыздыр, шулай бит?» Кыюрак малайлар шунда ук ярып та салды: «Әй, «өчле»ләр дә булгалый инде абый». «Кара син аны! – дип гаҗәпләнгән булды Бакый ага. – Мондый мәктәптә «өчле»гә уку бер дә килешми…»

Бик якты, ягымлы, шул ук вакытта сабыр, салмак кеше булып хәтердә калды Бакый ага. Аңарда һич кенә дә каударлык юк иде, аны бу сабырлыкка язмышындагы сөрген еллары да өйрәткәндер, күрәсең. Тагын – гадилек. Кешене олылый белү. Юкса ул чакта бит инде ул Татарстанда гына түгел, ә бөтен Россиядә, союздаш республикаларда да танылган олпат, иҗаты бәяләнгән шәхес иде. Ә менә янында басып торасың, үзеңне аңардан түбән итеп тоймыйсың. Чын интеллигент, кыскасы.

1. Бакый Урманченың үлеменнән соң алынган маска һәм уң кулының күчермәсе. Бу уникаль экспонатлар Бакый Урманченың Күл Черкене авылындагы музей-йортында саклана.

2. Останың эш кораллары һәм буяулары.

3. Бакый Урманче эш коралларын үзенчә камилләштерергә яраткан.

4. Бакый Урманченың Соловецк лагеренда сөргендә булганда файдаланган шәхси әйберләре – лагерь формасы, кружкасы һәм туркасы.

PRESSA.RU

Кул Черкене авылындагы музей-йортның макеты.

Бакый Урманченың Кул Черкене мәктәбенә бүләге – Галимҗан Ибраһимов сыны.

«БЕЗ БИТ БРАТЛАР, БАКЫЙ АГА!»

Кул Черкене авылына килеп төштек тә, музей-йортка аяк бастык. Безне Буада каршы алып сәламләгән, аннан, комачауламыйм, сезне авылдагы музейда көтәм, дип, күз ачып йомганчы юкка да чыккан Буа районы мәдәният идарәсе җитәкчесе Мөдәррис Гайфуллин белән Кул Черкене авыл җирлеге башлыгы Исмәгыйль Хәбибуллин инде көтәләр иде. Кадерле кунаклар кебек ихтирам белән каршылаулары, озата йөрүләре хәтердә Рафик абый Нугманов сүзләрен яңартты: «Кешеләргә игътибарлы булсаң, алар да сине хөрмәт итәрләр».

ШУЛАЙ БЕРВАКЫТ...

Исмәгыйль Хәбибуллин,
Кул Черкене авыл җирлеге башлыгы:

– Мин Бакый аганың кем икәнлеген аңлар дәрәҗәдә булмаганмын инде, кургән чакта. Әле бит 4 нче класста гына укый идем. Берзаман безне линейкага җыеп алдылар. Мәктәпкә Бакый Урманче белән Ренат Харис очрашуга килгәннәр икән. Нәкъ менә шул килүендә Бакый ага мәктәпкә Галимҗан Ибраһимов бюстын бүләк итте дә. Галимҗан Ибраһимовны да юньләп белми идек әле ул чакта. Бакый аганы яхшы хәтерләмим, ләкин очрашудан бик рәхәт, җылы тәэсир калган иде.

Фиргать Хәсәнов,
Кул Черкене мәктәбендә хезмәт укытучысы булып эшләгән, хәзерге көндә лаеклы ялда:

– Мин 7 нче классны бетереп килгән чак иде ул. Әтием Әгъзам Гыйләҗ улы Хәсәнов – колхоз рәисе. Берзаман авылга кино килде. Шунда таштан чокып ясый торган нәрсәләрне күрсәттеләр. Ул чакта без әле боларның скульптура икәнен дә белмибез. Мин шулкадәр кызыктым аларга! Үзем дә ясап карарга булдым. Таш балталар ясадым, аны мәктәпкә дә алып килдем. Алар аннары мәктәп музеенда сакланды да әле.

Тәмам илһамланып китеп, тау буена барып, олы бер таш алып кайттым да Геракл башы ясап куйдым. Гераклны тарих дәреслегеннән укып беләм, бик ошап калган иде ул персонаж миңа. Һәм менә авылга Бакый абый кайткан дигән хәбәр таралды. Әти аны безгә чәй эчәргә алып кайтты. Әти, чәйләп алгач, Бакый абыйга әйтә: «Менә минем төпчек малай таш кисү белән мәш килә, ниндидер баш та ясап куйды, карамассыз микән?» – ди. «Әйдә, карыйк!» – дип, шунда ук ризалашты Бакый абый. Карап керделәр дә, Бакый абый әтигә әйтә: «Бу малаеңны миңа бир әле, мин моннан скульптор ясыйм», – ди. Әмма безнекеләр мине яшь булгач, бигрәк тә төпчек тә булгач, чыгарып җибәрмәделәр инде...

Мөдәррис Гайфуллин,
Буа районы мәдәният идарәсе җитәкчесе:

– Бакый ага белән аның өендә дә, остаханәсендә дә берничә кат очрашып-аралашу бәхете тиде миңа. Хәзер аңлыйм: бу зур бәхет булган икән. Казан дәүләт культура институтында укыганда, Бакый Урманче иҗаты буенча реферат язарга алындым. Беренче тапкыр өенә барганны әле бүгенгедәй хәтерлим. Шүрләтә, билгеле, бөтен кеше дә ихтирам иткән, күренекле, олы шәхес янына барасың бит. Әмма Бакый ага бик гади, җайлы, ачык кеше булып чыкты. Әле шалтыратып, килергә рөхсәт сораганда ук: «И, якташ икәнсең, кил, әйдә, кил, кабул итәм, билгеле», – дип күңелне җылытты.

Мин остаханәсенә килгәндә, ул ниндидер олы бер картина язып маташа иде. Тулы бер стенаны алып торган ул киндер нәрсә булды икән, тарихи картиналарыннан берсе булырга тиеш. Күптән белгән танышын каршылагандай: «Әйдә, җегет, уз, без бит якташлар, оялып торма», – дип, иңемнән кагып куйды. Шуннан мин тынычланып калдым. Сөйләшеп утыра торгач, батыраеп китеп, шаяртып та алдым әле хәтта: «Бакый абый, – дим, – без бит сезнең белән братлар». Бакый абый гаҗәпләнеп куйды: «Ничек ул алай – братлар, энекәш?» – ди. «Соң, мин әйтәм, без бит икебез дә – Идрис уллары, ә авылда без – икәү генә». Бу сүзләремнән соң, и рәхәтләнеп көлгән иде Бакый ага. Көлүе рәхәт иде аның – ихлас, иркен...

Әмма эш мәсьәләсендә бик таләпчән булып хәтердә калган. Рефератны берничә тапкыр язып чыгарга туры килде. Җентекләп укый, һәр нәрсәгә игътибар итә, аннан сызып-төзәтеп, шул урыннарын яңадан язарга куша иде. Эшнең җиренә җиткереп башкарылуын ярата иде Бакый ага, кыскасы. Мин гаҗәпләндем аңа ул чакта: гап-гади бер студентның гап-гади рефераты бит инде, аңа әллә ни әһәмият бирмәсә дә була. Зур дәрес булды бу очрашулар. Эшемне башкарып чыккач, Бакый ага, ниһаять, кулын куеп, хуплау сүзләрен язып куйды рефератка.

«ЕГЕТКӘЙ ЧАКЛАРЫМ АЙ БАР ИДЕ ЛӘЙ...»

Гөлнур Гыйниятуллина,
мөгаллимә, шагыйрә:

Университетта укыган елларым гаҗәеп истәлекле очрашулар белән истә калган. Каләм тибрәткәнемне укырга кергәнче үк белгән остазым Мөхәммәт абый көннәрдән бер көнне үз янына чакырды: «Әдәби сүз»дә каләмең дә чарланыр, иҗат өчен дә файдасы булыр, бик кызыклы очрашуга җибәрәм, Гыйниятуллина. Бар да, күр, шәп материал язарлык булсын!» – диде. Кулыма уч төбенә генә сыярлык блокнот битенә язылган адрес та тоттырды.

Бара торган җиремнең кайда икәнлеге язылган, тик кем белән очрашу хакында Мөхәммәт абый берни әйтмәде. Адрес буенча килдем дә, беренче каттагы звонок төймәсенә бастым. Бер... ике... өч... Ачучы юк. Тагын басам. Бер... Шулчак ишекнең теге ягында чылбыр чылтыраган тавыш ишетелә. Ишек ачыла, каршымда казакъ хатын-кызларына охшаш кысыграк күзле, чем-кара чәчле, түгәрәк кенә сипкелле йөзле бер ханым пәйдә була.

– Вам кого? – дип сорый.

Мин бераз аптырабрак карап торам, ишек төбендә кемне сорарга да белмичә басып торам.

– Мине Мөхәммәт абый Мәһдиев җибәрде, – дим, авыз эчемдә ботка пешереп.

– Ә, Бакый, бу кыз сезнең яныгызга бугай! Сез кичә остаханәне җыярга ярдәмче кирәк дигән идегез бит... Узыгыз!

Бүлмә тулы агачтан, гипстан эшләнгән бихисап сыннарны күреп, һушым китеп торганда, күн алъяпкыч япкан озын буйлы, башына юка гына түбәтәй элгән берәү, авыз эченнән нидер көйләп, каршыма килеп чыга.

Йа Ходам! Соң бу бит Урманченың үзе! Ну, Мөхәммәт абый, әйтсә ни була инде, Бакый ага янына барасың, кызый, дисә?! Мин олпат гәүдәле рәссамга карап телсез басып торганда, тынлыкны Бакый ага үзе боза:

– Йә, сеңелкәш, сине кем дип белик?

– Мине... мине... Мөхәммәт абый җибәрде, – дип, көчкә телемне әйләндерәм.

– Ә, Мөхәммәт белән кичә сөйләшкән идек шул, чит илдәге картиналар галереясы турында. Минем соңгы еллардагы эшләрем белән кызыксынды, студентларын алып килмәкче бугай. Остаханәне бераз тәртипкә китерәсе бар, дигән идем. Мөхәммәт бер-ике кызны җибәрермен, дип ышандырды. Иптәшең кайда?

– Мин үзем генә, Бакый ага! – дим, аптырап.

Рәссам шул урында шаяртырга кирәк тапты:

– Акмыйм бит, менә алдыңда басып торам, сеңелкәш! – диде ул, елмаеп.

Мин ирексездән бу шаян карттан көлеп куйдым.

– Флора апаңнан кирәк-ярак сорарбыз да, эшкә керешерсең, бахыр! – диде ул.

Мин остаханә җыештырырга түгел, ә интервью алырга килгәнлегемне аңлатырга теләдем:

– Мин җыештырырга килүче түгел, Бакый ага, мин газетага материал әзерләргә дип килдем.

– Авыл баласы түгелмени? Чүпрәк, су күргәнең юк инде алайса?

– Авыл кызы мин!

– Соң, авыл кызы булгач, әйдә, Флора апаңнан чиләк белән су алып кил.

Флора апа еракта булмаган, күрәсең, безнең сөйләшүне тыңлап торганмы – бүлмәгә кечкенә генә чиләктә су, берничә кисәк тукыма кертеп куйды.

Сумкамны ишек төбендәге агач урындыкка куйдым да, җиң сызганып эшкә керештем.

– Мин гел туздырам бит монда, тузан, гипс оча... Әнә, Сөембикәне, картны бөтенләй тузан күмгән, сеңелем, эшне шулардан башла. «Сагыш»ның сырларын яхшырак сөрт, – дип, Бакый ага түрдә торган зур агач башка күрсәтте. Күн алъяпкычындагы кесәләргә әллә ничә өтерге-юнгычлар тезгән оста үзе бүрәнә сыман материалда нидер юна, аннары, урындыкка утырып, үзе ясаган бюстларга карап уйлана. Көтмәгәндә генә сорап куя:

– Җырлый беләсеңме?

Мин кулымда корыткыч чүпрәгемне тотып торган хәлдә гаҗәпләнеп аңа карыйм.

Бакый Урманченың «Хәзинә»дәге күргәзмәсе.

– Беләм, Бакый ага. Мин бит университетның татар хорына йөрим.

– Нинди җырлар өйрәтәләр сезгә, сеңелем?

– Күп инде! Русча да, татарча да, инглизчә дә!

– Алай да? Халык җырларын өйрәтәләрме соң? Мөхәммәткә дә әйттем кичә: «Повестьларыңа халык җырларын күбрәк керт, онытылмасыннар»,-дидем.

– Без күбрәк композиторларның әсәрләрен җырлыйбыз, Бакый ага, – дим.

Рәссам, өстәл читендәге чынаягыннан чәен йотып куя да, миңа таныш түгел җырны көйли башлый:

Егеткәй чакларым ай бар иде ләй,
Киң урамнар безгә ләй тар иде ләй,
Егеткәй булып йөргән чакларымда
Шәһәрләр саен ярларым бар иде ләй...

Мин картның, җыр ноталарын сузганда, сары кашлары бер күтәрелеп, бер җыерылып куюына игътибар итәм.

– Бу җырны белмим, бер дә ишеткән, җырлаганым юк, Бакый ага, – диюдән уза алмыйм.

– Шәп җыр бу – «Ончы Фәхри»! – ди оста.

Рәссамга күңеле булсын өчен генә түгел, чын-чынлап соклануымны яшерә алмыйча:

– Бакый ага, яхшы җырлыйсыз, көе дә матур, сүзләре дә, – дим.

Көне буе Бакый ага Урманче остаханәсендә күргәзмәгә барачак сыннарны, картина рамаларын сөртеп-юып, андагы эш коралларына, материалларына таң калып, инде китәргә җыенганда, Бакый ага Флора ападан махсус чәй әзерләтә. Үзе миннән имтихан алырга җыенган мөгаллим сыман сорап та куя:

– Фәхри исеңдә калдымы?

– Җырлыйммы? Тыңлап карагыз! – дип, кыюланып китеп, җырны сузып җибәрәм. Эчемдә ут: «Ни дияр? Оятка калмаммы?!»

– Ярыйсы гына җырлыйсың икән, сеңлем! Син бу җырны хорыңда җырла!

Мин остага җыр өчен дә, остаханә эше белән таныштырган өчен дә рәхмәтләремне әйтеп, китәргә кузгалам. Бакый ага, көрәк кадәр куллары белән алып, учымны кыса:

– Килгәләп йөр!

Остаханәдә җыештырып йөргән шул чагымны еш искә төшерәм. Эч пошканда, мин дә кулыма карандаш-пумалалар алып, ак кәгазьгә иеләм. Шигырь язам. Хәтеремдә Бакый аганың теге җыры еллар узган саен ешрак тибрәлә:

Егеткәй чакларым ай бар иде ләй,
Киң урамнар безгә ләй тар иде ләй...

PRESSA.RU

ҖИРДӘГЕ ИҢ ШӘП УРЫН!

МЕНДЕЛЕЕВСК – БОНДЮГ ЗАВОДЫ ВАРИСЫ

Фото: Ната Смирнова

Менделеевскиның шәһәр буларак яше тиздән түгәрәк сан – 50 гә җитә. Ә «тумышы» белән ул бертуган Ушковларның химия заводы каршындагы Бондюг бистәсенә карый. Бу хәлләр бистә шәһәр статусы һәм дөньякүләм танылган химик исемен алганга кадәр нәкъ йөз ел элек була.

XIXгасырда Россиянең химия сәнәгатенә нигез салучыларның берсе булган Пётр Капитонович Ушков үзенең Бондюг заводын төзегәндә, кайчан да булса завод каршында салына башлаган әлеге бистәнең шәһәргә әверелеп, Петербург университеты профессоры, атаклы химик Дмитрий Менделеев исемен йөртә башлар, дип уйлап карадымы икән? Әлбәттә, юк. Ләкин 1967 елда картада Менделеевск торак пункты пәйда була. Һәм юктан гына түгел. Эш шунда ки: 1893 елда Бондюг заводында бөек химик Россия өчен чыннан да бөек эш башкара. Аның җитәкчелегендә биредә 500 пот (8 тоннадан артык) күләмендә төтенсез дарының беренче сынау партиясе алына. Заводтан китер алдыннан Дмитрий Иванович улы Владимирга «мондагы халык бик яхшы, эшне дә тиз һәм җитез алып бара, заводның алга китеше дә гаять зур...» – дип, цех төзелеше турындагы тәэсирләре турында яза.

Бүген дә элеге уңган һәм җитез менделеевлыларның горурланырлыклары бар: 22 меңнән артык халкы булган шәһәрчекнең берүзенә ике химия предприятиесе!

Бу якларда язучы Борис Пастернак та булып киткән. 1916 елда ул бирегә гаилә дусты, булачак күренекле химик Борис Збарский чакыруы буенча килә һәм ярты еллап яши.

Бер сүз белән әйткәндә, дуслар, химияне өйрәнегез! Татарстаныбызны яратыйк – ул бит кызыклы һәм могҗизаи вакыйгаларга, гаҗәеп язмышлы шәхесләргә бай!

PRESSA.RU



ЮНОСТЬ
1941
1945
Великая
стена

PRESSA.RU





МЕНДЕЛЕЕВСК:
КҮР ӘЛЕ,
СИН ЯШӘГӘН
ДӨНЬЯ НИНДИ
МАТУР!



ИГЕЛЕКЛЕ ЭШЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Катлы бәлеш **НИЧЕК** әзерләнә

Татарстанның төп хатын-кызлары **НИНДИ** чәчәкләр ярата

Ренат Ибраһимов **НИНДИ** «сериал» төшерә

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН»
МАХСУС
журналы өчен
15:19
Electrolux
Журнал
ТАТАРСТАН
к народам всего мира
Татарстан
ТАТАРСТАН
ЖИЗНЬ
ЛЕНИНА
и история РИП(б)

«МИЛЛИ РИЗЫКЛАРЫБЫЗНЫ ДӨНЬЯГА ТАНЫТАСЫ ИДЕ...»

Без язны гүзәл затлар белән чагыштырырга яратабыз. Шуңа да бу санда дистә еллар дәвамында телевидениедә «Тәмле булсын» сәхифәсен алып барган Ризидә Хөсәенованы чакыруыбыз очраклы түгел. Газета-журналларда даими рәвештә тел йотарлык рецептларын да тәкъдим итеп килә ул. Безгә исә катлы бәлеш пешерү серләрен ачты.

Ризидә Хөсәенова – Татарстанның атказанган халыкара хезмәт күрсәтү өлкәсе хезмәткәре, «Тәмле булсын» китабы авторы. Аның пешерә белмәгән ризыгы юк. Шулай да милли ашларга өстенлек бирә Ризидә ханым. Алай гына да түгел, татар ашларын чит илләргә барып та таныта ул.

– Кайсы илдә генә булмадым, – ди танылган аш-су остасы. – Әле менә Майамига Сабантуйга җыенам. Андагы милләттәшләргә өчпочмак, бәлеш, токмачлы аш пешерәчәкмен. Чит илдә милләттәшләребез бу ризыкларны бик әзерләми. Аларга ул бик кадерле.

Беренче эш итеп, Ризидә апа бәлеш өчен сөтне җылытырга, майны эретергә куйды.

– Сөтнең җылы булуы мөһим, – диде ул.

Болай итсәң, камыр тизрәк кабара, үзле була икән. Бәлеш өчен әчлекне без килгәнче әзерләп куйган иде: лимоннарның төшен алып, кабыгы белән иттарткычтан чыгарган. Аннан шикәр комы салып, талгын гына утта пешергән. Җимешләрне шулай ук иттарткычтан чыгарып, утка куеп алган иде.

«КАМЫР САВЫТТА КАЛЫРГА ТИЕШ ТҮГЕЛ»

Ризидә апа – мишәр кызы. Кулында ут уйната, диләр аның кебекләр турында. Аш-су өлкәсеннән кала төрле конкурсларда, хәйрия чараларында катнаша. «Нечкәбил – 2008» бәйгесенең җиңүчесе. Буа районының Вольный Стан авылында туып-үскән ул. Гаиләдәге җиде баланың алтынчысы.

– Туган авылымдагы концертлар миннән башка узмый иде, – ди Ризидә апа. – Алып та бардым, җырладым да. Мәктәпне тәмамлагач, сәнгать юлын сайлыйсым килде. Ләкин әти кырт кисте: «Артист кешенең шәхси тормышы булмый. Әнә, бик оста пешерәсең, пешекчелеккә укы», – диде. Шуннан Казан кооперация техникумына укырга кердем. Кулга диплом алганнан соң, туган ягыма – Буага кайттым, кондитер булып эшләдем. Көненә меңәр өчпочмак ясый идем. Башкаларга караганда эшемне күпкә алданрак тәмамлагангадыр, мөгаен, мине бригадир итеп куйдылар. Ләкин туган ягымда озак эшләргә насыйп булмады. 1982 елда Фаязыма кияүгә чыктым.

Аның белән очраклы рәвештә поездда таныштык. Өч ай дигәндә өйләнешеп тә куйдык, «Майский» совхозына киттек. Ирем шунда эшли иде. Мин дә совхозның ашханәсенә урнаштым. Озакламый бер-бер артлы ике улыбыз – Фаил, Наил туды.

Ул арада Ризидә апа камыр куярга кереште. Башта савытта йомырканы туглады, аннан сөт, шикәр комы, тоз салып болгатты. Шуннан чүпрә өстәде.

– Чүпрәнең юешен яратам, аның белән камыр әйбәтрәк чыга, – дип аңлатты ул безгә. Һәм он салып камыр баса башлады. Иң кызыгы: эретелгән сыер мае белән сыек майны Ризидә апа соңыннан, камырны әвәләгәннән соң гына салды.

– Май салгач, янәдән озак итеп басарга кирәк. Камыр савыт кырыйларына ябышып калырга тиеш түгел, – диде.

Элегрәк татарлар, яшь киленне тикшереп карар өчен, аңа ипи пешертеп сынаганнар. Әгәр камыр савыт кырыена ябышып калмый икән, димәк, килен уңган, ипи дә тәмле булачак, дип саналган.

Автор:
Руфия Фазылова

Фото: Луиза Янсуар

Редакция кухнясы

РИЗИДӘ ХӨСӘЕНОВА РЕЦЕПТЫ:

Камыр өчен:
1. Сөт – 1 стакан
2. Йомырка – 2 данә
3. Ак май – 100 г
4. Шикәр комы – 2 аш кашыгы
5. Тоз – тәменчә
6. Чүпрә – 20 г
7. Сыек май – 1–2 аш кашыгы
8. Он – 500 г

Эчлек өчен:
1. Кара җимеш – 200 г
2. Сары җимеш (көрәгә) – 200 г
3. Лимон – 3 данә

СЫНАУЛАРГА БИРЕШМИЧӘ...

Аш-су остабыз савытның өстен ашъяулык белән ябып, камырны кабарырга куйды. Ул арада Ризидә апа ничек итеп үз эшен башлавы турында сөйләде.

– Шактый болгавыр заманда – 1990 нчы елларда АТП ашханәсенең бер почмагын арендага алып, төрле камыр ризыклары пешереп саттым. Аннан пешергән ризыкларны машинага төяп, кибетләргә таратып йөрдек. Бик авыр иде, очсыз-кырыйсыз тикшерүләр... Берсен озатып чыгарасың гына, икенчесе килеп керә. Кычкырып елаган вакытлар да күп булды. Ашчыларга хезмәт хакы бир, аренда түлә... Түздем инде. Боларны үткәреп җибәрсәм, аннан җиңелрәк булыр, дип уйладым. Берничә ел тәҗрибә туплагач, арендага Зинин урамындагы бер кафены алдым. Ләкин аренданың бәясе бик зур, йөз меңнәр белән исәпләнә. Ничек тә үзебезгә бер бина салырга кирәк, дип уйлап йөри башладым. Шулай итеп 2010 елны Осиново бистәсендә үзебезнең ресторанны булдырдык.

Ирем Фаяздан башка боларны ерып чыга алмас идем, бөтен уй-ниятемне хуплап торды, бик нык ярдәм итте. Уң кулым да, киңәшчем дә ул булды. Кайткан җиремә кайнар ризык пешкән, чәй кайнаган булыр иде. Кайбер ризыкларны аның кебек мин дә пешерә белмим.

Әле ярый, эшем бар, дип сөенәм. Балалар үз юлын тапты, оныклар үсә, дип шатланам. Аллага шөкер, Фаил белән Наил кечкенәдән мөстәкыйль булып үстеләр. Ваннага буйлары җитмәгән килеш, үз оекбашларын үзләре юдылар. Мин эшкә киткәндә балаларга ниләр эшлисен язып калдыра идем. Мәктәптән кайткач, әрле-бирле йөрмәде алар. Берәр җиргә сатарга барсак, безгә ияреп чыктылар. Ипинең өстәлгә ни рәвешле килгәнен күреп үстеләр. Банкетлар уздырганда да гел булыштылар. Олы улыбыз Фаил үзенең икмәк пешерү челтәрен оештырды. Киңәшләшеп эшлибез. Кече улыбыз – дәүләт хезмәтендә. Киләчәктә ресторан-кафелар челтәрен аларга калдырсам, рәхәтләнеп икесе дә монда эшли алачак.

«ТАТАРСТАН» БӘЛЕШЕ

Ул да булмады, камыр әзер дә булды. Аны Ризидә апа дүрткә бүлде: бәлешнең түбә өчен – зуррак өлешкә, арага кую өчен – ике кечкенә өлешкә һәм өстен каплау өчен тагын бер түгәрәккә. Төпкә дигән камырны табаның кырыйларына кадәр чыгарып җәйде. Камырның артык өлешен, уклау белән таба читеннән йөртеп, кисеп атты. Һәм алдан әзерләнгән караҗимеш эчлегеп салды. Беренче каты шулай итеп әзер булды. Аннан, кечкенә түгәрәкне җәеп, өстенә сары җимеш эчлеген, ягъни көрәгәне, ә соңыннан, кабат өстенә камыр җәйгәннән соң, инде лимон эчлеген салды. Калган камыр белән бәлешнең өстен каплады.

– Катлы бәлеш пешерүнең әллә ни авырлыгы юк, – диде Ризидә апа. – Иң мөһиме – камырны калын итмәскә, эчлек күбрәк булса тәмлерәк, сусылрак килеп чыга. Кайбер кешеләр табаның тышына чыккан камырны эчкә бөкләп калдыра. Мин алай яратмыйм. Бердән, матур түгел, икенчедән, бәлешнең кырыйларын кабарта. Артык камырны уклау белән кисеп алсаң яхшы. Өстәвенә, кискән өлешен бәлешне бизәү өчен кулланырга була.

Чынлап та, безнең күзләрне сөендереп, артык калган камырдан бәлешнең өстенә «Татарстан» дип язып та куйды. Моның да үз сере бар икән: хәрефләр камырга ябышсын өчен башта өслекне майларга кирәк. Мичкә куяр алдыннан, Ризидә апа «Татарстан» бәлешенең өстенә матурлык өчен май, шикәр комы, оннан ясалган катнашманы сипте. Аннан инде, теләкләрен тели-тели, бәлешне мичкә куйды.

– Камыр ул җанлы әйбер кебек, әйтерсең, каефеңне тоя, – ди Ризидә апа. – Шуңа күрә ризыкны пешерер алдыннан начар уйларны баштан алып атарга кирәк.

ИҢ МӨҺИМЕ – ҮЗЕБЕЗНЕКЕ

Бәлеш пешкән арада Ризидә апа зур сөенече белән дә уртаклашты: 2017 ел башында «Татар мәдәнияте һәм ашлары халыкара ассоциациясе» булдырганнар. Аның максаты – татар аш-су осталарын бергә җыю, гомумән, милли ризыкларыбызны киң җәмәгатьчелеккә таныту.

Чит илләргә еш йөргәч, шуңа игътибар итә идем: күп кенә милләтләрнең аш-су осталарының ассоциацияләре бар, ни өчендер татарныкы гына юк, – ди Ризидә Хөсәенова. – Бервакыт, Венадан кайткан вакытта, ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары Римма ханым Ратникова белән дә шул хакта сөйләштек. Эш сүздә генә калмады, тиз арада ассоциациянең эш планын булдырып, рәсми документларны тәртипкә китердек. Татар аш-су осталары бөтен Россия Федерациясе буенча таралган. Безгә бер-беребезне күреп, аралашып, хәбәрләшеп яшәргә кирәк. Милли ризыкларыбызны әзерләү буенча аерым конкурслар, чаралар үткәрергә

ният бар. Кыскасы, дөньяда безнең өчпочмак, бәлешләребез барлыгын белергә тиешләр.

Ассоциациянең җитәкчесе буларак, Ризидә Хөсәенова, иң беренче чиратта, яшьләр белән эшләргә уйлый. Аш-су осталары әзерләүче никадәр көллият, техникумнар бар, ә аларның берсендә дә милли ризыклар әзерләргә өйрәтмиләр икән.

Яшьләрдә татар ашларына карата кызыксыну уяту максатыннан, февральдә яшь пешекчеләр һәм аш-су осталары арасында «Татар гаиләсе» бәйгесен үткәрдек, – дип сөйләде Ризидә апа. – Казанның һәм республиканың башка шәһәрләре, районнарының техник югары уку йортларында, көллиятләрендә укучылар җыелды. Һәр катнашучы берәр милли ризык әзерләп килде. Башкалар алдында ризыкны пешерү серләрен сөйләделәр. Соңыннан, җиңүчеләрне билгеләп, затлы бүләкләр тапшырдык. Мондый бәйгеләрне ел саен үткәрергә ниятлибез. Бәйгенең географиясен дә киңәйтәсе иде – Россиянең төрле төбәкләреннән яшьләрне катнаштырасыбыз килә. Булачак аш-су осталары үзара танышсыннар, аралашып яшәсеннәр, тәҗрибә уртаклашсыннар, дим. Кызганыч, тәҗрибәле рестораторлар да бүген бер-берсе белән белешми. Бу вазгыятьне үзгәртәсе иде.

...20 минут чамасында «Татарстан» бәлешебез пеште. Азрак суынгач, Ризидә апа аны бүлеп тәлинкәләргә куйды. Мәтрүшкәле чәй белән яңа пешкән катлы бәлештән авыз итәбез... Гаҗәеп тәмле... Камыры нәзек, йомшак, шикәрләнеп тора. Эчлеге күп булгангамы, авызда эреп китә. Кибет тортларыннан йөз кат тәмлерәк. Берәр кунак килсә яки бәйрәм булса, һичшиксез, катлы бәлеш пешерегез. Аның әллә ни авырлыгы да юк, ә иң мөһиме – үзебезнеке!

1. Җәябез!

2. Табага урнаштырабыз!

3. Эчлекне салабыз!

4. Таратабыз!

5. Катларын җәябез!

6. Каплап бөрәбез!

7. Пешерергә әзерлибез!

8. Табынга чыгарабыз!

Шулай бервакыт эшләрем белән тыз-быз килеп йөрим. Фаяз шалтырата: «Ризидә, эшләрең беттеме әле?» – ди. «Юк әле, Фаяз», – дим. Яз иде ул, агачларның шау чәчәккә күмелгән чагы... Шулчак Фаяз әйтә: «Кайт әле, Ризидә, бакчада йөрим, алмагачлар шау чәчәктә, икәүләшеп йөрисе килә...» Кырык эшемне ташлап, кайтып киттем өйгә. Телефон шалтырый, әзлиләр. Мин әйтәм: «Менә, Фаяз белән бакчабызда алмагачларга сокланып йөрибез әле...» – дим. Шул алмагачлар шаулап торган көнне һич онытасым юк! Күңеле сизгәндер, күрәсең... Бер айдан 32 ел бергә гомер иткән газиз ирем якты дөньядан китеп барды...

PRESSA.RU

www.protatarstan.ru
ТАТАРСТАН
Әһәмиятле
Игелекле
Мәңгелек
Кеше бар яктан да белемле һәм киң карашлы булырга тиеш.
сайттагы яңалык
яңалыклар
WWW.PROTATRSTAN.RU
Реклама 16+

Фото: Ната Смирнова. Флорист: Елена Троицкая

ТАТАРСТАННЫҢ *төп* ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

«Татарстан» журналының махсус проекты безгә матурлыкны барлык сирпелешендә тәкъдим итә. Яз бит – елның төп фасылы, ә хатын-кызлар – аның төп бизәге, чәчәкләр исә – туташ вә ханымнарның иң яраткан бүләге. Матурлыкны шулай бер бәйләмгә җыйдык та, гүзәл затларга дүрт сорау бирергә булдык. Һәм менә, журналыбыз битләрендә – аларның ихлас җаваплары белән яраткан чәчәкләре.



PRESSA.RU

ТАТАРСТАННЫҢ *төп* ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

“ АҢЛАУ ҺӘРКЕМ ӨЧЕН КУЛАЙ БУЛГАН КАРАРЛАРГА КИЛҮНЕ ҖИҢЕЛӘЙТӘ

Талия Миңнуллина,

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИНВЕСТИЦИОН ҮСЕШ АГЕНТЛЫГЫ ҖИТӘКЧЕСЕ

1. **Һәрбер хатын-кызныкы кебек үк, чәчәкләргә мөнәсәбәтем уңай.** Үзем дә еш кына бүләк итәм аларны. Иң мөһиме нәрсә? Чәчәкләрнең бүләк ителгән кешегә нинди хисләр һәм уйлар җиткерүе. Шуңа да, минемчә, нинди төрдән булуы әллә ни мөһим түгел, беренче урында – игътибар. Билгеле, һәр хатын-кызның өстенлек биргән чәчәкләре була. Минем очракта – иң экзотик чәчәкләр. Мәсәлән, күке яшенең (орхидея) сирәк төрләре, такка шантрье һәм тагын шундыйрак хикмәтләр. Шулкадәр төрле булулары мине планетабызның муллыгы, байлыгы турындагы уйларга этәрә. Икенче урында, әлбәттә, кыр чәчәкләре: күкчәчәк, ромашкалар. Алар самими. Игелек бөркелә үзләреннән. Һәм кем дә кем, кыр буйлап атлап барганда, аларга юлыкса, шунда ук үзе дә ягымлырак һәм игелеклерәк булып әвереләдер шикелле.
Шулай да чәчәк сайлаганда иң мөһим фактор – ул нәрсәгәдер өмет итмичә, ихластан кешенең күңелен күтәрергә теләү.

2. **Җаваплылык бик күп тапкырга артты.** Дәүләт дәрәҗәсендә кабул ителә торган карарлар, Президент биргән күрсәтмәләрнең үтәлеше, кул астында эшләгән кешеләрнең куйган хезмәте – барысы өчен дә җавап бирәсең бит. Үсеш темплары да кызуланды, чөнки инвестицион проектларның тормышка ашырылуы төрле тармаклар буенча зур күләмдәге мәгълүматка ия булуны таләп итә: медицина һәм төзелештән башлап, нефть химиясе белән машина төзүгә кадәр. Мәгълүматның таралу мәйданы киңәйде. Аралашу кыры да, әйтик, минем эш өлкәсенә караган элемтәләрем олы бер халыкара челтәрне тәшкил итә. Моның тискәре яклары да бар, билгеле. Эчке резонанс барлыкка килде: никадәр генә ярдәмчел кеше булсам да, җитәкче вазыйфасында, миңа йомшарып, нечкәреп утырырга ярамый, кайберәүләр, каты тормасаң, гомумән эшләмәскә мөмкин бит. Икенче күңелсез фактор: янәшәмдә ихлас затлар кимеде, шуңа да мин әле бу вазыйфага кадәр үк дус саналган һәм шушы көнгәчә янымда булган кешеләрне икеләтә кадерлим хәзер. Димәк, алар алга таба да минем белән булачак.
Күпләр югары вазыйфа белән дәрәҗә яхшы бәйләнешләр белән тәңгәл, дип исәпли. Болай уйлаучыларга «Золушка»ның совет экраннарына чыккан фильмындагы король күптән җавап бирде инде: «Бернинди элемтәләр дә аягыңны – бәләкәй, җаныңны – олы, ә йөрәгеңне гадел итәргә булыша алмый».

3. **Беренче кагыйдә: барысы да кире үзеңә әйләнеп кайта – яхшысы да, начары да.** Шуңа күрә күбрәк яхшылык эшләргә кирәк, хәтта күңелсезлек китергән кешеләргә дә игелек белән җавап кайтарырга тырышырга. Икенчесе: әгәр үзеңне беразга гына уеңда башка берәү урынына куеп карасаң, аны бик тиз арада аңларга мөмкин. Ә аңлау һәркем өчен кулай булган карарларга килүне күпкә җиңеләйтә. Өченчесе: мөгаен, максатка ирешү өчен нинди ресурсларны (вакыт, акча, күңел көченң) ничек куллану да мөһимдер.

4. **Бәхет –** нәрсәдер тудыруда, һәр нәрсәдән ләззәт алуда, бүгенге көн белән яшәп, кадерле кешеләреңне кайгырту һәм тормышның тәмен тоюда.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАННЫҢ *төп* ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

“КЕШЕЛӘРНЕ ТЫҢЛЫЙ БЕЛЕРГӘ КИРӘК

Марина Патяшина,

ТР БУЕНЧА БАШ ДӘҮЛӘТ САНИТАР ТАБИБЫ

1. Миңа барлык чәчәкләр дә ошый. Әмма шулай да, лаләләр белән ландышларга аерым бер мөнәсәбәтем бар, алар бит язның килүен хәбәр итүчеләр һәм әйтеп бетергесез нәфисләккә, чисталыкка ия чәчәкләр. Бүлмәдә үсә торган гөлләргә килсәк, күке яшен, үз итәм – аларны әллә ни мәшәкатьләнеп тәрбияләргә дә кирәкми, ел буе чәчәк тә атып утыралар.

2. Җитәкче вазыйфасы күп нәрсәгә өйрәтте, мин элек үземдә барлыгын белми дә йөргән якларымны ачарга булышты. Бу вазыйфа бит үзеңне даими рәвештә үстерүне таләп итә – профессиональ яктан да, җитәкләү осталыгы буенча да. Баштарак чын-чынлап кыен иде: коллективтагы мөнәсәбәтләрне оештыру да, коллегалар, ягъни үзем кебек үк җитәкчеләр белән аралашуны җайга салу да. Профессиональ яктан ялгыш җибәрмәү дә зарур. Һәм әле тагын бик күп нәрсәләр сорала җитәкчедән. Әмма хәзер, инде биш ел дәвамында эшләгәннән соң, хезмәтемнең нәтиҗәләрен, оешкан һәм үз эшен тиешенчә башкарган коллективны күрәм. Эшнең күләме зур булса да, күп кенә катлаулы мәсьәләләрне күрә һәм аларны хәл итү юлларын беләм, бу зур канәгатьлек хисе алып килә.

3. Тормыштагы хәлләр белән идарә итүнең өч төп кагыйдәсе, минемчә, шушылар: намуслы һәм гадел булу, кешеләрне ярата һәм тыңлый белү, шуңа өстәп, үзеңә карата таләпчәнлек. Ә өйдәге төп кагыйдә – якыннарыңа игътибар бирү, балалар белән аралашырга вакытны кызганмау.

4. «Хатын-кыз бәхете», минем өчен, иң беренче чиратта, хатын һәм әни булуда, балаларның тормышында катнашып, аларның уңышларына сөенүдә. Икенче урында – профессиональ эшчәнлегем һәм анда ирешкән уңышларым, әлбәттә.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАННЫҢ
төп
ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

“ҮЗ ВАЗЫЙФАМНЫ КЫЗЫКЛЫ ЭШ БУЛАРАК КАБУЛ ИТӘМ

Розалия Габдуллина,

«КАМА КОММЕРЦИЯ БАНКЫ» ҖЧҖ ИДАРӘСЕ РӘИСЕ

1. Мин бөтен чәчәкләрне дә яратам. Һәр төрнең – үз урыны, үз вакыты. Лалә чәчәкләрен бигрәк тә үз итәм, чөнки алар миңа Урта Азиядә үткән балачагымны хәтерләтә. Яз башында без тауларга барып, беренче лалә чәчәкләре белән хозурлана идек. Кыр чәчәкләре үзләренең табигыйлыгы һәм гадилеге белән сокландыра.
Тирә-ягымны гөл-чәчәкләр уратып алган. Әмма энергетик яктан бигрәк тә орхидеяне үз итәм. Алар да мине якын итә – эш урынымда да, өемдә дә ел буе чәчәк атып утырлар. Гәрчә минем тормышымда башка чәчкәләргә дә урын бар.

2. Үз вазыйфамны кызыклы эш буларак кабул итәм. Банкта эшләү миңа бик ошый. Һәр кич мин инде иртәгә эшләнәсе эшләрнең планын төзеп куям.
Банк – чит кеше акчасы белән эш йөртә торган учреждение. Шунлыктан зур һөнәрмәндлек, җаваплылык, эшкә сәләтлелек һәм даими үсеш таләп ителә. Банкир компетентлыгы критерийларының берсе дә нинди җенестән булуыңа бәйле түгел. Шунлыктан, вазыйфамны тартып бармаслык авыр, дип әйтә алмыйм. Бу минем эшем. Әйе, даими үзгәрә, заманнан артта калмауны таләп итә, ялкауланырга ирек бирми торган, нәкъ менә шуның өчен дә яраткан эшем ул.

3. Эшкә сәләтлелек, дисциплина һәм һәрнәрсәгә уңай мөнәсәбәт. Бусы – иң мөһиме. Мин банк даирәсендә күп еллардан бирле эшлим һәм шуны яхшы беләм: акча – зур игелек тә, зур явызлык та. Акчага алып булмый торган әйберләр дә бар – сәламәтлек һәм белем. Шунлыктан дөньяга финанс муллыгы призмасы аша карарга кирәкми. Бар нәрсә дә вакытлыча. Һәм моңа әзер булырга кирәк. Иң мөһиме – теләсә нинди шартларда да яшәү мәгънәсен җуймау.

4. Бәхет – якыннарың һәм туганнарыңның үзләрен яхшы хис итүе һәм сәламәт булуы ул. Күңел тынычлыгы, позитив кәеф, илһам. Үзебезне бәхетле итеп тою өчен безнең нинди эш белән шөгыльләнүебез дә, янәшәбездә нинди кешеләр булуы да мөһим.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАННЫҢ
төп
ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

“ХАТЫН-КЫЗ ЮГАРЫ ВАЗЫЙФАГА ҮЗ МИССИЯСЕН ҮТӘҮ ӨЧЕН ОМТЫЛА

Роза Яппарова,

«ӘКИЯТ» ТАТАР ДӘҮЛӘТ КУРЧАК ТЕАТРЫ ДИРЕКТОРЫ

1. **Язгы чәчәкләрне яратам.** Лаләләрне, нәркисләрне бигрәк тә үз итәм. Җылы көннәрне сагынгангамы, бу чәчәкләр үзләренә бер төрле, аларны җәйге һәм көзге җете чәчәкләр белән чагыштырып та булмый. Бераз кыюсызлар, дип әйтимме, шуңа күрә алар миндә табигатьнең яңарышына бәйле тәэсирләр тудыра.

2. **Замана хатын-кызы, җилкәсендәге йөк ир-атларныкы белән чагыштырганда күпкә авыррак булса да, назланып утырмый.** Хатын-кыз югары вазыйфага һәм статуска хакимлек итү өчен түгел, бәлки үз миссиясен үтәү өчен омтыла. Кагыйдә буларак, алар балачактан бирле лидерлар – башта октябрят «йолдызчыгы», аннары пионер отряды һәм пионер дружинасы рәисе, комсомол оешмасы секретаре... Мин дә шундый идем. Мәктәп елларыннан бирле иҗтимагый тормышта актив катнаштым. Аннары бу университетта һәм театрда да дәвам итте. Әгәр син үз эшеңнең остасы икән, хезмәтеңнең башкалар тормышын яхшыртуыннан канәгатьлек кичерәсең.
Үз эшемне бик яратам. Ул мине һәрвакыт тонуста тота, гел эзләнергә мәҗбүр итә. Театр, бигрәк тә курчак театры – һәр тамаша саен абсолют тәвәккәллек ул: яшь тамашачы без әйтергә теләгән фикерне аңлармы, кабул итәрме? Форма (курчак) белән эчтәлекнең (драматургия) тәңгәллеген тәэмин итү өчен даими эш таләп ителә.

3. **Безнең нәселдә һәрвакыт җаваплылык, максатчанлык һәм сәламәт амбиция югары бәяләнде.** Хакимияттә йомшак кешеләр була алмый. Һәм аның ир-ат яисә хатын-кыз булуы бөтенләй мөһим түгел. Әгәр хатын-кыз акыллы икән, ул яхшы җитәкче булачак һәм үзенең өстенлекләреннән һәрвакыт дөрес файдаланачак. Артистлар мохитендә исә коллегаларыңны үз идеяләрең белән мавыктыру осталыгы, аларны куелган максатларны үтәүгә этәрү маһирлыгы бигрәк тә мөһим. Театрда йөрәк, хисләр белән яшәргә кирәк.

4. **Сәламәтлек, муллык, уңыш – бер карасаң, тапталган сүзләр кебек. Тик аларга гаять зур мәгънә салынган.** Без ирем белән инде 45 ел бергә яшибез. Шунлыктан минем өчен хатын-кыз бәхете ул – үзара аңлашуга һәм ихтирамга корылган нык гаилә дә.

PRESSA.RU

ТАТАРСТАННЫҢ *төп* ХАТЫН-КЫЗЛАРЫ

“ДУСЛАРЫГЫЗ ҮЗЕГЕЗДӘН ЯХШЫРАК БУЛСЫН

Ольга Тарнаева,

«ЖИЛКОМСЕРВИС» ҖКФ» ҖЧҖ ГЕНЕРАЛЬ ДИРЕКТОРЫ, ЧАЛЛЫ

1. Минем яраткан чәчәгем – гербера. Бу чәчәк бәхет һәм уңыш символы санала. Миңа ул якты нурлар белән уралган кояшны хәтерләтә. Сөендерә һәм җылыта ул, ә төрле төстәге таҗ яфракчыклары аны тагын да соклангычрак итә, елның теләсә кайсы фасылында яз җиткәндәй була. Гербера чәчәк түгел, бәлки гүзәл нимфа икән дигән риваять тә бар әле. Тышкы кыяфәте белән ромашканы хәтерләтсә дә, чибәр гербера бөтен игътибарны үзенә җәлеп итә. Шатлык һәм җылылык биргәнгә күрә, герберага мин гел куанам. Төрле чәчәкләрдән төзелгән букетта ул «примадонна» булып тора.

2. Эшемне беркайчан да авыр йөккә санамадым. Һәрвакыт рәхәтләнеп эшлим, чөнки үз эшемне бик яратам. Җитәкче булып эшләү дәверендә үз гамәлләрем өчен генә җавап бирергә өйрәнеп калмыйча, һәрбер хезмәткәр өчен җаваплы булырга өйрәндем. Карьера баскычыннан күтәрелә барган саен, һәр баскычта үзем өчен яңалык табам, укыйм, өйрәнәм, шуның белән үз-үземне, яңадан-яңа мөмкинлекләремне ачам.

3. Беренчесе: тормышта нәрсә генә булса да, ул яхшыга була. Икенчесе: беркайчан һәм беркемгә дә ярарга тырышмагыз. Барыбер бөтен кешегә дә ошап бетә алмассыз. Өченчесе: дусларыгыз һәрвакыт үзегездән яхшырак булсын. Авыр булачак, тик тора-бара үзегез дә алар дәрәҗәсенә ирешәчәксез.

4. Минем өчен хатын-кыз бәхете – яратып яшәү ул. Нәкъ менә мәхәббәт хатын-кыз бәхетенең нигезен тәшкил итә. Ул илһамландыра, канатландыра. Мин яратканда, әйләнә-тирәдә бөтен нәрсә үзгәрә! Пешергән ризыкларым – тәмлерәк, кәефем – яхшырак, елмаюым җылырак була. Янәшәдәгеләр дә миндәге үзгәрешләрне тоя. Билгеле, бу бераз романтика белән сугарылган һәм чынга ашмас күренеш кебек тоела, тик мин мәхәббәтнең булуына һәм аның дөньяны коткара алачагына ихластан ышанам. Бу сөйгәнеңнең, балаларыңның, туганнарыңның мәхәббәте булырга мөмкин. Халык бит тикмәгә генә, яратканда, хатын-кыз чибәрләнә, дими.

Фото: Кирилл Рочев.

PRESSA.RU

«ТАТНЕФТЬ»НЕҢ ХАТЫН-КЫЗ ГЕОГРАФИЯСЕ

«Татнефть» Татарстанның кара алтыны белән генә түгел, берсеннән-берсе чибәр ханым-туташлары белән дә дан тота. Алардан башка нефть чыгару да, аны эшкәртү дә мөмкин булмас иде. Компания хезмәт куйган кайсы гына географик ноктаны алма, кайсы гына эш фронтына күз салма, гүзәл затларыбыз уртак гамәлгә үз көчен, осталыгын һәм мөлаемлыгын өсти.

АЛДЫНГЫ ХАТЫН-КЫЗ, СПОРТЧЫ ҺӘМ ПРОФСОЮЗ ҖИТӘКЧЕСЕ

Зөлфия Шакирова, «Татнефть газ эшкәртү» Идарәсе Миңлебай газ эшкәртү заводының 4 нче цехында товар операторы.

Зөлфия Тәлгать кызы бу предприятиедә инде чирек гасыр хезмәт куя. Цехның профсоюз эшен алып бара, торак-көнкүреш мәсьәләләре өчен җавап бирә.

1996 елда Зөлфия товар цехына товар операторы вазыйфасына күчә. Әлеге катлаулы һөнәргә өйрәткән остазларына карата рәхмәт хисен бүген дә йөрәк түрендә йөртә.

Өч бала тәрбияләп үстергән ана да, сәламәт яшәү рәвеше тарафдары да әле ул. Йөзү, җиңел атлетика ярышларында актив катнаша, шахмат уйный, чаңгы шуарга ярата. Быел «Татнефть газ эшкәртү» Идарәсе буенча чаңгы ярышында көмеш медаль яулаган.

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен, «Татнефть» компаниясенең мактау грамотасы белән бүләкләнгән.

БАУЛЫ СКВАЖИНАЛАРЫ ХУҖАБИКӘСЕ

Ирина Зарытова, «Баулынефть» НГТИнең нефть һәм газ чыгару операторы.

Бу предприятиедә нефть һәм газ чыгару операторы вазыйфасында 35 елдан артык эшли. «ЦДНГ-2»нең (нефть һәм газ чыгару цехының) 2 нче бригадасындагы булдыклы гүзәл зат ул.

Ирина Зарытованың нефть хуҗалыгына дистәләгән скважина һәм берничә ГЗУ (группалы үлчәү җайланмасы) керә. Әлеге объектлар бер-берсеннән шактый ерак урнашкан. Бер тапкыр карап-тикшереп чыгу өчен генә дә оператор унлап чакрым юл уза. Скважиналар хуҗабикәсенең эше бихисап: механик һәм автомат кыргычлар ярдәмендә скважинадагы насос-компрессор торбаларын парафин һәм сумалалардан чистарту дисеңме, автоматика һәм күзәтү приборлары күрсәткән саннарны ачыклау-хисаплау дисеңме…

Быел Ирина Зарытова чаңгы ярышында икенче урын алган. Үзе әйтүенчә, мондый уңышка ирешүдә җиңү теләгенең көчле булуы гына түгел, ә көндәлек күнегүләр: 10 км араны җәй көне – җәяүләп, кышын чаңгыда узу да ярдәм иткән.

Нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш керткәне һәм нәтиҗәле хезмәте өчен, Ирина Валентиновна Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале белән бүләкләнгән.

ШӘХСИ КЕЛӘЙМӘ ҖАВАПЛЫЛЫКНЫ УНЛАТА АРТТЫРА

Галина Артамонова, «Татнефть» компаниясенең Бөгелмә механика заводы бораучысы.

Шундый үзенчәлекле һөнәр турында Галина заводка мәктәп белән экскурсия ясаган вакытта белеп ала. Һәм менә инде 39 ел хезмәт куеп, ул бораучы хезмәтенең, шул ук вакытта стропальщик һәм токарь эшенең бөтен нечкәлекләрен үзләштерә. Хәзер ул өч һөнәрнең дә чын остасы булып тора.

Галинаның шәхси келәймәсе бар. Аның сүзләренчә, бу җаваплылыкны нык арттыра, чөнки бораучы кулыннан узган детальләр бик мөһим җиһазларга куела.

Галина Артамонова берничә тапкыр «Иң яхшы эшче» исеменә лаек булган. Күпьеллык намуслы хезмәте, фидакарьлеге өчен, Галина Владимировна II дәрәҗә «Ватан алдындагы казанышлар өчен» орденының медале белән бүләкләнгән.

«ЕЛХОВНЕФТЬ»ТӘ – 40 ЕЛ

Любовь Ломовцева, «Елховнефть» НГТИда нефтьне комплекслы әзерләү һәм кудыру цехының сусызландыру һәм тозсызландыру җайланмасы операторы.

Любовь Ломовцева мәктәпне тәмамлагач, әнисе эзеннән барып, «Елховнефть» нефть һәм газ табу идарәсенә эшкә килә, хәзер инде монда 40 ел хезмәт куя.

Ул вакытта, 70 нче еллар ахырында, Татарстан нефтен чыгару рекордлы темплар белән бара иде. Әзерләүчеләр нефть чыгаручыларга өлгереп барырга тиеш. Ә нефть комплекслы әзерләү һәм кудыру цехларында автоматлаштыру процессы юк дәрәҗәсендә, бөтен эш кул көче белән башкарылган чаклар. Любовь барлык кыенлыкларга түзеп эшли. 1982 елда исә яңа объект – Кичүдә югары күкертле нефтьне әзерләү җайланмасы куллануга тапшырылгач, Любовь Ломовцева шунда күчерелә.

Хәзер операторлар җитештерү процессы белән компьютер идарә итә. Ләкин сынау-тикшерү өчен үрнәк алу барыбер кулдан башкарыла.

«Татнефть» компаниясе хезмәт коллективының күптән түгел узган конференциясендә Татарстанның атказанган нефтьчесенә чираттагы бүләк – «Дуслык» ордены тапшырылды.

Реклама

ИҢ ЯХШЫ СЫЙФАТ МЕНЕДЖЕРЫ

Екатерина Полутяглова,
«Түбән Кама Шин» ГАҖнең 1 нче җыю цехы башлыгы урынбасары.

«Түбән Кама Шин» ААҖнә Екатерина 1997 елда, Казан дәүләт технология университетын тәмамлагач килә. Хезмәт юлын техник контроль бүлегендә шин җитештерү контролеры булып башлый, хәзер ул – 1 нче җыю цехы башлыгы урынбасары.

Екатерина Борисовна һәрвакыт һөнәри осталык дәрәҗәсен күтәрергә омтыла һәм перспективасы булуын тоемлаганда, яңалыклар белән даими кызыксынып тора. Җитештерелгән продукциянең сыйфатын яхшырту юнәлешендә 2013 елгы эш нәтиҗәләре нигезендә аңа «Татарстан Республикасының сыйфат буенча иң яхшы менеджеры» мактаулы исем бирелде.

Күпьеллык намуслы хезмәте һәм җитештерүдәге югары күрсәткечләре өчен, 2015 елда Екатерина Полутяглова Татарстан Республикасы Сәнәгать һәм сәүдә министрлыгының мактау грамотасы белән бүләкләнде.

ҺӘР ЯҢА КӨН БАШКАСЫН КАБАТЛАМЫЙ

Лариса Сереброва, «ТАНЕКО» АҖ Үзәк сыйфат лабораториясенең сынаулар буенча инженеры.

Иҗади, тере, кызыклы... Лариса Сереброва үз эшен әнә шулай сурәтли, хәер, ул үзе дә шундый. «ТАНЕКО» комплексына Лариса 2010 елда ире Вячеслав артыннан килә. «Татнефть»нең стратегик әһәмияткә ия проекты аны, тәҗрибәле белгечне, иң заманча технологияләре, иң алдынгы җиһазлары белән җәлеп иткән. «Акыллы тимер» белән эшләү кешенең даими һөнәри үсештә булуын таләп итә. Комплексның югары темпларда төзелүе, яңа җайланмаларны кулланышка тапшыру, яңа төр продукцияләр эшләп чыгару – болар барысы да, бер урында таптанмыйча, укырга, өйрәнергә, үсәргә, камилләшергә мәҗбүр итә. Шуңа карамастан, эшен никадәр генә яратса да, Лариса барыбер тормышында гаиләсен, йортын беренче урынга куя. Улы Роман, институт тәмамлап, Казанда инженер-метролог булып хезмәт куя. Әти-әнисен Матвей исемле онык белән сөендерергә дә өлгергән ул. Ларисаның кызы Анастасия алтынчы сыйныфта укый, музыка һәм бию белән бик җитди рәвештә шөгыльләнә.



ТОТАШТЫРУЧЫ ҺӘМ ШАГЫЙРӘ

Әлфия Сибгатуллина, «Түбән Кама йөк машиналары шиннары» ҖЧҖнең 1 нче җыю цехында полосалар тоташтыручы.

Әлфия хезмәт юлын 1989 елда «Түбән Кама Шин» ААҖндә полосалар тоташтыручы өйрәнчеге булып башлый. Бүген һөнәрен камил дәрәҗәдә белә, ләкин акционерлык җәмгыятенең уку-укыту комбинатындагы максатчан курсларда даими рәвештә осталыгын арттыра килә. Бу һөнәренә якын булган өстәмә профессия – резина эшләнмәләр һәм детальләр өчен өлге кисүче эшен дә үзләштергән.

Әлфия Рифгать кызы – җитештерү барышында уку-укыту инструкторы да, яшь кадрларны ул әзерли. Төп эшчеләр арасындагы ярышларда күп тапкыр җиңү яулый, сменада башкарылырга тиешле норманы 137 процентка үти!

Күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен, Әлфия Рифгать кызы күп мәртәбә рәхмәт хатлары, акчалата премияләр белән бүләкләнә. 2011 елда аңа «Хезмәт ветераны» исеме бирелә.

Ул әле берничә шигъри җыентык та бастырып чыгарган, татар композиторлары тарафыннан көйгә салынган җырлары да шактый.

ПРОФЕССИОНАЛ ҺӘМ ЯХШЫ ОЕШТЫРУЧЫ

Надежда Толстикова, «Түбән Кама тоташ металл кордлы шиннар заводы» ҖЧҖнең техник контроль бүлеге башлыгы.

37 еллык хезмәт дәверендә Надежда шин җитештерү контролеры вазыйфасыннан башлап техник контроль бүлеге җитәкчесе булуга ирешә. Ул – үз өлкәсендә чын профессионал.

2009 елда Надежда Владимировна яңа төзелеп килгән Түбән Кама тоташ металл кордлы шиннар заводының Баш технолог бүлегенә әйдәп баручы инженер-технолог итеп күчерелә.

Надежда Владимировна – теоретик белемнәр бирүгә, яшь белгечләр әзерләүгә аеруча игътибар күрсәтә. Үзенең һөнәри белем дәрәҗәсен дә һәрвакыт үсештә тотарга тырыша. «Сыйфат менеджменты», «Автокомпонентлар җитештерә торган предприятиенең сыйфат менеджменты системасын эшләтү нигезләре», «ISO/TS 16949:2002 стандарты өчен SPC, MSA, APQP, PPAP, FMEA методикалары» кебек курсларда укыганлыгын раслаган сертификатлары бар. Заводның сыйфат менеджменты системасына һәм продукция җитештерү процессына мөстәкыйль рәвештә аудит-тикшерү үткәрә.

Ул – «Социалистик ярышта җиңүче», «Коммунистик хезмәт ударнигы», «Иң яхшы мастер», «Сыйфат буенча иң яхшы белгеч», «Татнефть» ААҖ, «Түбән Кама Шин» ААҖ мактау грамоталары белән бүләкләнгән.

* SPC – процесслар белән статистик идарә итү, MSA – үлчәү системалары анализы, APQP – продукция сыйфатын алдан планлаштыру, PPAP – деталь җитештерүне килештерү процессы, FMEA – төзексезлекләрнең төрләрен һәм алар китереп чыгарган нәтиҗәләрне анализлау методикалары. ISO/TS – ИСО/ТС.

«ТАТАРСТАН» МАХСУС журналы өчен

«ТАТАРСТАН»НЫҢ АЛТЫН ЗАПАСЫ

Килешәсездер, йөз яшь гадәти генә итеп билгеләп үтелә торган бәйрәм түгел. Бигрәк тә сүз яраткан республикабыз турында барганда. Әйе-әйе, яшь һәм матур күренсә дә, Татарстанга тиздән, төгәл өч елдан, нәкъ бер гасыр була.

Исеме буенча гына түгел, рухы белән дә республиканың адашы булган журналыбыз юбилейга ФОТОБАНК әзерли. Аның сейфларында бәһасе булмаган хәзинәләр ята – олы тарихның әһәмиятле мизгелләре һәм шул тарихны тудыручы шәхесләр чагылыш тапкан аларда. Республика үзе һәм ул ирешкән уңыш-казанышлар һәм, гомумән, гап-гади тормышның бәхетле мизгелләре теркәлгән елъязма турында бара сүз.

Фото: Рамиль Гали

Казан. 1990 нчы еллар. 1 Май мәйданы, аңарчы ул – Спасская, Ивановская, Александровская исемнәрен йөрткән, Казанның тарихи үзәгендә урнашкан.

Безнен ФОТОБАНКны озак еллар Казан университетының журналистика факультетында фоторәсем эшен укыткан Җәвит Акчурин ачып җибәргән иде. Ул безнең банкка беренчеләрдән булып үзенең саллы өлешен кертте.

Әлеге изге эшне чираттагы фотограф – Рамил Гали дәвам итә. Журналыбызның март санында хатын-кыз темасын чагылдырган фотоларга күз салыгыз. Алар сезне узган гасырның 90 нчы елларына алып кайтыр. Матурлык кайчан да – матурлык, аны еллар үзгәртми!

PRESSA.RU

Казан. 1990 нчы еллар. «Лик» мода театрына узган гасырның 90 нчы елларында Көнкүреш хезмәте күрсәтү министрлыгы (шундый министрлык бар иде!) инициативасы буенча нигез салына.

Казан. 1990 нчы еллар. Парикмахерлар конкурсы.

PRESSA.RU

Бәхетле кеше язмалары.
РЕНАТ ИБРАҺИМОВ «СЕРИАЛЫ»

«Тормышым күпсерияле киноны хәтерләтә, һәм мин әле берничә сериясен генә карарга өлгердем бугай, алда яңа, гаҗәеп вакыйгаларга бай көннәр көтә!» – менә шулай образлы итеп аңлатты үзенең гомер юлын Ренат Ибраһимов. Язмышының тагын бер «сериясе» күптән түгел генә төшерелде. «Моннан бер көн элек кызым – сигезенче балам туды!» – дип шатлыгы белән уртаклашты җырчы. Казанга җырчы озакка түгел – үзенең «Избранное» китабын тәкъдир итәргә генә кайткан иде. Хәбәрчебез аның белән тормышының иң якты мизгелләре турында әңгәмә корырга өлгерде.

БАЛАЧАК ТУРЫНДА: «БӘХЕТЛЕ ВАКЫТ ИДЕ!»

«Ренат, ашарга кер!» – әниемнең тавышын әле бүген дә ишетәм кебек. Бары тик шул чакыру гына мине, агач мылтык тотып, «ура!» кычкырып уйнап йөргән җирдән – ишегалды дигән «сугыш кырыннан» аерып алырга сәләтле иде. Безнең Олькеницкий урамы Казанның үзәгендә диярлек урнашкан. Урам тулы агач йортлар. Канализациясе дә, үзәктән җылыту да юк иде, суга да бертуганым Равил белән күрше урамдагы колонкага йөрергә туры килде.

Әле дә хәтердә, ишегалдына ассенизатор, калайчы һәм пычак кайраучы килә иде, әмма бала-чага бигрәк тә иске җыючыны зарыгып көтә. Аны бөтен нәрсә кызыксындыра: кирәкмәгән савыт-саба, иске чүпрәк-чапрак, хәтта буш банкалар. Ә малай-шалайга исә алар урынына төрле төстәге шарлар бирә, без моның хакына иске-москы эзләп бөтен ишегалдының астын-өскә китерергә риза! Нинди бәхетле вакыт иде!»

БЕРЕНЧЕ ТӘҖРИБӘ: «БЕЗ АНЫ ӘЛЕ ИШЕТӘЧӘКБЕЗ!»

Опера һәм балет театрындагы хезмәт юлым… сәхнә эшчесеннән башланды. Мин ул вакытта әле 9 нчы класста гына укый идем. Театр оркестрында уйнаган апам Луиза аркылы каникул көннәренә бригадага алдылар. Әйтергә кирәк, эш җиңелләрдән түгел – декорацияләр бик авыр! Спектакльләр аншлаг белән бара – мин дә исем китеп сәхнәдән күземне алмыйм. Күбесе инде таныш – астан, оркестр утырган урыннан бер генә мәртәбә карамаганмындыр, шул ук Луиза апа ярдәме белән. Бервакыт кичен, спектакльдән соң, декорацияләрне сүткәндә, түзмәдем – буш залда Антон Рубинштейнның «На воздушном океане» әсәрендәге Демон ариясен җырлап җибәрдем. Шул вакытта төп рольне башкаручы артист үтеп бара икән. Мине күреп, туктап калды һәм иптәшләремә: «Без аны әле ишетәчәкбез!» – диде. Сүзләре хак булып чыкты: күпмедер вакыт үткәннән соң, мин театрга килдем, инде – солист сыйфатында.

ТОРМЫШ МӘКТӘБЕ ТУРЫНДА: МУЗЫКА ХУЛИГАНЛЫКТАН САКЛАП КАЛДЫ

«Ислам Хаҗиевич кайтып килә!» – дип кычкыралар иде әниемә күршеләр, без әтием белән ишегалдына кереп килгәндә үк. Тавышыннан танийлар – әтием йөрәгенә якын сугыш җырларын көйләп йөрергә ярата. Ул йомшак баритон тавышка ия иде. Мин исә, әтием репертуарының бер өлешен өйрәнеп, балалар бакчасында иптәшләремне «По долинам и по взгорьям шла дивизия вперед!» дигән җыр астында атларга өйрәтергә маташам. Нәтиҗәдә тәрбиячеләрем әти-әниемә мине музыка мәктәбенә бирергә киңәш итәләр. Анда мине тыңлыйлар. Хәер, тагын бер сәбәп була. Без яшәгән район тыныч түгел иде. Һәм әтием берьюлы ике мәктәптә уку миңа ишеалдында йөрергә вакыт калдырмас, дип уйлый. Шулай итеп, музыка мәктәбе мине хулиганлык мохите йогынтысыннан саклап калырга булышты, дип әйтергә дә мөмкиндер.

Фото: «Татар-Информ» МА

ТӘНКЫЙТЬ ТУРЫНДА:
БЕРЕНЧЕ МӘРТӘБӘ «РОССИЯДӘ»

«Егетем, ник алай кычкырасыз?» – дип сорады бервакыт мин чыгыш ясаганнан соң атаклы композитор Василий Соловьёв-Седой. Бу 70 нче еллар башы иде. Мине ул вакытта Мәскәүгә бәйрәм концертында катнашырга чакырганнар иде. Росконцертның өлкән яшьтәге концертмейстеры миңа аталарча мөнәсәбәт күрсәтте. Концертта өстемдәге костюмымнан чыгыш ясаячагымны белгәннән соң, кыяфәтемә карап алды да күршедәге прокат пунктыннан смокинг алып торырга киңәш итте. Концерт ботинкаларының кирәкле размерын без, ни тырышсак та, таба алмадык, һәм остазым миңа үзенекен – 1941 елдан бирле кия торган легендар лаклы ботинкаларын биреп торды! Шундый матур кыяфәттә мин әле өр-яңа «Россия» концертлар залы сәхнәсенә чыктым. Дулкынланудан тыным кысылды: залның зурлыгы хәйран калдырды, иксез-чиксез тоелган рәтләрнең беренчеләрендә күренекле һәм хөрмәтле кешеләр утыра бит. Ул вакытта үземнең кешеләрдә зур тәэсир калдырырга тырышуымны бүген елмаеп искә алам. Тырышудан тирләп пештем. Ә пәрдә артында Соловьёв-Седой белән бәрелешә яздым, ул исә, елмаеп, миңа әлеге соравын бирде. Бу җырлау манерам өстендә җитди эш алып баруга зур этәргеч булды.

ХАТЫН-КЫЗЛАР ТУРЫНДА:
ҮЗЕМНӘН КӨНЛӘШКӘНМЕН

«Җәннәт әниләрнең аяк астында» – минем сүзләр түгел, Изге Коръәндә шулай язылган. Әниемнең ярату һәрвакыт җылытып килде, бу хис олыгая барган саен артты гына. Янымда һәрвакыт кадерле-якын кешеләрем булса да, аның бакыйлыкка күчүе мине ялгыз итте. Мин тормышымның мәгънәсе турында уйлана башладым. Һәм аны таптым да! Ул җаныңны камилләштерүдә. Ирекле булу, яраткан эшең белән шөгыльләнү, шуңардан тәм табу. Ә игелекле эшләрдән күңел канатлана, тормыш тагын да кызыклырак тоела башлый.

Дингә килгәндә мин инде иллене тутырган идем. Яңа тормышымны уртаклаша алырдай хатынны алтмыштан соң очраттым. Светлана бик яшь иде – вуз студенткасы. Без аның белән кытай ресторанында таныштык. Ул анда буш вакытында эшли иде, ә мин яхшы чәй эчәргә кергәлим. Елмаеп торган ачык күңелле кыз татар гаиләсеннән булып чыкты. Мин рәхәтләнеп туган телемдә сөйләштем. Әчтән генә аның булачак иреннән көнләшә идем. Үземнән көнләшкәнмен икән.

ЯЗМЫШ ЯЗГАН ОЧРАШУЛАР ТУРЫНДА:
ПРЕЗИДЕНТ РЕЗИДЕНЦИЯСЕНДӘ...

Россиянең беренче Президентыннан язулы сәгатем бар минем. Аның каршында чыгыш ясау хәтергә нык уелып калды. Бу вакыйга тагын бер беренче Президент – Татарстан Республикасы Президенты Минтимер Шәймиевнең шәһәрдән читтәге резиденциясендә булды. Ельцинның Казанга сәфәре вакыты иде. Һәм менә баянчы белән бергә Борис Николаевич белән очрашуны көтәбез. Менә ул килеп керде – кәефе күтәренке, бик шат. Кәнәфидә урын алды. «Только раз бывает в жизни встреча» романсыннан башлап җибәрдем. Аннан соң, курсны үзгәртеп, «Вдоль по Питерской» җырын суздым. Карыйм, Ельцин тыпырдый ук башлады. Ә инде «Из-за острова на стрежень» җырын җырлый башлагач, түзмәде – миңа кушылды, һәм рольгә шулкадәр кереп китте ки, миңа бер мизгелгә генә каршымда шаян-шук Стенька Разин үзе торадыр кебек тоелып китте! Җырлап бетергәч, Ельцин мине кочаклап алды һәм шул сәгатьне бүләк итте.

Сүз уңаеннан, Минтимер Шәриповичның шәһәрдән читтәге резиденциясендә үткән концертлар минем язмышымда зур роль уйнады дияргә була. Шуларның берсеннән соң, мин Мәскәүгә күчендем – Виктор Степанович Черномырдин булышты. Мин анда «Газпром»ның мәдәният идарәсе башлыгы вазыйфасына эләктем. Предприятие җитәкчелегенә җиткергән тәүге идеяләремнең берсе «Факел» музыка фестивален оештыру булды. Ел саен үткәреләчәк фестивальгә талантларны эзләү өчен шәхсән үзем регионнарга чыктым. Мин инде «Газпром»да эшләмәсәм дә, фестиваль бүгенге көнгә кадәр уңышлы эшләп килә.

ЯШЬЛЕК ҺӘМ ЕГЕТЛЕК ТУРЫНДА:
ТАТАР ЭЛВИСЫ

Мине ничектер бер Элвис Пресли белән чагыштырдылар. Америкалылар үзләре үк. Бу ерак совет заманнарында ук булды. Беркөнне Казан пристанена АКШ гражданнарын төягән экскурсия теплоходы килеп туктады. Нинди вакыйга! Галимнәр йортында кунаклар өчен кечкенә генә концерт әзерләделәр. Программага минем номер да кертелгән иде. Джаз-бэнд аккомпанементы астында җыр башкардым, алай гына да түгел, бер үк вакытта чүгәли-чүгәли, тезләремә елыга-егыла твист та биергә тырыштым. Туристларның исе китте! Араларында бер яшь туташ та бар иде. Гомумән алганда, АКШ туристлары белән якыннан аралашырга ярамаганлыгы турында катгый кисәтелгән иде, ләкин минем өчен искәрмә ясадылар. Һәм без теплоход киткәнче аралаштык. Вакытлар үткәч, мин аңардан открытка да алдым әле. Хәер, безнең аралашуыбыз шуның белән өзелде дә инде.

БӘХЕТ ТУРЫНДА: ӨЕҢ – ҖИРДӘГЕ ҖӘННӘТ УЛ

Миңа авыл тормышының өч буын бергә яши торган борынгы тәртибе ошый. Мәскәү янындагы урман эчендә шундый тормышны төзедем дә. Әби белән бабай, Света белән без, аның әти-әнисе һәм безнең балаларыбыз – бергәләшеп яшибез. Янәшәдә генә елга, мунча морҗасыннан төтен күтәрелә, чоланда бакча алмаларының хуш исе аңкый, тавыклар һәм каҗәләр йөреп тора. Һәм без үзебез кайнаткан кайнатма белән самовар чәе эчәбез. Җирдә төзегән җәннәте өчен Аллаһыма рәхмәт!

PRESSA.RU

ТӨП ЮНӘЛЕШ – СЫЙФАТ

Төзелеш мәйданында тулы куркынычсызлык, эшләрне вакытында һәм сыйфатлы итеп башкару, барлык хезмәткәрләрнең югары квалификациясе – «Татарстан Республикасы төзүчеләре бергәлеге» үзкөйләнешле оешмасы таләпләрен даими раслап торучы төзелеш оешмаларына карата куелган критерийлар әнә шулар. Бары тик сирәкләр генә мөмкин булган 100 баллдан 100не җыя. «СтройТраст» ЖЧҖ – шул сирәкләрнең берсе.

Раил Миңнегалиев, «СтройТраст» ЖЧҖ генераль директоры

– Без Татарстанның төзелеш базарында дистә елга якын эшлибез, һәм безнең тәҗрибә профессионаллар, бик югары әзерлекле хезмәткәрләр генә тел тидермәслек эш сыйфаты күрсәтә алуын раслый. Шуңа күрә без кадрлар потенциалын үстерүгә һәм көчәйтүгә һәрвакыт зур игътибар бирәбез, – дип сөйли компаниянең генераль директоры Раил Миңнегалиев.

Хәзерге вакытта предприятие штатында 340тан артык хезмәткәр исәпләнә, аларның 67се – югары һәм урта махсус төзүче белемена ия инженер-техник хезмәткәр. Алар өчен даими рәвештә квалификация күтәрү һәм имтихан программалары оештырыла.

– Төрле объектлар рөхсәт итүнең төрле дәрәҗәләрен таләп итә. ҮКО хезмәткәрләребезнең безнең тарафтан билгеләнгән һөнәри күрсәткечләренең аларның реаль квалификацияләренә туры килүен җитди тикшерә. Шуңа күрә безнең төзелеш мәйданында үз вазыйфаңа салкын карау, эшеңне начар белү мөмкин хәл түгел, – дип басым ясый Раил Габделхаевич.

Заказларның югары дәрәҗәдә башкарылуы һәр этапта гарантияләнә: «СтройТраст» ЖЧҖ структурасында тулысынча кадрлар белән тәэмин ителгән техник, җитештерү, смета-шартнамәләр, матди-техник тәэминат, сыйфат контроле, җитештерүгә әзерлек хезмәте бүлекләре бар. Төзелеш мәйданчыгында бурычларны турыдан-туры үтәү белән гомумтөзелеш, бизәү, сантехник, тышкы челтәрләр, фасад эшләре, электромонтаж һәм түбән көчәнешле эшләр участоклары белгечләре шөгыльләнә.

– Бернечә ел элек без чыгымнарны һәм кайбер эш процессларын оптимальләштерү турында карар кабул иттек. Моның өчен үзебезнең автотранспорт паркын оештырдык. Төзелеш краннар, «тягач» машиналар, үзбушаткыч автомобильләр, автокраннар, автобуслар, тракторлар, йөк «Газель»ләре, төягечләр – техниканың барысы да бездә бар һәм эшли, – дип аңлата безгә «СтройТраст» ЖЧҖ генераль директоры.

Кадрлар белән һәм техник яктан тәэмин ителгәнлек оешмага сәнәгать һәм граждан төзелеше объектларында төзелеш-монтаж эшләренең тулы комплексын (чокыр казудан тулысынча төзеп тапшыруга кадәр) башкарып чыгарга мөмкинлек тудыра. Эре проектлар кысаларында компания субподрядчы сыйфатында ышанычлы, һәм шулай ук эшнең таләп ителгән сыйфатын гарантияли алырлык партнерларны җәлеп итәргә сәләтле генподрядчы буларак уңышлы катнаша.

Компания белгечләре бөтен Татарстан буенча торак һәм сәнәгать төзелеше проектларын гамәлгә ашыруда катнаша. Шуларның иң әһәмиятлеләре – Яр Чаллыда һәм Әлмәттә киң күләмдә торак төзү, «Чаллы-Бройлер» ЖЧҖ нең кош ите эшкәртү заводын, «Хортум» фәнни-җитештерү предприятиесенең производство корпусын салу. Предприятие «КАМАЗ» ГАҖндә SFTP кабиналары каркасларын җитештерү заводын төзүдә дә катнаша.

«СтройТраст» ЖЧҖнең төп заказчылары зур төзелеш проектлары белән шөгыльләнүче компанияләр. Атап әйткәндә, бу – «Уңайлы торак» ТТК ЖЧҖ һәм «ДОМКОР» ЖЧҖ.

Компания клиентларының таләпләренә җавап йөзеннән даими рәвештә эш төрләрен арттыра бара. Перспективалы юнәлешләрнең берсе – «Текс-Колор»ның популяр «юеш фасад» системасы буенча фасадларны ясау, композит панельләрдән һәм керамогранитган вентиляцияләнә торган фасадлар җыю.

– Теләсә кайсы проектта безнең өчен иң мөһим бурыч булып объектлар төзелешенә җентекле контрольлек итү, матди һәм кадрлар ресурсын нәтиҗәле куллану тора. Моның белән беррәттән, без алгарыш ягына юл алабыз, динамик үсештәге Татарстан базарында көндәшлеккә сәләтлелекне күтәрүгә китерерлек яңа хезмәтләр һәм технологияләр кертәбез, – дип йомгаклады сүзен Раил Миңнегалиев.

Реклама

МӘҢГЕЛЕК КЫЙММӘТЛӘР

БУ САНДА ТӘКЪДИМ ИТӘБЕЗ:

Кубрат хан хәзинәсе **КАЙДА** яшерелгән

«Татарстан» журналының әдәби премиясе»н **КЕМ** дәгъвалый

Без **НӘРСӘЛӘРНЕ** хәтердә сакларга тиеш

Чыршы авылында **НИЧӘ** чыршы бар

«Свияжск әкиятләрен» **КЕМ** язып алган

Кубрат ханның «Кувpат патрикий» дигән монограммалы йөзеге. Бу монограмма аның Византия сараенда шундый дәрәҗәгә ия булуы хакында сөйли. Б.э.ның 632-665 еллары.

КУБРАТ ХАН ХӘЗИНӘСЕ

Халыкларның Бөек күчеше вакытында һуннар дулкынына эләгеп Көнчыгыш Европа далаларына килеп чыккан болгарлар VI гасырның 70 нче елларында Төрки каганаты кул астында кала. Әмма вассал хәлендә буйсынып яшәргә күнекмәгән болгар ханы Кубрат, Византия императорының ярдәменә таянып, 630 нчы еллар башында төркиләрдән бәйсезлек яулап алуга ирешә һәм Азов, һәм Кара диңгез тирәләрендә үзенең мөстәкыйль дәүләтен төзи. Ул дәүләт тарих битләренә Бөек Болгар исеме белән кереп кала.

Автор:
Фаяз Хуҗин

КУБРАТ ХАН БОЛГАРЫ

Тарихи документларда утригурлар, кутригурлар, оногурлар исеме астында теркәлеп калган сугышчан болгар кабиләләре баштарак чорларда Кара диңгез буе далаларында таралып яшәгәннәр, башлыча терлек асрап көн күргәннәр. V гасыр ахырында алар бер халык булып оеша башлыйлар. Шул заманнардан башлап, болгарлар халыкара аренага чыга – Византия императорлары аларны үзләренең тышкы сәясәт планнарын тормышка ашыру максатында ялланган гаскәриләр рәвешендә файдалана. Болгар атлы гаскәрләре Византия армиясе составында Фракиядә, Дакиядә, Мёзиядә сугышлар алып бара.

Болгарларны бердәм дәүләт кысаларында туплау эшен Кубрат хан башкарып чыга. Ул зирәк акыллы сәясәтче, булдыклы хәрби җитәкче, батыр йөрәкле шәхес була. Документлардан күренгәнчә, Кубрат хан – затлы Дуло төрки ыруыннан чыккан Орхан исемле хакимнең бертуган агасының улы. Язма чыганакларда аның Константинопольдә, Византия императоры Ираклий сараенда тәрбияләнүе, христиан дине кабул итүе һәм чит кавемнәргә сирәк бирелә торган патрикий дәрәҗәсе алуы турында мәгълүматлар сакланган. Табигый ки, Кубрат рум телендә сөйләшә дә, укый-яза да белгән, гади халык арасында исә төркиләрнең рун графикасына нигезләнгән язуы таралган булган. Болгарларның Византия белән дустанә мөнәсәбәтләре археологик материалларда да чагылыш таба: мәҗүси каберләрдә мәет янына еш кына Византиядән китерелгән кыйммәтле сугыш кораллары, алтын-көмеш акчалар, савыт-сабалар куя торган булганнар.

Кубрат хан әмере буенча болгарлар һуннар вакытында җимертелгән Фанагорияне яңадан торгызалар. Антик чорлардан калган борынгы грек шәһәре Бөек Болгарның башкаласына, эре һөнәрчелек һәм сәүдә үзәгенә әверелә. Болгарлар Таматарха/Тмутаракан шәһәрендә дә яшәгәннәр. Шушы ике шәһәр янәшәсендә башка утрак поселоклар да үсеп чыга, аларда яшәүчеләр игенчелек һәм һөнәрчелек белән шөгыльләнгәннәр. Халыкның күп өлеше исә күчмә һәм ярымкүчмә тормыш алып барган, күпләп ат, мөгезле эре терлек, сарык асраган, тире эшкәрткән.

БӨЕК БОЛГАРНЫҢ ТАРКАЛУЫ

Төрки каганлыгы кебек үк, Бөек Болгар да тотрыксыз һәм кыска вакытлы дәүләти берләшмәсе булып чыга. Анда барысы да абруйлы хакимнең ихтыярына буйсына. Кубрат хан вафат булгач, VII гасырның 50–60 нчы елларында бу дәүләт таркала. Аның җирләрен ханның варислары – уллары үзара бүлешәләр.

Тарихи риваятьләр рәвешендә язылган кайбер чыганаклардан күренгәнчә, үзе үлгәннән соң «Кубратның биш улы кала. Ул аларга бер-берсеннән аерылмаска, дошман кабиләләргә коллыкка төшмичә, башкалар өстеннән һәрвакыт хакимлек итеп бердәм яшәргә васыять иткән». Буыннан-буынга күчеп килгән риваятьләрнең берсендә (ул Византия монахы Феофан Исповедникның 810–815 нче елларда язылган әсәрендә теркәлгән) болай диелә: Кубрат хан вафаты алдыннан улларын үз янына чакыртып ала да, аларга бер бәйләм чыбык алып килергә боера. Аннары улларының һәркайсына шуларны сындырырга куша. Чыбыклар бәйләмен берсе дә сындыра алмый. Шуннан соң этиләре бәйләмнән бер чыбык суырып ала да, аны җиңел генә сындырып ата. «Күрәсез, бәйләмне яшь, көчле кеше дә сындыра алмады, ә аерым бер чыбыкны үләргә яткан хәлсез карт та сындырды, – ди ул. –

Фотолар автордан алынды



Кубрат идарә иткән Бөек Болгар дәүләте – картада.

Сез дә бердәм чакта менә шулай җиңелмәс булырсыз, аерылсагыз дошманнар бик тиз юкка чыгарачак сезне һәм кол итәчәкләр». Ләкин уллары әтиләренең акыллы киңәшен тотмыйлар һәм, туганлык хисләрен җуеп, тәхет өчен үзара көрәш башлыйлар.

Уңайлы форсаттан файдаланып, аерым төркемнәргә бүленгән таркау болгарларга яңа гына үзләренең мөстәкыйль дәүләтләрен төзегән күрше хәзәрләр һөҗүм итә һәм җиңеп чыга. Кубратның Аспарух исемле бер улы үз урдасын көнбатышка, Дунай буйларына, яңа җирләргә алып китә. Биредә алар, элегрәк күчеп килгән славяннарны буйсындырып, шул ук вакытта Византиянең 50 меңлек көчле гаскәрен тар-мар итеп, 681 елда Дунай Болгариясе дәүләтен төзиләр.

Болгарларның зур гына тагын бер төркеме Кубратның Батбай исемле икенче улы җитәкчелегендә Кубан елгасы буйларында, Кавказ тирәсендә һәм Кара диңгез буе далаларында кала. Батбай болгарлары хәзерге балкар һәм карачай халыкларының барлыкка килүендә зур роль уйнаганнар.

Котраг кул астындагы төркем Идел елгасы буйлап төньякка күтәрелә. Болгарларның VII гасыр ахырына – VIII гасырның беренче яртысына караган археологик һәйкәлләре – каберлекләр соңгы елларда Самара һәм Ульяновск өлкәләрендә казып тикшерелде.

Кубратның Кубер исемле дүртенче улы үзенең урдасын Паннониягә, хәзерге Венгрия җирләренә алып китә. Венгриядә әле бүген дә өч дистәләп болгар топонимы сакланып калган (Болгар, Полгар, Берсел, Боляр һ.б. торак пунктлары).

Болгарларның тагын бер төркемен Кубрат ханның Альцек исемле төпчек малае франк короле Дагоберт рөхсәте белән Паннониядән Бавариягә алып китә. Төрле сәбәпләр аркасында (шул ук Дагоберт аларны үтереп бетерергә куша), болгарлар тиз арада бу җирләрне ташлап китәргә мәҗбүр булалар. Лангобард короле Гримуальд аларга Италиянең төньяк өлкәсендә урын бирә. Һәм Альцек болгарлары биредә төпләнеп калалар. Италия археологлары әлеге болгарларның эзләрен җирле халыктан калган борынгы зиратлардагы ат түшкәләре белән кәкре кылычлар куеп күмелгән монголоид тибындагы кешеләр каберләрендә күрәләр.

PRESSA.RU

Амфора. Көмеш, алтын.
Чүкү техникасы. VII гасыр.

Космологик сюжетлы сасанид касәсе.
Алтын. V-VII гасырлар.

Сасанид касәсе.
V-VII гасырлар.

Провинциядә ясалган алтын
сасанид касәсе.
V гасыр – VII гасыр башы.

Алтын йөгертелгән агач савыт.
VII гасыр.

Алтын йөгертелгән түгәрәк башлы кылыч.
Сабына грек алфавитының беренче хәрефләре
тырнап язылган. Алтын, тимер, пыяла. VII гасыр.

КУБРАТ ХАН ХӘЗИНӘСЕ

Полтава губернасының Константиновград өязе Малая Перещепина авылы – бу исемне Россия һәм чит ил археологлары арасында белмәүчеләр юктыр, дип уйлыйм. Шушы авылның ике яшәүсмер малае 1912 елның 29 маенда көтү көткәндә очраклы рәвештә бик зур хәзинәгә юлыгалар. Малайларның берсе, 12 яшендәгесе, уҗымга кереп баручы сыер артыннан чабып барганда, аягы ниндидер бер чокырга төшеп, туктап кала. Кулындагы таягы белән чокырны казып карый – алтын савыт килеп чыга. Чакыруга иптәше йөгереп килеп җитә – тагын бер көмеш савыт табып алалар. Табылдыклар турында авыл старостасына хәбәр җиткерәләр. Чокыр урынын тиз арада авыл крестьяннары чолгап ала. Хәзинә бай булып чыга: әллә никадәр савыт-саба, металл акчалар, сугыш кораллары, ат дирбияләре, бизәнү әйберләре... Барысы да диярлек алтын-көмештән. Табылдыклар кулдан-кулга күчә һәм... кешеләр арасында таралып та бетә.

Әмма бу тарихның ахыры хәерле була. Хәзинә турында өязнең полиция идарәсенә һәм Полтава гыйльми архив комиссиясенә һәм җирле археолог И.А. Зарецкийга хәбәр итәләр. Петербургтан Император археология комиссиясе Малая Перещепинага тагын бер археолог_ны – Н.Е. Макаренконы җибәрә. Берничә көн эчендә әлеге төркем авыл кешеләре кулыннан хәзинәдәге әйберләрнең барысын да диярлек җыеп ала һәм табылдык урынын җентекләп тикшерә. Әйберләрнең тулы исемлеген төзеп һәм авырлыгын төгәл үлчәп, аны башта Константиновградтагы полиция идарәсенә, аннан Полтавага һәм июль ахырларында Петербургка, Дәүләт банкына озаталар. Әлеге банктан хәзинәне Император археология комиссиясенә галимнәр карамагына җибәрәләр. 1914 елда Перещепина хәзинәсе Дәүләт Эрмитажы фондларына килеп керә. Эрмитаж хезмәткәрләренең тырышлыгы аркасында, хәзинәнең авыл кешеләре кулында калган яисә төрле юллар белән коллекционерларга эләккән өлеше дә дәүләт саклагычына кайтарыла.

Шулай итеп, хәзинә составында 800 дән артык предмет, шул исәптән 69 Византия акчасы булуы ачыклана. Хәзинәнең гомуми авырлыгы 75 килограмм чамасы, аның 25 килограммы – алтын, 50 килограммы көмеш әйберләрдән гыйбәрәт. Табылдыклар арасында тәлинкә, кубок, амфора, кувшин, кашык-чүмеч кебек савыт-саба, бил каешы очлыклары, хәнҗәр-кылычлар, колак алкалары, беләзекләр-йөзекләр, ат йөгәне, ияр, өзәңге, ыңгырчак бизәкләре, кадаклар һ.б. күптөрле әйберләр бар.

Хәзинә табылган урынны 1960–1980 нче елларда Украина һәм Болгария археологлары тикшереп карыйлар, әмма яңа әйберләр табылмый. 1912 елгы хәзинәгә юлыккан Карп Иванович Маджар исемле кешене дә эзләп табалар. Аның сөйләве буенча, хәзинә яткан чокырда черек агач калдыклары, берничә данә кеше һәм хайван сөякләре дә булган.

Хәзинә галимнәр арасында зур кызыксыну уята: кайчан һәм ни сәбәпле күмелгән, кайсы халыкка нисбәтле? Беренче сорауга җавапны тиз табалар – VII гасыр урталары яисә шул гасырның икенче яртысы. Икенче һәм өченче сораулар бәхәслерәк булып чыга.

Озак еллар совет археологиясенең башында торган академик Борис Рыбаковның фаразы, көчле фактлар белән расланмаган булса да, аксиома рәвешендә бөтен дәреслекләргә үтеп керде һәм Г.Ф. Корзухина, М.И. Артамонов, А.К. Амброз һәм Б.И. Маршак кебек археологларның фикерләре, көчле тәнкыйть утына дучар булып, аларга көлеп кенә карадылар. Академик Б.А. Рыбаков Перещепина хәзинәсен, аңлашыла ки, тарих битләренә антлар исеме белән кереп калган борынгы славяннарныкы дип «исбатлады». Аның төп аргументы, гадиләштереп әйткәндә, болайрак яңгырый: шулкадәр дә бай хәзинә славяннарныкы булмыйча, күчмән төркиләрнеке булмас бит инде?! Аның оппонентлары СССР Фәннәр академиясенең Археология институты директоры белән артык бәхәсләшеп торырга теләмәсәләр дә, хезмәтләрендә нәкъ менә шундый фикерне үткәрә башлаганнар иде.

Хәзинә кемнеке, дигән сорауга көтелмәгән яктан һәм берминди

Алтын сасанид чүлмәге.
V гасыр – VII гасыр башы.

Кулъюгыч. Көмеш чүлмәккә алтын йөгертеп эшләнгән. VII гасыр.

Ат дирбиясе каешындагы очлыклар. Алтын, пыяла кушып эшләнгән орнамент-бизәк. VII гасыр.

Зәбәрҗәт куеп ясалган пар беләзек.
VII гасыр уртасы.

бәхәсләргә урын калдырмаслык ачык җавап килде. Австрия галимнәре филолог В. Зайбт һәм тарихчы Й. Вернер хәзинә составына керә торган монограммалы (язулы) ике алтын йөзеккә игътибар итәләр һәм шул монограммаларны, дөреслегенә бернинди шик калдырмыйча, укуга (дешифровкалауга) ирешәләр. Бу ачыш турында Йохим Вернер беренче тапкыр үзенең 1984 елда чыккан китабында хәбәр итә. Беренче йөзек кашларына – ХОВРАТОУ («Кубрат/Кубрат»), икенчесенә ХОВРАТОУ ПАТРІКІОУ («Кубрат/Кубрат – патрикий») дип язылган була. Беренчесе, күрәсең, Кубратка әле патрикий дәрәҗәсе бирелгәнче бүләк ителгән булгандыр.

Өченче йөзек кашындагы монограммага галимнәр ВАТ ОРХА (N) ОУ ПАТРІКІОУ (ват/кенәз Орхан – патрикий) дип дешифровка ясыйлар. Орган/Орһан, югарыда әйтеп үтелгәнчә, болгарларның әле Төрки каганатына буйсынып яшәгән чордагы юлбашчысы, Кубратның агасы, яшь вакытта аны Константинопольгә, император сараена тәрбиягә биреп калдырган регенты. Әмма хәзинәнең Орханга бәйләнеше юк, чөнки әйберләре соңгырак чорга карый. Шулай итеп, Перещепина хәзинәсе Бөек болгар ханы Кубратныкы булып чыга. Хәзер аны «Кубрат хан хәзинәсе» дип кенә йөртәләр.

Ничек барлыкка килгән соң бу хәзинә? – бүген галимнәрне шул сорау борчый. Болгавыр заманнарда киләчәктә тыныч көннәр килүгә яңадан казып алу максаты белән дошманнар күзеннән саклап калу өчен махсус күмелгән «чиста» хәзинәме бу? Бераз шикләндерә. Археологлар хәзинәне табучы кешенең, без казыган чокырда черек агач калдыклары, берничә данә кеше һәм хайван сөякләре дә бар иде, дигән сүзләренә игътибар итәләр. Әгәр дә «хәзинәбез» болгарлар патшасының кабере булса? Бик мөмкин ич! Бу хакта бер-берсенә каршы килә торган, әмма тарихи чынбарлыкны якынайтуга, хакыйкатьне ачыклауга юнәлдерелгән фаразлар күп әйтелә. Шуларның иң ышанычлысы, минемчә, Украина археологы А.Т. Смиленко тарафыннан әйтелгән. Кубрат хан хәзинәсе серләрен ачуга күп көч куйган бу ханым озак тикшеренүләрдән соң, болгарлар үз патшаларын яндырып күмгәннәр (мондый йола югары катлау төркиләр өчен традицион күренеш) һәм кремация урыныннан якын гына бер җирдә аның үзе исән вакытында бүләк итеп бирелгән әйберләрен дә күмеп куйганнар, дигән нәтиҗәгә килә. Шунысы кызык: соңгы елларда Кубрат хан «хәзинәсенә» охшаш бай хәзинәләр Албания территориясендә дә, Врап һәм Ерсеке авыллары тирәсендә табылды. Биредә дә шундый ук алтын һәм көмеш савыт-саба, алар арасында Византия императоры Констанц II (641–651) тамгалары куелган ике көмеш савыт, билбау бизәкләре, сугыш кораллары һәм металл акчалар. Галимнәр фаразлавынча, бу байлык башта авар каганы кулында булып, соңыннан Кубрат ханның улы Куберга күчкән һәм әлеге «хәзинәләргә» эләккән.

Кубрат хан «хәзинәсенең» составына игътибар итик. Византия акчалары арасында күпчелекне Константинопольдә, император Ираклий хакимлегенең соңгы елларында (637/638 – 41 данә) һәм Константин II хакимлегенең башлангыч чорында сугылганнары (641–646 – 19 данә) тәшкил итә. Каеш прәшкәләре арасында бары тик югары катлау кешеләре – патрикийлар өчен махсус эшләнгәне бар. Бу, һичшиксез, Кубратка Ираклий бүләк иткән билбавы бизәге. Кызыклы факт: ул саф алтыннан эшләнгән һәм аның авырлыгы 400 граммны тәшкил итә. Элгәререк чорга караган әйберләр арасында Патерн исемле епископның император Анастасий (491–518) келәймәсе куелган тәлинкәсе, Юстиниан I (527–565) вакытында эшләнгән амфора аерылып тора. Кайбер әйберләр тупасрак, әмма күчмәннәрнең зәвыгын күз алдында тотып эшләнгән.

Полтава өлкәсенең Малая Перещепина авылы янында, хәзинә табылган урында, моннан берничә еллар элек Кубрат ханга Истәлек билгесе куелды. Татар тарихына турыдын-туры катнашы булган болгарларның беренче дәүләтенә нигез салган бөек ханыбызга Татарстан җирендә дә һәйкәл куярга вакыттыр, шәт!

PRESSA.RU

«ТАТАРСТАН» ЖУРНАЛЫНЫҢ ӘДӘБИ ПРЕМИЯСЕ





«Татарстан» журналының
әдәби премиясе

«Татмедиа» Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм «Татарстан» журналы әдәби премиягә бәйге игълан итә

«Татарстан» журналы әдәби премиясе Татарстан матур әдәбиятына сизелерлек өлеш керткән әдәби әсәрләр иҗат итүче авторларны барлау һәм иҗатларына игътибарны арттыру максатыннан игълан ителде.

Премиягә түбәндәге жанрларда иҗат ителгән кульязмалар дәгъва итә ала: роман, повесть, хикәяләр циклы. **Әсәрләрнең Татарстан турында яки Татарстан авторы тарафыннан иҗат ителгән һәм моңарчы беркайда да басылмаган булуы – бәйгенең төп шарты!**

Кульязмалар Татарстан Республикасының ике дәүләт телендә – русча һәм татарча – кабул ителә.

2017 ел дәвамында «Татарстан» журналы Экспертлар советы тарафыннан сайлап алынган текстларны журнал битләрендә һәм журнал сайтында protatarstan.ru басылып барачак.

Гран-при – китабыгызның басылып чыгуы.

2017 елның декабрендә бәйгенең жюрие ике телдә иҗат ителгән әсәрләр арасыннан җиңүчеләрне сайлап алачак – татар телендә бер әсәр һәм рус телендә бер әсәр. Икесе дә китап булып басылып чыгачаклар.

Бәйгенең шартлары:

1. Кульязманың электрон версиясе.
2. Номинант турында мәгълүмат – әсәр авторының фамилиясе, исеме, атасының исеме, контактлары – элемтә өчен телефоны, адресы).
3. Авторның кыскача иҗади биографиясе (әгәр әдәби әсәр берничә автор тарафыннан иҗат ителгән булса, һәрберсенеке).
4. Әсәрнең синопсисы.

Кульязма таләп ителгән материалларның тулы пакеты белән килмәгән очракта, жюри рәисе әсәрне кабул итмәскә хокуклы.

Кульязмалар tatarstan@tatmedia.com электрон тартмасына «КОНКУРСКА» тамгасы белән кабул ителә.

Конкурсны үткәрү вакыты 2017 елның 19 гыйнварыннан 2017 елның 15 декабренә кадәр.

Тулырак мәгълүмат protatarstan.ru сайтында.

PRESSA.RU

Ландыш Әбүдәрова 1980 елда Актаныш районы Карт авылында туа. Казан дәүләт университетының татар филологиясе һәм тарихы факультетын тәмамлый. Уфада «Кызыл таң» газетасында, Казанда «Идел», «Сөембикә» журналларында эшли. Хәзерге көндә – «Сөембикә» журналының бүлек мөхәррире. Республика вакытлы матбугатында журналистик язмалары белән дә, шигырьләре һәм хикәяләре белән дә даими күренеп тора.

Ландыш Әбүдәрова

«Татарстан» журналы өчен махсус

ЧӘКЧӘК

В деревне Бог живет не по углам...
Иосиф Бродский.

Ура! Иртәгә Өшәргә чәкчәк пешерергә барабыз! Минем әбекәй Йөзсылу түткәй – аш-су остасы, аны бөтен күрше-тирә авылларда беләләр. Фәлән авылда фәлән-фәләннең улы өйләнә, кызы кияүгә чыга яки башкода булып бара икән, дигән хәбәр телдән-телгә, колактан-колакка күчәргә өлгерми, көт тә тор – бездә телефон шалтырый. Әбекәйне чәкчәк пешерергә чакыралар.

Безнең якның чәкчәге дә әллә каян аерылып тора – бармак башы кадәрле сап-сары гәрәбәләрне чәчәк балына катырып өяләр, аңа карлыган кагыннан төрле-төрле чәчәкләр кисеп куеп бизиләр, ул көн яктысында бер төрле булып ялтырый, ут яктысында башка төрле итеп елык-елык килә. Бездә чәкчәк – туй тантанасының иң югары ноктасы. Мәҗлес ахырына таба авышкач, кияү белән кәләшне котлаулар тәмамлангач, нәсел-нәсәпнең хөрмәтле апасы кодагыйлар алып килгән күчтәнәчне баш түбәсенә куеп, бии-бии алып чыга. Кыштырдавык үтәкүренмәле кәгазьгә төрелгән тау чаклы чәкчәкне күреп, туй халкы «аһ!» итеп куя. Бер мәл тынсыз калып, аның сыйфатын бәяләп өлгергәч, дәррәү алкышлый башлыйлар. Аннары аш бүлмәсенә алып кереп китеп, кисәкләргә бүлеп чыгаралар – авыз итмәгән берәү дә калмый. Безнең якта беләләр: чәкчәк нинди – килен шундый.

Бу дәрәҗәле эшне булачак киленнең әти-әнисе оста кулына тапшыра. «Кызны үстерә белдек, ә менә чәкчәккә тотынырга куркыта. Йөзсылу түткәй, безгә дә пешереп кенә бирерсең инде, синең кулдан төшкән камыр ризыгы бигрәкләр дә уңа. Кул артың да җиңел – син пешергән белән барган килен кияү нигезенә таш булып төшә», – дип, салпы якка салам кыстыра-кыстыра чакыруларына әбекәй озак чыдамый – ризалаша. Театр уйнамый калмый үзе – тагын да мактатасы килеп ялындырган була: «Әллә нәрсә кулым китте әле соңгы араларда, уңдыралмам, дип куркам. Картаям, ахрысы...» Теге якның җавабы әзерләп куелган була инде: «Йөзсылу түткәй, ни дигән сүз ул? Аны синнән дә остарак пешергән кешене күргәнебез юк безнең, әле күптән түгел генә ерак туганнарыбызның туенда булып кайттык – синекенә җитми инде, дип анда да искә алдык», – дигәч, әбекәй бирешә.

Менә бу көнне дә әбекәй әзерләнеп көтте. Аннан бигрәк мин зарыктым, чөнки әти белән әни эштә булгач, әбекәй мине дә еш кына үзенә ияртеп йөри. Барасы кешеләрне алдан ук кисәтеп куя: «Колыным да бар инде минем», – дип кет-кет көлгән була. Шулай итеп мине дә зур кунак итеп каршы алалар. Мин дә моңа ияләнеп беттем инде, кунакта үз дәрәҗәмне белеп кенә йөрим, артык әрсезләнмим дә, кадерсезләнмим дә. Бу юлы безне алырга дип Шакирҗан бабай ат җигеп килгән. Урамда әллә ни суык түгел, шулай да салкын тимәсен, дип, мине пәлтә өстеннән шәл белән төреп, чанага чыгарып утырттылар. Әбекәй дә шәлен кат-кат урап, пешеренгәндәге кирәк-яраклары салынган төенчеген кочаклап, артка карап утырды. Шакирҗан бабай чананың алдына ук утырып: «Әйдә, малкай!» – дип дилбегәне бер кагуы булды, ат чем кара төстәге йонына туктап торган арада бәс сарган сыртын бер калтыратып алды да чананы акрын гына шудырып тарта башлады. Барган саен адымнарын тизәйтеп, юртырга кереште.

Өшәр ерак түгел, өч-дүрт чакрым гына. Озак та үтмәде, без зәңгәр буяулы, агачтан челтәрләп төшерелгән бизәкле капка алдына килеп туктадык. Бер мизгелдән ишектә өстенә куфәйке кия-кия чыгып килүче бер апа күренде. Ул туп-туры әбекәй янына килеп, ике куллап күреште, аннан соң мине иңнәремнән тотып өйгә әйдәде.

– Йөзсылу түткәй, кем исемле була әле сезнеке? Бусы кечерәгеме әле?

– Әйе-әйе, Фатыйма, бусы төпчеге – Таһирым.

Үзем турында сүз чыккач, җитдиләнә төшәм. Минем роль – тәрбияле, зур үскән малай.

– Менә бит, безнең кыз Зөһрә исемле, бик яхшы, бергәләп уйнарлар менә, дуслашырлар, – дип сөйләнә-сөйләнә болыт-болыт пар ияртеп өйгә килеп кердек. Пар таралуга, олылар арасыннан алгарак чыгам. Оп-па, дияр иде минем әти бу очракта: нәкъ каршымда кара чутыр бер кызый басып тора. Ике кулы билендә... Зөһрә шушыдыр инде. Башка вакытта җайлап кына чишенер идем, киез каталарымны, пәлтәләремне салып, үзем элеп куяр идем, бу юлы әллә нишләдем: теге кызның карашы шулай тәэсир иттеме, көтмәгәндәрәк килеп чыктыммы – кадаклаган кебек бастым да каттым. Ә теге кызый керфек тә какмый, туп-туры күземә карап тора.

– Таһир улым, чишен инде, – әбекәй дәшмәсә, күпме торыр идек икән шулай?

– Кызым, бу Таһир була, кунакны каршы ал, бергәләп уйнарсыз, – дип, теге апа оныгын кузгатмакчы була, ләкин кызый аның сүзләренә колак та салмый, мине энә күзеннән үткәреп тикшерүен дәвам итә.

– Һы, бу малай чәкчәк ашый-ашый үзе дә шуңа охшап беткән икән инде, сап-сары сипкелле, борыны да төш кебек кенә. Борын астыннан балы да агып чыккан, әнә-әнә – дип, бармагы белән төртеп күрсәтә дә, көлеп җибәрә. Тавышы яңгырап чыга, колакны ярып зыңлап-зыңлап китә. Мин «лыч!» итеп борын тартып куям – салкында җебегән генә ул, маңка малай дип белдеңме әллә мине?

– Зөһрә, дим, сиңа әйтелгән бит, кунак малаен кыерсытасы булма! Ишетсен колагың! Кара аны! – Шулчак кулына ботинкаларын тотып, мич арасыннан яшьрәк кенә бер абый чыга. Зөһрә дигәннәренең әтиседер инде: чем кара чәчле, кара мыеклы. – Исәннәрмесез! Әйдәгез, узыгыз, кыенсынып тормагыз, – дип безгә юл бирә.

– Бир бишне! – дип, миңа кулын суза. Югалып калмыйм, шунда ук шап итеп аның кулын кысам.

– Маладис, Таһир! Шәп егет! – ди дә мыеклы абый, миңа күз кыса, үзе Зөһрәгә ымлап: – Нык тор! – ди. Мин аның ни әйтергә теләвен төшенеп җитмим, шулай да аның теләктәшлеге көч бирә. Аның бу сүзләре көн дәвамында күп тапкырлар искә төшәчәк, билгеле, чөнки алда мин сөйлисе вакыйгалар, нәкъ чәкчәк кебек, бер-берсенә ябышып барды, җыйгач, озаклап искә төшереп сөйләрлек олы бер өем хатирә булып укмашты.

Бергәләп бал, ак күмәч белән чәйләп алгач, өлкәннәр, озакка сузмыйча, эшкә кереште. Әбекәй үз эшен әйбәт белә,

Иллюстрация: www.tea-terra.ru

PRESSA.RU

чигүле альяпкычын япты, башына ак яулыгын чөеп бәйләп куйды. Бу рәвешле киенгәч, аның болай да нурлы йөзе тагын да яктырып китә, ләкин кыяфәте җитдиләнә төшә: әбекәй пешеренгәндә артык сүз сөйләшми, бу вакытта аны эшеннән бүлмәвең хәерле. Шуңа да мин, кунакта булсам да, әбекәйдән ераграк йөрим. Аңа ярдәм итүче хуҗа апа да йөгергәләп, ул кушканны гына үтәп йөри.

– Казан астына чыра тык!

– Төшне болгат!

– Майны кара!

– Күмерен ал, бераз сүрелсен! – Менә шундый фәрманнар гына бирә әбекәй, башка вакытта йомшак, ягымлы итеп сөйләшә торган Йөзсылу түткәйне алыштырып куйганнармыни?!

Шуңа күрә дә чәйдән соң миңа теләсәм дә, теләмәсәм дә, Зөһрәгә иярүдән башка чара калмый. Зөһрә үзе усал булып кыланган гына икән, икәү калгач, уенчыкларын күрсәтеп чыкты: аның курчакларының минем өчен ни кызыгы бар инде? «Әйдә мин сиңа бер нәрсә күрсәтәм», – дип, караваты астыннан бер тартма сөйрәп чыгарды. Анда бик күп конфет кәгазьләре ята иде. Шулар арасыннан Зөһрә ялтыравык кәгазьне алды да: «Менә иснәп кара», – дип, борын төбенә сузды. Чыннан да тәмле ис килә иде – шунда ук таныдым: җиләкле сагыз кәгазе. «Минеке дә бар иде мондый», – дигән булдым, борын тартып. «Алма апаны сорарга килгәндә, булачак җизни алып биргән иде, бетте инде. Сиңа да калдырган идем, иртән чәйнәп карыйм әле дип каптым да ялгыш йоттым», – диде дә чылтыратып көлеп җибәрде.

Башка күрсәтер уенчыклары калмагач, качышлы уйный башладык. Берсендә Зөһрә мич башына менеп качкан булып чыкты. Әбекәйгә бу җаваплы эшен башкарганда якын килергә ярамаганны мин беләм дә ул, ә менә Зөһрә – юк. Гөнаһ шомлыгы, мич башына киптерергә кабак төшләре куйган булганнар. Зөһрә кыштыр-кыштыр килгән арада шуның берничәсе казанга төшкән. Әбекәй чыжлап торган майга салырга дип иләктәге төшен или-или казанга таба килсә, тегендә кабак төшләре чыжылдап йөзеп йөри. «Һай, җаным!» – дип кычкырып җибәрмәсенме әбекәй! Аның тавышына хәтта ки Зөһрә дә куркуыннан тизрәк шылу ягын караган – каравын караган да, күлмәге белән эләгеп калган. Күлмәк шунда ертылып китеп, Зөһрә чатлык арасына мәтәлеп төшкән.

Шуннан безне, бәладән башаяк, дип, урамга чыгарып җибәрергә карар иттеләр. «Әбей, тау шуарга барабыз алайса!» – диде Зөһрә чыгып киткәндә. Аңа мин булгач әллә ни эләкмәде. «И-и, бала, кайнар майга төшкән булсаң соң!» – дип бот чаптылар да күлмәген алыштырып киендереп тә куйдылар. Шакирҗан бабай – аны Зөһрә «бабаем» дип йөртә – мал карарга чыгып бара иде, аңа безгә күз-колак булырга куштылар. «Бабаемнан курыкма, ул күп сөйләшми, әбей аны коры, ди нигәдер. Шулай да мине бик ярата», – дип кисәтеп куйды урамга чыккач Зөһрә. Ә Бабайга нәрсә? Арттан ишек ябылуга, юлларыбыз аерылды безнең: ул – лапаска, без урамга таба юл тоттык. Кәнүшнәйләрендә ялманып көткән бозаулары янына бармыйча, безне җитәкләп йөрергә бала-чагамыни ул?

Урамда мин дә, ниһаять, иркен сулыш алдым. Хәзер бөтенесен дә үз кулыма алырга кирәк, егет кешеме мин ахыр чиктә, юкмы? Алдан сөйләшкәнчә, тау шуарга киттек. О-хо! Биек икән таулары! Җитмәсә, текә дә әле.

– Әйдә, син минем чанада шуарсың, мин менә бу палитилинда, – дип, Зөһрә юмартлык күрсәтте. Аны-моны әйткәнче, чанага утыртып, этеп төшереп тә җибәрде. Моңа кадәр болай ук биек таудан төшкән юк иде әле, куркуымнан чытырдатып күзләремне йомдым. Күпме төшкәнемне белмим, Зөһрә: «Борыл-борыл!» дип кычкырды бугай, ләкин мин кая, ничек борылырга икәнне абайлап өлгергәнче, «дыңк!» итеп килеп бәрелдем. Дөнья тып-тын булып калды, рәхәт итеп әйләнеп тора. Күпме вакыт узгандыр, әкрен генә күзләремне ачсам, өстән алты күз карап тора. Зөһрәнең шомырт күзләрен шунда ук танып алдым, тагын ике түп-түгәрәк күз... аю түгелдер инде? Ә-ә, эт икән. Теге икесе? Таныш түгел бер малай.

– Уф, үлмәгән икән әле, – дип, җиңел сулап куйды Зөһрә, мин күземне ачуга.

– Әйдә, торгызып карыйк, – дип, теге таныш түгел малай кулларын сузды. Аларга тотынып торып бастым. Эт тә сөенгән була, сикерә-сикерә битемнән яларга маташа.

Күзләремне йомып төшкәндә, чана бераз гына кырыйга алдырган икән, һәм мин өч кешенең колачы да җитмәслек карт өянкегә бәрелгәнмен. Елыйсы килгән иде, борын да җебеп төшкән иде инде, әтинең «Егет кешеләр еламый!» дигән сүзләрен искә төшереп, тыелып калдым. Зөһрә алдында да, бу таныш түгел кәтәнә малай алдында да авыз күтәреп елап тораммы соң?

Ләкин бераздан теге бәләкәй буйлы малай тату гына уйнысы урында үчекләшә башлый. Зөһрә дә кимен куймый, тегенең бер сүзенә бише белән җавап кайтара:

– Мин барыбер ераграк шуам, син үзең куркак. Фуу, – дип борын җыерган була шул арада артистланып. – Исе чыкты, шыр җибәрдең әнә.

– Аның каравы мин ераграк сикерәм! – ди тегесе – Рөстәм исемле икән.

– Мине тота да алганың юк бит әле синең. Башта куып тотып кара, – дип, Зөһрә чаба башлый. Рөстәм чыннан да җитез икән, ике атлап бер сикерүгә, кызыйны куып тота да ега. Зөһрә дә маһы бирми – җавап итеп сугыша башлый.

– Әй, туктагыз, сугышмагыз, – дип тегеләрне йолыккалый башлыйм, ләкин аерып ала торган түгел. Һәркайсы «Мин җиңәм!» дип сугыша. Шунда «кытырт» – кайсыныңдыр киеме ертылган тавыш ишетелә. Бер мизгелгә тынлык урнаша. Зөһрәнең якасы яртылаш умырылып чыккан икән, җилфердәп тора. Менә шунда туктарга кирәк тә бит! Юк, Зөһрә аны бер кулы белән сыпырып алгандай итә дә, янә Рөстәмгә килеп ябыша. Миңа нишләргә соң? Кушылып сугышыр идем, кунак малайга алай килешми. Аптырап Рөстәмнең пәлтәсенең бавыннан тарта башлыйм. Шунда башка бер уй килә!

– Әйдәгез, сикереп карыйк, кем ераккарак сикерә – шул җиңә!

Тегеләр туктап кала. Торып басып өсләрен каккалыйлар да, берни булмагандай, ризалашып сикерергә урын эзли башлыйлар. Иң кыю фикер кем башына килгәндер, дисезме? Дөрес, Зөһрәнекенә: инеш аша сикерәчәкбез. Беләм инде, Рөстәм кыр кәҗәсе кебек елгыр, ул җиңәчәк. Аннан бер башка озын була торып, җиңелеп ятып булмас, кыз кешегә дә бирешмәскә кирәк.

Чишмәдән берничә адым киткәч, басмалары бар икән, шуның янында карны таптап такырайтып бетергәннәр. Менә шул урыннан сикерергә кирәк. Зөһрә тиз генә санап та ала:

Бер, ике, өч, дүрт, биш

Мич башыннан егылып төш!

Рөстәмгә чыга. Кызу канлы малай икән:

– Син хәрәмләштең, дөрес санамадың, шундый санамыш буламыни? – дип тезеп китә.

Күз алдына яңа дустымның әле иртән генә мич башыннан мәтәлүе килеп баса да көлеп җибәрәм.

– Бүген генә егылып төштең бит әле, – диюем була, күз алдында йолдызлар биеп ала.

– Ярар, синеңчә булсын, үзем сикерәм, – дип, ризалашам тизрәк, кызлар белән әйткәләшеп торырга егет кеше лә мин!

Һәм артка таба берничә адым китәм дә: «Бер-ике-өч!» – дип, йөгереп килеп сикерәм... Аяк астында каты җирне тоюга авызлар ерылып китә. Шулай да җитдилегемне сакларга тырышам: имеш, минем өчен бу сикереш чүп кенә!

Икенче булып Зөһрә сикерә, өченчегә Рөстәм чабып килә. Шулчак күз кырые белән генә басма читеннән Зөһрәнең аяк сузганын күреп калам. Кап-кара киез-каталары, мамыктан бәйләнгән бияләйләре белән дүртаяклап басып кала.

– Чу-кын-ды... – ди Зөһрә әкрен генә. Һәм җәһәт кенә Рөстәмне артка таба сөйрәп чыгара. Тегесе нәрсә булганын аңлаганчы, кызый үзе минем артка качарга өлгерә.

– Ну, беттең инде! – ди Рөстәм, тизрәк аягын кага-кага, ләкин атлаган саен, аның юеш каталарына күбрәк кар сылана.

– Тиеп кара, әнигә әйтәм! – ди Зөһрә.

– Мин сине үзем әйтәм әле әнигә, – ди дә, Рөстәм әнисен исенә төшерепме, әллә кайткач, юеш каталар өчен эләгәчәген уйлапмы, авызын чалшайтып елап та җибәрә. Рөстәм урынында мин дә елар идем, аны жәлләп куям.

– Син уйлап чыгардың сикерүне, син гаепле, – дип, миңа да эләгә ул арада.

Ул инде әнә елый-елый кайтып бара, ә Зөһрә артыннан үчекләп кала:

Елак-елак, елкы колак,
Карама таяк, карт әтәч!

– Әйдә, озатыйк Рөстәмне, – дим.

– Озатты, ди, менә, көтеп тор! Аның елаган тавышына әнисе йөгереп чыгып киракне бирер, – ди Зөһрә, берни булмагандай. – Әйдә, кайта торыйк, аның әнисе бүген барыбер безгә киләчәк болай булгач.

Чананы тартып, аңа иярәм. Бераз киткәч, ул кырт борылып туктап кала.

– Синең тимергә телеңне тигереп караганың бармы? – дип сорый ул кинәт.

– Бар, – дим.

– Авыртканчымы?

– Юк, авырта башлауга алам.

– Ә минеке авыртмый, – ди ул, мактанып. Һәм, чанага ятып, телен алгы тимеренә ябыштырып та куя.

– Нишлисең? – дип әйтергә дә өлгермим, кубарып та ала.

– Әл-ләл-ләл, әчеттерә, – ди ул, иреннәрен кысып. – Хәзер син.

– Юк, – дип карышып карасам да, Зөһрә: «Авыртмый ул, аны-моны сизгәнче, тартып алырга гына кирәк», – дип үгетләгәч, ризалашам.

Тиз ябыша каһәр – тик менә алырга куркыта.

– Ал инде, ал, – ди Зөһрә.

– Алалмыйм, куркам, – дип әйтмәкче булып мыгырдыйм.

– Тиз бул, алалмыйсың аннары, – дип түземсезләнә, минем тел чымыр-чымыр итә инде.

– Ыыы-ыыы-ыыы, – дим көчлерәк итеп. Зөһрә иелеп, ике кулы белән каплап, сулышы белән минем телне җылыта башлый. Шулчак безне бер төлке бүрекле абый куып тота.

– Колак тешләшәсезме әллә? – дип төрттерә улерактан ук. Зөһрә теге абыйны күргәч сикереп тора да: «Тизрәк бул инде, нәрсә маташасың?» – дип, минем башны чанадан аерып та ала. Телем чанага ябышып калгандай тоела башта, аннан соң авызга сыймый башлый. Ул арада Зөһрә теге абыйга кар атып кала. Көлә-көлә чаба төлке бүрекле абый, аңа рәхәт. Ә минем авызда – утлы күмер! Шушы кызның сүзен тагын бер тыңласаммы? Исемем Таһир булмасын, егет кеше дигән ат күтәреп йөрмим дә!

– Авыртамы? – ди Зөһрә кәефсез генә. Мин турсаеп барам. Тизрәк кайтып җитәргә иде, әбекәйнең чәкчәге пешкәндер инде, түгәрәк төш йөздереп, җылы чәй эчәр идем, ичмасам.

Тагын биш-алты өй арасын маҗараларсыз гына кайтып җитәбез. Мин тагын бер җиңел сулап куям. Ниһаять, җылы өйгә керәбез, дисәм – Зөһрә миңа умырылган якасын күрсәтә. Күрсәләр, беттек, янәсе.

– Кайттыгызмы, балалар? – ди аз сүзле Шакирҗан бабай безне күргәч. Мал чиләге тотып келәткә барган җиреннән туктап, безне баштанаяк күздән кичерә дә, үзенчә «дүрт саннары төгәл, бурыч үтәлде» дигәндәй, юлын дәвам иттерә.

– Син минем арттан керерсең, тиз генә пәлтәңне салып эләрсең, күрмәсләр әле, – дип, үземчә үгетләгән булам.

– Юк, әбей кайтып керүгә, мине әйләндереп карый башта, аннан соң гына чишенергә була, – ди Зөһрә. – Берәр нәрсә уйларга кирәк…

Аның нәрсә уйлаганын алдан белсәм, яисә алдан күрү сәләтем булса, ай-ваена карамыйча өйгә кереп шыпырт кына, хәтта ки чәкчәкне пешереп, кайтыр сәгать җиткәнче кымшанмыйча да бер почмакта утырыр идем, валлаһи. Ләкин шушы ут кебек кызның чәнечкеле йомгак икәнен алдан белмәвем белән харап булдым мин ул көнне.

Бабай чиләген келәттә калдырды, чанага зур савыт утыртып, чишмәгә юл тотты. Аның китүен генә көткән кебек Зөһрә арт бакча капкасының келәсен ычкындырды да, мине дә үзе артыннан әйдәп, утарга алып чыкты. Киртә белән уратып алынган утарда бер дистә тирәсе сарык бәрәннәре белән печән кетердәтә. Араларында зур мөгезле тәкә дә бар. Зөһрә бәрәннәрне сөймәкче булып, киртә арасына кулын тыкты. Тегеләре чәчелде дә бетте. Тәкә генә алгы сыйрагы белән тибенеп сарыклар алдына чыгып басты. Аның болай кылануы кызыйны котыртты гына, ахры. Ул мәче җитезлеге белән киртә аша тәкә алдына сикереп төште һәм янә улакка сикерде.

– Таһир! Әйдә тәкә котыртабыз! Теге баштан бу башка кем тиз генә тәкә алдыннан йөгереп үтә – шул…

– Юк, йөгерәсе килми минем, – дип аны бүлдереп карыйм. Ләкин бу кызый «юк» дигән сүзне аңламый бугай.

– Әйдә инде, куркасыңмы әллә? – белә ул нәрсә белән алдырасын! Батыраеп утар эченә кереп басам да, теге тәкә аны-моны аңышканчы, каршы якка йөгереп үтәм.

– О-хо! – ди Зөһрә торып басып. – Хәзер мин!

Ул да мәче җитезлеге белән каршы якка йөгереп үтә. Сарык тәкәсе, аңлапмы-аңламыймы, безне күзәтүен дәвам итә. Бу уен миңа да кызык була башлый, хәзер без икәүләп кара-каршы йөгерәбез. Биш-алты тапкыр шулай йөгереп үтәбез, җиденчесендә нәкъ арт ягыма «дык!» итеп бәрәү китереп бәрә. Аякларым җирдән аерылганын сизеп калам һәм бер мизгелдән лап итеп, ләкин йомшак кына бишеккә салган бәби кебек печән тулы улакка килеп төшәм. Зөһрәнең теге «Чу-кын-ды!» дигән «фирменный» сүзен ишетеп калам. Күз алдында йолдызлар вальсы тәмамланугa, астыма җылы йөгергәне тоела башлый. Авыртуны курку алыштыра, куркуны – гарьләнү. Ләкин еларга ярамый! Егет кешегә…

Әмма күз яшьләре мине тыңламый инде, гарьлегемнән бөтен дөньяга ишетелерлек итеп кычкырып елап җибәрәм. Күңелнең әллә кайсы бер почмагында: «Хәзер Зөһрәгә яка өчен эләкмәячәктер инде», – дигән хыянәтчел бер уй йөгереп уза… Ул арада җәһәт-җәһәт атлап бабай килеп җитә. «Нәрсә булды инде тагын, кызым?» – дип сөйләнә-сөйләнә, ул мине күтәреп ала, шунда күзгә утар кырыена өелешеп, өннәре алынып карап торучы сарыклар чалынып кала. Мин хәтта аларның күзләрендә кызгану хисен тойгандай булам, ә менә Зөһрәнең карашында кызыксынудан битәр берни юк.

Мин акырып елаган, Зөһрә туктаусыз такылдаган, аз сүзле бабайның да теле ачылып оныгын битәрләгән хәлдә шау-гөр килеп өйгә килеп керүебез ике әбине дә сагайта, әлбәттә. Эшләре никадәр генә җаваплы булмасын, буленми хәлләре юк. Әмма әбекәйнең чәкчәге уңган, үзеннән канәгать чакка туры килдек – ул тыныч кына мине юатырга керешә, ә Зөһрәне акылга утырту вазыйфасын әбисе үз өстенә алды. Бабайга да күз-колак булмаган өчен каты гына эләкте. Ул янә дәшмәс булды. Кулын селтәде дә чыгып китте.

Ә иң зур гарьлек алда иде әле: миңа мәҗбүриләп Зөһрәнең колготкиларын, гамажын һәм оекбашын кидерделәр. Өйгә кайткач, әни, кием алыштырганда, сигез күгәргән, сыдырылган урынны санады, телем турында әйтеп тормадым инде. Аның каравы, әбекәйнең чәкчәге тәмле килеп чыккан иде – күчтәнәчкә төйнәп җибәргән тәмлүшкәләрнең иң истә калганы шул булды, тәме әле дә кышның шушы озын бер көнен искә төшереп, тел очында тора. Хәзер инде мин бу көн турында, Зөһрәдән кача-поса, балаларыбызга сөйлим. Ул сөйләмәскә куша: ояла бугай. Уларымны: «Егет булыгыз!» – дип искәртергә дә онытмыйм.

* Өшәр – Актаныш районында 1970 елларда Түбән Кама ГЭСы төзелү аркасында су басу зонасында калып бетерелгән авылларның берсе. Картадагы атамасы – Иске Симыстрау (Старый Семиостров). Бу вакытта су басу зонасында калып, тагын берничә зур авыл (Тат. Әҗби, Рус Әҗби, Чиялек (Яңа Симыстрау), шәһәр тибындагы Дербышка (Дирбүшкә) бистәсе бетерелә. Хәзер анда иксез-чиксез булып печән болыннары гына җәйрәп ята. Әле дүрт дистә ел элек кенә бу урыннарда авыл булуы турында ташландык хәлдәге зиратлар гына сөйли…

Декабрь 2016 – гыйнвар 2017

PRESSA.RU

БЕЗ ОНЫТКАН ҺӘМ ОНЫТМАСКА ТИЕШ ХӘТЕР

Автор:
Луиза Янсуар

Танылган фантаст Орсон Скотт Кардның «Игра Эндера» дигән фәнни-фантастик әсәрендә шундый гыйбарә бар: «Я есть то, что я помню». Кайчандыр Рене Декарт игълан иткән «Я мыслю, следовательно существую» дигән атаклы фәлсәфи тәгълиматның дәвамы буларак та кабул итәргә мөмкин моны. Яңа заманда без инде «хәтер», «вакыт» һәм «чынбарлык» төшенчәләренең шактый иллюзор, шартлы булуына инандык. Әмма шулай да безне хәтер саклап тора бугай.



«УЛ МИНЕ ТӨШЕНДӘ КҮРГӘН ИКӘН...»

СЭМ ТЭЙЛОР. АМНЕЗИЯ.

Туу-Үлем кисемтәсенә нигезләнгән дөнья картинасы яңа заманда актуаль булудан туктады. Һәм, аңлашыла ки, XX–XXI гасырдагы язучыларның әсәр фактурасын да сизелерлек үзгәртте. Кафка, Майринк, Борхеслардан килгән традицияләрдән, Роб-Грийе белән Натали Саррот тәгаенләгән «яңа проза» шаукымыннан соң да дистә еллар узды. Безне хәзер медиакиңлектә гаять популяр булган Милорад Павич белән Харуки Муракаминың «линияле булмаган» прозасы да гаҗәпләндерми. «Контркультура» сериясендә китаплары басылган күпчелек авторларның сюрреализм белән абсурдны укмаштырып, аңа тагын әллә никадәр ингредиентлар өстәгән трэш, китчы да сискәндерми. Шунысы анык: бүгенге узаңыбыз тәкъдим ителгән дөнья картинасының барлык төрләренә дә әзер.

Кайчандыр Аргентина язучысы Хорхе Луис Борхес: «Человеческая память – не итог, а лишь хаос вероятностей», – дип язган иде. Британиянең бүгенге өметле прозаикларының берсе Сэм Тэйлор да – нәкъ шушы теориянең тарафдары. Юкка гына аның каһарманы әсәрнең буеннан-буена үзе белән Борхесның «Лабиринты» китабын йөртми. Һәм, аннан да бигрәк, әсәрнең буеннан-буена башваткычлар яратучы Аргентина авторының «Фунес, Помнящий» хикәясен укып бетерә алмыйча җәфаланмый. Ә аңа кадәр шул ук Борхесның «Другой» хикәясендәге очрашуны үз язмышына үлчәп карый каһарманыбыз Джеймс Пэдью. Әйтерсең, бу юллар нәкъ менә аның хакында язылган:

Он почти не слушал меня. Вдруг сказал:
– Если вы были мною, как объяснить ваше забвение встречи с одним пожилым сеньором, который в 1918-м сказал вам, что он тоже Борхес?
Я не подумал об этой опасности. И отвечал не очень уверенно:
– Видимо, этот случай показался мне столь удивительным, что я постарался его забыть.

Һәм менә шулай бер әсәрдән икенчесенә күчеп, лабиринтның бер борылышыннын башкасына алып чыгып, Сэм Тэйлор безне постмодернистик пространстволарның чиксез булуына, һәм яшәеш модельләренең дә башы-азагы юклыгына төшендерергә омтыла бугай, дип уйлап куясың. Нигездә, шулай булып чыга да.

Хәтер лабиринтының башлангыч ноктасы – Амстердам шәһәрендәге мәһабәт каналга карый торган гадәти бер йорттагы кечкенә генә фатир. Каһарманыбыз Джеймс Пэдьюга 30 яшь. Нәрсә бу – урта яшьләр кризисына ишарә түгелме? Ул бу фатирда сөйгәне Ингрид белән инде биш ел яши. Көннәрдән бер көнне, телефон шалтырагач, трубканы алырга йөгергәндә, егылып, аягын сындыра да гипста утырырга мәҗбүр була Джеймс. Һәм, аңлашыла инде, чарасызлыктан, эше юклыктан, үткәненә кайтып, тормышына анализ ясый башлый. Караватастыннан махсус тартмага тутырып яшереп куелган көндәлекләрен табып ала. Шуларны актарып утырганда, кинәт кенә бикләп куелган, ачкычы яшерелгән кара металл тартмачыкка – сейфка тап була. Ачкычның кая булуын исенә төшерергә тырыша. Төшерә алмый. Әмма бу сейфта 1991–1994 елларга караган көндәлекләре бикләп куелган икәнлеген төгәл хәтерли ул. Анысын хәтерли, тик менә шул өч ел гомерен – бөтенләй хәтерләми. Алай гына да түгел, шул өч ел эчендә ниндидер төзәтеп булмастай вакыйга булып, тормышының котылгысыз борылыш алуын да тоныкына төсмерләгәндәй була. Тик нәрсә булган да, нәрсәне оныткан соң?!

Шушы мизгелдән Джеймсның тормышы тоташ җәза булып әверелә. Аның миен бары бер сорау гына борaулый: ачкычны ничек эзләп табарга? Акрынлап бу сорауга калганнары да килеп кушыла: әгәр мин бу көндәлекләрне шулай ныгытып яшереп куйганмын икән, берәр җинаять эшләмәдемме икән? Мине кем дә булса эзәрлекләмиме? Һәм гомумән Джеймс Пэдьюмы мин?

Акрынлап аның гасаби сорауларына җаваплар да табыла башлый.

Әйтик, пабта утырганда, берәү килеп аның белән нәкъ менә хәтер темасына сөйләшә башлый. Төшләрендә ул ниндидер параллель тормышларда адашып йөри. Ахыр чиктә, Джеймс үзенең чынбарлыктагы тормышын, Ингрид белән араларын өзә дә, баштанаяк хәтер лабиринтларына кереп бикләнә. Яшьлеге узган Британиягә юл тота. Шундагы бер шәһәрчеккә килеп, аның урамнары, тыкрыклары, парклары буйлап йөри башлый. Һәр йорт, һәр урам, һәр чаттан аңа яшьлеге бага сыман тоела. Кафелардан яңгыраган музыка, подъездларның төс-кыяфәте, ачык тәрәзләрдән аңкыган исләр – барысы да үтә таныш тоела аңа. Һәм менә «Белый медведь» исемле пабта утырганда кинәт ул газетадагы гороскопка юлыга – әйтерсең, гороскопта нәкъ аның турында язылган. Аннары янәшәсенә килеп утырган бер әфәнде Джеймска бөтенләй башка кешегә мөрәҗәгать иткәндәй... танып эндәшә.

Впервые в жизни Джеймс Пэдью видел юного Джеймса Пэдью не как несовершенную версию себя самого, а как другое существо. Бедный ты мой, подумал Джеймс. Если бы я мог вернуться назад и утешить тебя! Взять за руку и вывести из лабиринта! Но путешествия во времени придуманы писателями. В жизни человеку суждено в одиночку блуждать в потемках настоящего. И тут он повернулся, взглянул мне в глаза, недоверчиво усмехнулся. И захохотал.
В это мгновение я перестал существовать. Я привык считать, что это он мне снится, но, когда он рассмеялся мне в лицо, я понял, что на самом деле это я ему снюсь.

Каһарманыбызны бу катлаулы йомгак шулай акрынлап-акрынлап Лаф-стрит, 21 нче йортка китереп чыгара. Аны бу йортның хуҗасы – Малкольм Трюви көтә булып чыга. Йортларны арендага бирүче контора клерклары гаҗәпкә кала: күпме еллар дәвамында кешесез каңгыраеп торган йортка берәүне дә якын китермәгән Трюви кинәт кенә, Джеймсның исемен әйтүгә, аны кичекмәстән бирегә урнаштыруларын таләп итә. Урнашкач та, Джеймс бу йортта кайчандыр җинаять булуы хакында белеп ала... Йорттагы һәр бүлмә, һәр җиһаз аңа нәрсәнедер хәтерләтә...

Кара металлдан эшләнгән сейфтагы көндәлекләр кебек үк, йортта да аның аналогы табыла – көн аралаш телефон шалтырый, әмма ул агач тартма эченә яшереп куелган. Һәм, йортны арендалау инструкциясе буенча, Джеймска аңа кагылу катгый тыелган. Килгән хатлар «Малкольм Трювига» дип тамгаланган. Һәм тора-бара Джеймс бу зат мин үзем түгелме икән, дигән шиккә үк төшә...

Психологик башваткычны хәтерләтүче бу әсәр безне үз хәтеребез лабиринтлары буйлап сәяхәткә чакыра. Куркытырга теләми автор, ә кисәтә: «На восемь десятых память – это то, что мы забыли, и на две десятые – то, что придумали».

Роман буйлап Лондонның куе томанын ерып баргандай барасың-барасың да... ахыр чиктә җиңел сулыйсың. Чөнки аңлыйсың: Сэм Тэйлор барлык мистификацияләр томаны аша үз кризисларыбызны, үзебез үк уйлап чыгарган ялган «мин»нәрне җиңәргә һәм, җаваплылыкны үз өстеңә алып, бала-чага булудан туктавыңны танып, тормышка йөз белән борылырга чакыра. Сүз онытү турында түгел, ә искә төшерү турында бара. Үзеңне.

«БАР ДА КӨНЧЫГЫШТАН БАШЛАНА...»

ЭМИ ТАН. КЛУБ РАДОСТИ И УДАЧИ.

«Все начинается на востоке, – сказала мне мама однажды, – с восточной стороны встает солнце и приходит ветер»...

Шулай дип кабатларга ярата әнисе кызына... «Клуб радости и удачи» романы төп героиняның әнисе үлеменнән һәм аңарга васыять булып әнисенең маджонг уйный торган клубы калудан башланып китә. Юк, бу рәсми исемнәре, статуслары булган оешма түгел, ә әнисенең Америкадагы дуслары җыелып, кытай милли ризыклары әзерләп, чәйләп, гәп корып утыру урыны. Ягъни үзенә күрә глобальләшкән Көнбатыш дөньясы эчендәге милли оазис.

Сан-францисский вариант Клуба радости и удачи мама организовала в тысяча девятьсот сорок девятом, за два года до моего рождения. В тот год мои родители уехали из Китая с одним только жестким кожаным чемоданом, набитым дорогими шелковыми платьями. Захватить с собой что-либо еще не хватило времени, объяснила мама папе уже на корабле. Но его руки все еще продолжали лихорадочно перерывать скользкие шелка в поисках полотняных рубашек и шерстяных брюк.

Әсәр җиңелчә генә нотадан башланып китә дә, көтмәгәндә-уйламаганда, әнә шундый чынбарлыкны күз алдына китереп бастыра. Һәм аңлыйсың: юк, сүз маджонг уены, аталар белән аналар проблемасы хакында гына түгел, ә тамырлары белән кубарылып, иммиграциягә китеп, бөтенләй башка туфракта тамыр җәеп тә, үзләрен саклап калырга тырышучы халык һәм аның аяныч язмышы турында барачак.

Эми Тан – Америкада яшәп иҗат итүче, нәселе белән Кытайга барып тоташучы язучы. Кытайларның Америкада үзләрен ничек тоемлавы, милли идентификация мәсьәләсе – аның төп темалары. Әсәрләренең автобиографик башлангычын үзе үк таный Эми Тан. Әмма ул моны турыдан-туры кабул итмәскә өнди: кеше иленнән, ватанынан никадәр ераклашса, милләтенә караган бөтен тарихлар да аңа үз гаиләсенең тарихы кебек булып тоела башлый, шулай итеп, ул үз тамырларын саклый, хәтерен югалтмаска омтыла, дигән карашта тора язучы.

«Клуб радости и удачи» дүрт хатын-кыз авызыннан сөйләнә торган новеллаларны хәтерләтә. Бу китапта – хатын-кызлар галәме. Монда алар хөкем сөрә. Ир-егетләрнең роле – икенчел. Аларга кадер-хөрмәт булмаганга түгел, киресенчә, кытай гаиләсендә ир затына нинди олылау белән карауны һәр дүрт героиня һәм сүзе, һәм гамәле белән даими ассызыклый. Эш – башкада. Нәселне гореф-гадәтләр, традицияләр аша – гап-гади чәй пешерү рецептыннан башлап, Ай бәйрәменә киелә торган махсус ефәк күлмәккә чигелгән нечкә бизәккә кадәр – нәкъ менә хатын-кызлар үз кулында тотып тора.

Әниләр белән кызлар арасындагы катлаулы, четерекле мөнәсәбәтләрне җентекләп, детальләп сурәтли Эми Тан. Шуларның берсе ире Харольд белән гаиләсен Көнбатыш рухында корып, үзен күңеленнән

генә барыбер дә ризасыз тоеп яшәүче Лена Сэнт-Клэр. Икенчесе әнисе яраткан кешесен кабул итмәс, аңа кияүгә чыгарга мөмкинлек бирмәс дип шикләнгән Уэверли Чжун. Өченчесе – Кытайда язмышының бер төенен калдырып, тормышын өр-яңадан – чиста биттән башларга мәҗбүр булган Линдо Чжун. Дүртенчесе – кызының ялган иллюзияләр, ялган тормыш белән яшәвен тоеп, аны шул баткаклыктан коткарырга теләүче Иннин Сент-Клэр. Һәм аларның барысын да берләштереп торучы – безнең героиня. Цзиньмэй У. Нәкъ менә аңа, моңарчы әнисе төйнәп торган кебек, барлык героиняларның язмышларын бер төенгә төйнәү вазыйфасы йөкләнә:

И тут до меня доходит. Они испуганы. Они видят во мне своих собственных дочерей, не очень-то интересующихся их прошлым и ничего не знающих о надеждах, с которыми их матери ехали в Америку. Дочерей, которым не хватает терпения выслушивать их, когда они говорят по-китайски. Дочерей, считающих своих матерей недалекими, оттого что те изъясняются на ломаном английском. Дочерей, чьи куцые американские мозги не способны понять, что слова «радость» и «удача», даже поставленные рядом, не передают известного каждому китайцу простого иероглифа «фу». Дочерей, вынашивающих детей, понятия не имея о переходящей из поколения в поколение надежде.

Һәр ике буынның – үз хакыйкате. Язмыш бирегә китереп ташлагач, балаларын монда табып, монда үстергән өлкән буынга караган ханымнар теше-тырнагы белән милли генофондны сакларга омтыла, кызларына үз тарихын сөйләргә мөмкинлек таба алмаганга пошына. Ә Америка хыялын балачактан социумда сеңдереп үскән яңа буын вәкилләре – инде үзләре дә урта яшькә җитеп килгән ханымнар исә, киресенчә, яхшы җирдән качып килмәсләр иде, дип исәплиләр. Артка борылып карарга теләмиләр. Әниләренең аларны үстергәндә Кытай турында сүз чыкса йөзләренә бәреп чыккан әрнүе дә моңа сәбәпчедер, бәлки. Үз ватаннарында барысын да югалтып, Америкада барысын да яңадан башлый алганнар икән, бу илгә рәхмәтле булырга тиешле әти-әниләр, дигән инану яши яңа буынның күңелендә.

Әмма... маджонг – уен гына түгел икән. Бу уенда башкаларның һәр адымын барлап тору зарур. Алай гына да түгел, янәшәдәге уенчыларның алдагы адымнарын юрап кую, анализлау да кирәк. «Синең әнием менә дигән уенчы иде», – диләр ханымнар Цзиньмэй Уга. Һәм уен саен аңа әнисенең язмышын, үз ватаннарының гади булмаган тарихын да сөйлиләр. Шулай итеп Цзиньмэй У әнисенең әлеге Клубны Куэйлиньда ире – кытай офицеры японлылар белән сугышка чыгып киткәч оештыруы хакында белә. Озын-озак шомлы кичләрне шулай уздыра торган була офицер хатыннары. Япон гаскәренең шәһәргә якынлашуы турында хәбәр алгач, ул ике кызын җитәкләп, өйдә булган малны чемоданнарга төяп, качып чыгып китә. Офицер хатыннарын һәм гаиләләрен японлылар мәсхәрәләп, газаплап үтерә, дигән хәбәр ил буйлап йөри, чөнки.

Әмма юлда каты авыруга сабышып, барлык малын, йөрәгеннән өзә-өзә, юлда сибеп калдырып, ярымүле хәлгә җиткән бу ханым, ахыр чиктә, кызларын юлдагы кешеләргә саба – минем белән ни булса-булыр, балаларым исән калсыннар, ди. Аның гәүдәсен табып алганда, ике кызын инде үзләре белән бер крестьян гаиләсе алып киткән була.

Озак эзли ул кызларын җимерелгән, пыран-заран китерелгән шәһәр буйлап. Йортларының эзе калмаса да, таныш-белешләре нәселләп-нәселләп кырылып бетсә дә, кемгә барып бәрелергә, ярдәм сорарга белмәсә дә. Эзли. Үзе аңын җуйганда кызларының исемнәрен кәгазьгә язып калдырган була: Чан Ю һәм Чан Ва, ягъни Язгы Яңгыр белән Язгы Чәчәк.

– Димәк, әнием беренче иреннән булган ул кызларын гомере буе сагынып яшәгән. Минем янәшәмдә булганда да... гел аларны уйлаган, – дип, ачыргаланып, әтисеннән сорый Цзиньмэй, бу тарихны тыңлап бетергәннән соң. – Ә минем исемем нәрсәне аңлата, әти?

Һәм әнисен Америкага алып килеп, яңадан тормышка ышанырга өйрәткән, гомере буе аны саклап, хөрмәтләп яшәгән әтисе, елмаеп, җавап кайтара:

– «Кечкенә сеңел» дигәнне...

И снова я вижу ее, одну в двух лицах, она машет мне зажатой в руке поляроидной фотографией, которую я им отправила. И, как только я выхожу за ворота, мы бежим друг к другу и обнимаемся, все трое, забыв про все опасения и страхи. И теперь я наконец понимаю, какая часть во мне китайская. Это совершенно очевидно. Это моя семья. Это наша кровь. Сколько лет должно было пройти, чтобы я сама это почувствовала.

Психологлар тарафыннан күптән расланган факт: без гадәттә иң авырттыра торган хатирәләрне аңыбыздан кысрыклап чыгарырга тырышабыз. Чөнки алар һәрдаим яралап тора. Чөнки адәм баласы туктаусыз сыкранып-сызланып яши алмый. Әмма бу әсәрләр онытырга бик теләсәк тә онытылмаска тиешле хәтер барлыгын искә төшерәләр.

PRESSA.RU

ЧЫРШЫ АВЫЛЫ

«Татарстан» журналы, кызыклы атамалы татар авылларын, аларның тарихын һәм бүгенге яшәешен яктырту максаты белән, яңа сәхифә башлады. Сез дә безгә үз авылларыгызның хикмәтле яклары, гыйбрәтле хәлләре, уңган-булган кешеләре турында яза аласыз.

Биектау районы Чыршы авылы

ЫЛЫСЛАРГА КҮМЕЛГӘН ЧЫРШЫ

Биектау районында Чыршы исемле авыл бар. Гаҗәеп матур урынга урнашкан: тау астында инешләр ага, тау өстенең як-ягына йортлар тезелеп киткән. Бер як урамның озынлыгы чакрым ярымга җитә. Авылның гади, ачык халкы белән күрешеп, кызыклы язмышлы кешеләр белән таныштык.

Мин шушы авылда тудым, гомер иттем, – дип сөйләде җитмеш бер яшен тутырган Солтания апа Зарипова.

Автор:
Руфия Фазылова

«400 ЕЛЛЫК ТАРИХЫ БАР»

Авылга килеп кергәч тә шуңа игътибар иттек: күпләрнең капка төбендә чыршы үсә. Мәдәният йорты, башлангыч мәктәп каршында да мәгърур булып дистәгә якын ылыслы агач утыра. Авыл төзек, йортлар матур. «Үлеп баручы авыл түгел бу», – дип сөенеп куйдым.

Асфальт юлдан мәдәният йортына килеп туктадык. Киләсебезне алдан хәбәр иткәнгә күрә, авыл апалары безне шунда көтеп тора иде. Сүзебез танышудан, Чыршының үткәне, бүгенгесеннән башланды.

Мин шушы авылда тудым, гомер иттем, – дип сөйләде җитмеш бер яшен тутырган Солтания апа Зарипова. – Безнең яшьлектә Чыршы зур, балалар да күп иде: бер сыйныфта утызар укучы укыды. Бүген авылда бала саны аз, чөнки яшь гаиләләр күп түгел. Картлар бала тапмый, сеңлем. Мин үзем ялгыз яшим. Ирем Фидаил белән бер ул, бер кыз үстердек. Ул гомер буе колхозда машина йөртте, үзем фермада эшләдем. Фидаилем үлгәнгә ун ел, улым да яшьли гүр иясе булды. Кызым гаиләсе белән Казанда яши, кайтып йөриләр. Менә шулай яшәп ятыш...

Солтания апа сер генә бирми, – дип сүзгә кушылды Чыршы авылының мәдәният йорты директоры Лилия Гәрәева. – Алар гаиләләре белән сәнгатьне яратучылар. Фидаил абый тальянда уйный иде, Солтания апа да, кызы да җырлый. 8 мартка клубта «Ретро-концерт» куйдык. Озак еллар авылыбыз клубы сәхнәсендә чыгыш ясап йөргән хатын-кызлар, ир-атлар сәхнәне «ду» китерде. Шул концертта Солтания апа да өч җыр җырлады. Халык бик яратып тыңлады. Әле менә аның белән «Балкыш» фестиваленә барырбыз, дибез.

Солтания апа тыйнак кына елмайды. Ялындырып тормый гына безгә дә җырлап күрсәтте:

Сахраларда ялгыз йөргән чакта,
Мин яратам чәчәк исләрен...

Сигезенче дистәне ваклавына карамастан, Солтания апаның тавышы матур, моңлы, тын да алмый тыңладык. Сөйләшүебез акрынлап Чыршы тарихына күчте. Авылның мулласы Айрат хәзрәт Нигъмәтуллин менә нәрсәләр сөйләде:

– Рәсми чыганаклар Чыршы авылына дүрт йөз ел бар дип күрсәтә. Борынгы бабаларыбыз хәзерге җирдән өч-биш чакрым ерактарак урнаша. Анда көчле агымсулы кизләү була (мул сулы чишмәләрне бу якларда шулай дип атыйлар – авт.). Язгы ташулар белән кизләү тирәләрендә упкын хасил була. Шул упкын зурая баргач, бабаларыбыз бергәрәк килеп яши башлый. Соңрак, алар чишмәләр күп булуын күреп, авылның хәзерге урынына килеп урнашалар. Монда ул вакытта бөтен җирне чыршы агачлары баскан була. Аларны кисеп өйләр салалар. Авылга да «Чыршы» исеме бирәләр. Исеме җисеменә туры килсен өчен, халык бүген дә йорт каршысына чыршы агачлары утыртырга тырыша. Бу эштә мәктәп балалары да булыша.

Фото: Ната Смирнова

PRESSA.RU

Чыршы авылының иң өлкән кешесе – Сәгъдәт Рәхимова. Бүген ул килен булып төшкән нигезендә улы, килене гаиләсендә яши.

ИҢ ӨЛКӘН КЕШЕ

Чыршы авылының иң өлкән кешесе – Сәгъдәт Рәхимова. Аңа апрель башында 99 яшь тула. Биш бала – ике кыз, өч ул тәрбияләп үстергән. Дүрт баласын үзе тапкан, баккан, ә олы улы иренең беренче хатыныннан калган була. Бүген ул килен булып төшкән нигезендә улы, килене гаиләсендә яши. Әбинең акыл-зиһене бик әйбәт, әллә кайчангы вакытларны да хәтерли, оныкларын да исемләп белә. Тик бүген Сәгъдәт әбинең аяклары начар йөри, ике як тез башын сындырган була, шулар һаман үзен сиздерә икән. Һәм тагын колаклары начар ишетә. Әбигә сорауларны кычкырып бирергә туры килде:

Җәй көне урамга чыгам, әле өйдә генә утырам, – дип сөйләде авылның иң өлкән кешесе. – Ирем күптән үлде инде. Мин һаман яшим әле. Кайчан алып китәрләр…

Алай димә, Сәгъдәт апа. Яшә әле, караучыларың бар, үз аягыңда йөрисең, – дим әбигә.

Рәхмәт яусын, анысы, бик карыйлар. Нәрсә ашыйсым килсә, шул бар. Күршедә генә кызым яши, көн саен килә. «Үзебезгә алып чыгам», – дип әйткән иде, малай белән килен җибәрмәде. «Гомер иткән нигезендә яшәсеннәр», – диләр. Мин каршы түгел, үз йортым. Менә яңа комод, карават алып бирделәр. Киемнәрем шунда, алып киеп кенә торам. Калган бер улым, бер кызым да исән-сау, киләләр. Хәзер тормышлар бик матур, балалар өчен сөенәм. Без бик газап белән үстек. Черек бәрәңгедән башканы күрмәдек. Сугышлар юк. Бик рәхәт тормышлар, бик рәхәт…

Әби утырган төштән гел шулай үз алдына сөйли икән: бүгенге тормышны мактый. Чынлап та, балачагы, яшьлеге бик авыр заманга туры килгән шул аның. Әтисе авырып, абыйлары Бөек Ватан сугышында һәлак булган. Тормышны үз җилкәсендә тарткан. Ә аннан сугышта яраланып кайткан тол иргә кияүгә чыккан. Бер-бер артлы балалар тапкан.

Бу йортка килен булып төшкәнгә 41 ел булды, – дип сүзгә кушылды әбинең килене Гөлфия апа. – Гомер буе бергә яшәдек. Әни гел тырыш булды. Дүрт класс белеме бар. Колхозда склад мөдире булып эшләде. Санау эшләрен белә. Газета-журналлар, китаплар укый иде. Безнеңчә укый белә. Хәзер балага әйләнеп бара инде. Бер көн урамнан керсәм елаган: «Әнине сагындым», – диде. Күрәсең, уйлаган булган. Элеккеләрен искә алып сөйләп утыра. Яшәсен иде әле, дибез. Бер авырлыгы да юк. Йомышын үзе йомышлый, махсус җайланмага тотынып, үзе ашарга чыга. Мунчага да үз аякларында бара. Әйбәт әле, әйбәт. Оныклар аны аеруча ярата. Шулар кайтса, елмаеп утыра башлый, яшәреп киткәндәй була. Үзе янына килгәннәренә сөенә инде. Балалар исә: «Безнең әбигә йөз тула», – дип горурлана.

Гөлфия апа кебекләр турында: «Кулында ут уйната», – диләр. Гаҗәеп ачык, күңелле кеше ул. Колхозда хисапчы булып эшләгән, хәзер лаеклы ялда икән. Тиз арада табын әзерләп, тел йотарлык ризыкларын пешереп куйган иде:

Сез бөтен кешегә шулай ачык йөз күрсәтәсезме? – дип шаяртабыз.

Шундый инде мин, – дип елмайды Гөлфия апа. – Кергән кешене чәй эчерми чыгармый. Берсендә авылга чегәннәр килде. «КАМАЗ» машинасы белән колхозга нәрсәдер алып килгәннәр иде. Шуларны җәлләп, өйгә ашарга алып кайттым. Үзем дә аңламыйм: өйдәге унлап бизәнү әйберләрен бер-бер артлы чегәннәргә чыгарып бирдем. Янәсе, алтыннарны начар энергетикадан чистарталар. Тегеләр чыгып киткәч кенә аңыма килдем.

Ә бу хәлләрдән соң ирегез Радик абый нәрсә диде? – дим.

Нәрсә дисен инде, бер сүкте дә бетте. Чыгасы мал булгандыр. Азрак борчылып йөрдем дә тынычландым. Баш исән булсын, алтынны тагын алып була.

Алкалар турында сүз барганлыгын аңлап, Сәгъдәт апа да:

– Алтын йөзегемне кызыма бирдем, алканы Гөлфиягә бирдем, – дип куйды.

Әйе, әни: «Үзем исән вакытта алтыннарымны сезгә бүләк итәм. Тәсем итеп сакларсыз», – дип бирде. Шуны әйтә инде ул. Юмарт шул мин, – ди Гөлфия апа. – Ләкин шуңа игътибар итәм: кешегә берне бирсәң, Аллаһы Тәгалә уны белән кайтара.

Рәхимовларның йорты гаҗәеп нурлы, хәтта китәсе дә килми. Ләкин безгә авыл белән танышуыбызны дәвам итәргә кирәк: йөз дистәне тутыручы әби, кунакчыл хуҗалар белән саубуллашып, мәктәпкә таба юл тоттык.

ДҮРТ СЫЙНЫФКА 8 БАЛА

Чыршы авылы әллә ни зур түгел: 320 кеше яши, йөздән артык хуҗалык бар. Буш йортлар юк, булганнарын шәһәрдән кайтучылар сатып ала икән. Кемдер өйләрне җәйләрен яшәр өчен махсус дача урынына тота икән. Чыршы Казаннан 40 чакрым ераклыкта гына урнашкан.

Безнең авылда Рабит Батулла, «Мунча ташы» артистлары Шәмси Закир, Ульяна Князева кебек танылган шәхесләрнең дә йортлары бар, – диде клуб мөдире Лилия Гәрәева.

Чыршыларга күмелеп утырган Чыршы башлангыч мәктәбенә кердек. Киң, иркен коридорлы, бик якты ике катлы заманча мәктәп бу. Һәм шунда нибары 8 бала белем ала. Кызык та, кызганыч та булып китте.

Мәктәп 1996 елда ачылды, – дип сөйләде Чыршы башлангыч мәктәбе укытучысы Энҗе Хөсәенова. – Ул вакытта урта мәктәп иде, йөзгә якын бала укыды. 2011–2012 уку елыннан башлангыч мәктәпкә кал-

дырдылар. Зуррак сыйныф укучылары Дөбьяз урта мәктәбенә йөреп укый. Сыйныф саен икешәр бала. Ике укытучы без, ике сыйныфны бергә кушып укытабыз.

Чыршы башлангыч мәктәбе мөгаллимнәренең сөенече зурдан: балалар бакчасына 16 бала йөри. Димәк, мәктәп ябылмаячак, авылда исә бала-чага тавышы тынмаячак.

– Мәктәпнең икенче катында спорт лагеры эшли, – дип белем йорты белән таныштырып йөрде Энже Хөсәенова. – Җәен балалар өзелми, көзге каникулда да спортны яратучы укучылар килде. Бездән генә түгел, республика районнарыннан да җыелдылар. Язгы каникулга да киләләр, дип беләм. Шулай булгач, мәктәп бинасы буш тормый.

Чишмәгә яңа җан өргән кеше Илһам Гарифуллин хөрмәтенә «Илһам» дип исем биргәннәр.

АВЫЛНЫ ЯШӘТҮЧЕЛӘР

Чыршыда тагын бер үзенчәлекле гаилә белән таныштык – Илһам һәм Гөлчәчәк Гарифуллиннар. Йортлары әллә кайдан балкып тора. Бөтен җир төзек, нәзакәт белән эшләнгән. Хәтта эт оясы да курчак өен хәтерләтә. Ә иң мөһиме – боларның барысын да хуҗа кеше үз куллары белән ясаган. Илһам белән Гөлчәчәк 3 бала үстерәләр: Динә, Динара, Дамир. Олы кызлары Казанда югары белем ала, Динара көллияттә, ә төпчек уллары 1 сыйныфта укый. Гаилә башлыгы сату белән шөгыльләнә, дөресрәге, кечкенә авылларга автолавка белән йөри. Гөлчәчәк исә авылда фельдшер. Илһам белән танышып булмады, сату белән чыгып киткән иде. Бары ул эшләгән сәнгать әсәре булырдай җиһазларны күреп сокландык.

Тик тора белмибез, – дип сөйләде көләч йөзле хуҗабикә ханым. – Мал асрыйбыз, кош-корт тотабыз. Бакчабыз зур. Җәй көне тирә-юнебез чәчәккә күмелә. Кышын иркенрәк. Кичләрен тик утырмыйм, бәйләргә яратам. Илһам да үзенә кул эше тапты: тимердән бизәкләп ишек яңаклары, кыеклар эретеп ясый, агачтан да әллә ниләр майтара. Соңгы ике елда бу эш белән бигрәк тә «җенләнде». Эретеп-ябыштыру җайланмалары сатып алды. Эштән кайтып хайваннарны карагач, гаражында мәш килә. Әтиләренең нинди әйберләр ясаганын күреп, балалар да сөенә. Илһам аларга үз эшләрен зур бер сөенеч белән күрсәтеп йөри.

Илһам тагын җырлый, бии дә, – дип сүзгә кушылды безнең белән Гарифуллиннар гаиләсенә кергән мәдәният йорты директоры Лилия Гәрәева. – Авылда әле шундый гаиләләр бар, дим. Нәрсә әйтсәң дә тыңлыйлар, бергә концертлар куябыз.

Гарифуллиннар йортына җиткәнче, тау астына төшеп, «Илһам» чишмәсен карадык. Төсле поликарбонаттан бизәкләп эшләнгән чатыр эченә миләш тәлгәшле самовар куйганнар. Аннан су килеп тора. Бик күркәм күренеш.

Ул чишмә безнең бакча башыннан гына ага, ташландык хәлдәрәк иде, – ди Гөлчәчәк ханым. – Илһамның чишмәне бик матурлыйсы килде. Самовар ясау өчен газ баллонын кисеп, аерым детальләр эретеп ябыштырды. Аннан аны бизәкләп буяды. Чишмә өчен чатыр да ясады. Вакыты булган саен, тау астына гел төшеп менәбез. Язгы сулар самоварны агызып китмәсен, дибез.

Чишмәгә яңа җан өргән кеше хөрмәтенә «Илһам» дип исем биргәннәр. Гарифуллиннарның теләк-хыялы: бу изге урынны балалары да гел шулай карап, чистартып торсын, әтиәниләренең ядкаре итеп сакласын иде.

Чишмәне узган елның сентябрь башында зурлап ачтык, – диде Лилия Гәрәева. – Палаткалар корып, коймаклар пешереп, авылның бар халкын җыйдык. Җыр-моң яңгырап торды. Бик матур авыл бәйрәме булды ул. Гомумән, без күңелле яшибез, Гарифуллиннар кебек тагын берничә актив гаилә бар. Бәйрәмнәрне бергә үткәрәбез, районда узган бер генә чарадан да калмыйбыз.

Илһам Гарифуллин киләчәктә тимердән бизәкле кыеклар эшләүне дәвам итәргә уйлый икән. Гараж кыегын күреп, күршесе дә «заказ» биргән.

Илһам алар белән акча эшләүне максат итеп куймый, – ди Гөлчәчәк. – Ул аңа рәхәтлек бирә. Башта дәфтәргә әллә ничә төрле рәсем ясый, карый. Аннан шуны тимердән ясый.

Илһам һәм Гөлчәчәк Гарифуллиннарның йортлары әллә кайдан балкып тора. Бөтен җир төзек, нәзакәт белән эшләнгән.

Кем белә, бәлки киләчәктә махсус сатар өчен дә эшләр. Әйтәм бит, шулар белән бик «җенләнде».

...Татар авылларына барган саен аның уңган кешеләренә сокланып кайтам. Таң атуга-алар аяк өстендә. Әллә ничә сыерын да сава, эшенә дә бара, йорт-җире дә ялт иткән. Чыршы авылында андый гаиләләр күп икән, шуңа сөендек. Калага якын булгангамы, халык шәһәрчәрәк яши монда: душы, бәдрәфе өендә, башка бөтен уңайлыклар да бар. Казанга концерт-спектакльләр карарга да еш баралар икән. Кыскасы, биредә тормыш гөрли.

PRESSA.RU

Безнең бүгенге легендабыз Свияжскига карый. Авторы, әлбәттә, халык, әмма аны безгә Свияжск музей-тыюлыгы директоры Артем Силкин язып җибәрде.

ТАТАРСТАН РИВАЯТЬЛӘРЕ: БЕР ПЛЮС ТУГЫЗ

Свияжскида бер председатель яшәгән. Председательнең хезмәткәрләре генә – эх... Берсе эчә, икенчесе ялкау, ә өченчесе эчми дә, ялкауланмый да, эшләвенә караганда, эшләмәве яхшырак.

Шулай бервакыт председатель кайгырып, уйга батып утыра икән. Кемдер эшләргә тиеш бит, ә кем – һич аңлый алмый! Халык арасында сихерче карчык буларак даны таралган Сметаниха янына барырга була бу. Аннан киңәш сорамакчы, янәсе, гади кешенең акылы җитмәгән нәрсәләр турында сораштырырга өметләнә.

Карчык яшәгән өй янына килә бу, әкрен генә шакый. Сметаниха кунакны өстәл янына чакыра. Чынаякка ниндидер кайнар сыеклык агыза. Председательнең чынаякны ирене тирәсенә китерүе була – катып кала: чынаяктан аңа җем-җем килгән йолдызлы күк бага...

– Күккә төнлә багарсың! Ни йомыш белән килдең – сөйлә, – дип, сәер елмаю белән сорый Сметаниха.

Шулай дигәч, тегесе барысын да сөйләп бирә: кайсы эчә, кайсы эштән кача, тегесе бөтенләй исәр, эшли дә, тик эшләтә башлаганчы, ярты көн үгетләргә кирәк.

– Карап торам менә, синең өчен барысы да – әллә ниндиләр, син үзең нинди соң?

Председатель иңнәрен сикертеп ала:

– Мин менә нәкъ шундый, кирәкле кеше, минем кебекләр берәр дистә булса – эшләр бөтенләй башкача барыр иде!

Карчык көлемсерәп куя да болай ди:

– Ну, моны эшләүнең әллә ни катлаулылыгы юк. Менә моны эчеп куй, иртәгә барысы да синеңчә булыр.

Һәм иргә ниндидер кечкенә шешә суза. Уйлап та тормый, эчеп куя председатель, чәй тәлинкәсе астына карчыкка дигән өчлеген тыга да өенә кайтып китә. Сөйләшү турында шунда ук оныта – тик төне буе чынаякта чагылган йолдызлы күк төшенә кереп газаплый.

Уянып китә – бүлмәдә үзенә игезәктәй охшаган тагын тугыз кеше шыпырт кына сөйләшәләр! Моның уянганын күреп, бердәм исәнләшәләр.

– Нәрсә бу?! – председатель күземә күренәләр дип, каушап кала.

Ә бүлмәдәгеләр, ирен читләре белән генә елмаеп, җавап бирә:

– Син бит үзең кичә Сметанихадан үзең кебекләрне үрчетүне сорадың – менә алар без инде! Нәрсә эшләргә кирәк – әмер бир!

Һәм эш гөрли башлый! Ул уйлап кына куя – тегеләр инде эшкә ябышалар. Барысын да моныңча эшлиләр, бәхәсләшеп, сүз куертып тормыйлар. Председательгә барысы да ошый.

Свияжскида монастырь диварлары артында аның яраткан урыны була. Шунда еш кына ялгыз калып, ерактагы Идел күперенә карап хыяллана яисә тәмәке төтәтә ул. Менә, гадәттәгечә, шул урынга килә – ә анда теге яңалар тугызау утырып торалар, тәмәке тарталар, күперне күзәтәләр. Моңа урын да калмаган, һәм, гомумән, аның ялгызы гына буласы килә – берни эшләп булмый, борылып китә ир.

Икенче тапкырында сөйгәненә кагылырга уйлый – ул санитарка булып эшли. Ромашкалар җыеп, өенә бара. Килсә, ни күрсен, козгыннар кебек тугыз кеше инде ишек янында. Санитарка пәрдә читен күтәреп карый да куркып кала, берни аңламый! Ир аптырап сүз ката:

– Егетләр, сез нәрсә монда? Бу бит минем сөйгәнем – үзегезнекен эзләгез!

Тегеләр болай дип җавап бирә:

– Юк, хөрмәтлем, безгә башка беркем дә кирәкми, без бу кызны яратабыз – синең кебек буласыбыз килә!

Председатель ачудан чырт иттереп төкерә дә чәчәкләрен җиргә атып бәреп китеп бара! Иртән килсә, күлдәвектә шундый ук тугыз чәчәк бәйләме ята!

Әллә ничек булып китә аңа...

Җитмәсә, ирнең әнисе дә улының хәлен белергә уйлый – һәм тугыз егет моның әнисен кочып ала, аның кебек шатлана. Әни карчык кемнең кем икәнен һич кенә дә аңламый. Әле берсен сөя, әле икенчесен, ниһаять, бердәнберен тапкан кебек була: менә ул, чын улы! Юк шул, ялгыша. Кучтәнәчне дә унга бүлә. Шулчак председательнең сабыры төкәнә. Уйлап куя – менә шулай өйләнерсең дә: балалар ун кешегә әти диярләрме?!

Сметанихага йөгерә ир, аягына егыла:

– Мин җүләрне кичер! Барысын да кире кайтар!

Сабак булсынга, бераз газапларга уйлый да карчык, тик күрә: кеше акылга утырган. Чебен һәм тараканнарда төнәткән төнәтмәне бирә иргә. Стакандагы сыеклыкны эчкәч, күз аллары караңгылана, ә инде айнып киткәндә, тугыз ир-ат юкка чыккан була!

Шуннан бирле ул ун кешелек итеп эшли, ә янәшәдәгеләр нинди генә булмасыннар, алар белән уртак тел табарга тырыша. Эш, бәлки, игезәкләре белән эшләгәндәгедәй тиз дә бармыйдыр, тик күңеленә тынычлык иңә. Без төрле булырга тиеш, бөтенебез бертөрле булганда бернинди дә кызык калмый бит!

АЙ КӘЕФЕ: **БАЛАЛАРЧА**

Март аенда «Татарстан» журналы редакциясенә 4 яшьтән 14 яшькә кадәрле булачак космонавтлар, төзүчеләр, милиционерлар, археологлар, блогерлар һәм табиблар килде. Аеруча стоматологлар күп иде. Әмма алар бик тиз генә профильләрен журналистныкына алыштырды, һәм дәваланып сәламәтләнгәч вә үскәч, ул вакытка инде пенсиягә китәчәк «Татарстан» журналы хәбәрчеләренә алмашка килергә вәгъдә итте. Күпләре, балигълык яшенә җитүне көтеп тормастан, шунда ук беренче хәбәрләрен язарга утырды. Әлегә яза белмәгәннәре рәсем ясарга керешә. Анысы да, монысы да матур килеп чыкты! Хәзер «Татарстан»ның баш мөхәррире борчылмый – хәтта мөхәррир кәнәфиен дә калдырырлык кешеләр бар.



Ковригин. Влад. 7. лет.
Я. ЛЮБЛЮ ПРЕДМЕТ
ЛИТЕРАТУРНОЕ ЧТЕНИЕ.
МОЙ ЛЮБИМЫЙ!
РАССКАЗ „КОЛОБОК".
!МОЙ ЛЮБИМЫЙ
ГЕРОЙ КОЛОБОК.

«Географияне яратам, миңа шәһәрләрне һәм илләрне өйрәнү бик ошый. Мин бик күп шәһәрләрдә булдым. Казанга, Әлмәт, Бөгелмә, Лениногорск, Түбән Кама, Яшел Үзән һ.б. шәһәрләргә бардым. Үсәргә һәм тагын күп җирләрдә булырга телим. Бөтен дөньяны күрәсем килә!»

Диана Идрисова, 12 яшь

«Мин 4 нче класста укыйм. Иң яраткан дәресем – әйләнә-тирә дөнья. 10 елдан соң археолог булырга телим. Мин борынгы калдыкларны һәм савыт-сабаларны казып табачакмын. Аннан соң шул борынгы калдыклар буенча экскурсияләр үткәрәчәкмен».

Гадел Гыйззәтуллин, 10 яшь

«Мин планшетта уеннар уйныйм. Анда – ике уенчы, алар канатлар белән кортлар җибәрәләр һәм уртадагы ике манараны җимерергә тиешләр. Иң мөһимендә – король, әгәр аның манарасын җимерсәң, икесе дә җимереләчәк...».

Илнур Ногманов, 12 яшь

Входит в группу компаний КОМОС ГРУПП

ГКЗ | ГЛАЗОВСКИЙ комбикормовый завод

СТАНЬ ДИЛЕРОМ

ГЛАЗОВСКОГО КОМБИКОРМОВОГО ЗАВОДА
В ЛЮБОМ РЕГИОНЕ РОССИИ!

ДИЛЕРАМ МЫ ОБЕСПЕЧИВАЕМ:

- бесплатные образцы комбикормов
- рекламный баннер на торговую точку
- инструкции по кормлению и каталоги продукции
- % скидки*

Позвони и уточни условия сотрудничества

+7 (912) 010-53-51, ljapushinds@kombi-korm.ru, www.kombi-korm.ru

* Подробности по телефону +7 (912) 010-53-51. Срок действия скидок до 31 декабря 2017 г.

Реклама